


# КУАНЫЧ

## ТӨБӘКНЕҢ МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАСЫ

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ЭМОЦИОНАЛЬ ИНТЕЛЛЕКТ



КҮРШЕ
УМАРТА
ул үрдәк
зәңгәр
умырзая
ҮЛӘН
СҮЗ
сум
нәрсә
өй
кыяр
һәйкәл
ОЧРАШУ
ЗИННҺАР
кыш
ләкләк
көчтәнәч
өн
ЕЛ
мәхәббәт
пәрәмәч
елга
нечкә
оста
кибет
песи
кадерле
ТӨЗ
һич
лаек
океан
кыяр
исә
кайдан
ял
оя
озак
кызыл
гөбәдия
вак
ерткыч
дуслык
үрдәк
оча
нәрсә
хәл
нигез
җомга
ЖИТМЕШ
җөмлә
җөмһүрият
чүл
КЫЙБАТ
кыйммәтле
егет
ешш
даруханә
очрашу
һәйкәл
НЕФТЬ
күрше
һәм
мәңгегә
дүрт
ут
җавап
егерменче
кавын
олы
он
ҮСМЕР
һава
чәч
НӘНИ
һӘРВАКЫТ
сулыш
ял
исәнлек
лаек
океан
хәл
тарак
озак
татар
ТҮБӘ
АЙ
ЮЛ
лачын
ЗАТ
мөһим
егет
келәм
пешекче
АЙ
җомга
каен
китап
олы
сабан
ЭТ



УДК 373.2
ББК 74.14
Ш16

Р е ц е н з е н т л а р:
**М.З. Закирова**, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары, педагогика фәннәре кандидаты;
**Л.Н. Ногманова**, «Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты» ректоры, педагогика фәннәре докторы;
**Й.Ш. Хисамиева**, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәктәпкәчә белем бирү бүлеге җитәкчесе

*Авторлык хокуклары турында гамәлдәге законнар белән саклана (РФ Гражданлык кодексы, 4 нче өлеш, 70 нче бүлек). Нәшриятның язмача рөхсәтеннән башка китапны тулысынча яисә өлешләп теләсә кайсы төрдә бастыру тыела.*

**Шәехова, Р. К.**
Ш16 «Куаныч» төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы. – Казан: Татар балалар нәшрияты, 2024. – 146 б.

ISBN 978-5-6050160-1-4

Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандарты, Федераль мәктәпкәчә белем бирү программасы таләпләренә туры китереп эшләнгән. Әлеге Программа максат һәм бурычларны, планлаштырылган нәтиҗәләрне, мәгариф эшчәнлеген оештыруны, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан балачак үсешенең этномәдәни һәм яңа социомәдәни вазгыятен исәпкә алып формалаштырыла торган мәктәпкәчә белем бирүнең эчтәлеген билгеле. Программа белем бирүнең иң югары максатын – кеше турында әхлакый (идеаль) күзаллау буларак аңлана торган милли тәрбия идеалын гамәлгә ашыруга нигезләнә.

Басма татар телендә тәрбия һәм белем бирә торган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында эшләүчеләргә, тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарына, шулай ук урта һөнәри һәм югары белем бирү оешмаларында белем алучы укучыларга тәкъдим ителә.

УДК 373.2
ББК 74.14

ISBN 978-5-6050160-1-4

© Шәехова Р. К., 2024
© Татар балалар нәшрияты, 2024
Барлык хокуклар да якланган

Р.К. Шәехова

# КУАНЫЧ

## ТӨБӘКНЕҢ МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАСЫ

Казан
2024

# КЕРЕШ

«Куаныч» төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы (алга таба – Программа) 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы «Россия Федерациясендә Мәгариф турында»гы Федераль законына, 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы «Мәгариф турында»гы ТР Законына (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә), 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында»гы ТР Законына (2014 елның 12 июнендәге редакциясендә), 2013 елның 17 октябрендәге 1155 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгы белән расланган Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандартына (алга таба – ФДМББС), 2022 елның 25 ноябрендәге 1028 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының боерыгы белән расланган Федераль мәктәпкәчә белем бирү программасына (алга таба – ФМББП) һәм 2015 елның 17 июнендәге 443 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән расланган 2015–2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларны тәрбияләүне үстерү стратегиясенә туры китереп эшләнгән.

Программада 2–7 яшьлек балалар өчен белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан төбәкнең иҗтимагый-мәдәни һәм милли кыйммәтләрен исәпкә алып формалаштырыла торган белем бирү эчтәлеге чагылыш таба, күпмилләтле Россия Федерациясе халыкларының тел мирасын саклау һәм үстерүне тәэмин итү максатыннан әлеге программаны туган (татар) телдә тормышка ашыру каралган.

Программа нигезендә Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары (алга таба – Оешма, МББО) мәктәпкәчә төп белем бирү программасының (алга таба – МТББП) вариатив өлешен мөстәкыйль эшли һәм раслый.

Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыклары, бала үсешендә белем бирүнең әйдәп баручы роле, балага шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы психология һәм педагогика фәннәренең фундаменталь тикшеренүләренә (А.Г. Асмолов, Л.С. Выготский, В.В. Давыдов, П.Я. Гальперин, А.В. Запорожец, А.Н. Леонтьев, Н.Н. Поддьяков, С.Л. Рубинштейн, Д.И. Фельдштейн һ.б.), мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә әйдәп баручы белгечләрнең хезмәтләрендә чагылыш тапкан гамәли эшкәртмәләргә һәм методик киңәшләргә, фәнни тикшеренүләр нигезләмәләренә, МББО эшчәнлеген көйли торган башка норматив-хокукый актларга нигезләнә.

Программа Оешмада һәр баланың эмоциональ иминлеген тәэмин итүче, баланы тел, предмет, табигать, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә, шулай ук танып белү, үзгәртеп кору һәм иҗат итү ысулларына нигезләнгән гомумкешелек мәдәнияте белән таныштыру һәм аны үзләштерү өчен шартлар тудыруны күз уңында тоткан мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсеше проблемасына мәдәни-тарихи якын килүгә (Л.С. Выготский, В.Т. Кудрявцев) туры китереп эшләнде. Тәрбия процессында баланың үсеше һәм үзүсеше закончалыкларын, аның үсешендә белем бирүнең әйдәп баручы ролен, мәдәни-тарихи, эшлекле (гамәли) һәм шәхси якын килүне исәпкә алу һәр кешенең милләтен билгели торган аерым бер мәдәниятка каравын, үз (татар) халкының вәкиле итеп расларга омтылуын мәктәпкәчә яшьтә аңлавын күз алдында тота.

«Куаныч» төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы белем бирүнең иң югары максатын – кеше турында әхлакый (идеаль) күзаллау буларак аңлана торган милли тәрбия идеалын гамәлгә ашыруга нигезләнгән. Балаларга тәрбия бирү процессы нигезендә Татарстан Республикасы халыкларының конституцион, гомумкешелек һәм милли кыйммәтләре ята.

Бу кыйммәтләрне бала үзләштерә алсын өчен, алар тәрбиянең төп юнәлешләрендә чагылыш табарга тиеш. Әйтик, патриотик тәрбия нигезендә – Ватан, кече ватан, туган җир, туган як табигате кыйммәтләре, шәхесне социальләштерү нигезендә кеше, дуслык, гаилә һәм нәсел кыйммәтләре ята. Туган якны, туган телне белү кыйммәтләре – танып белү-сөйләм үсеше нигезенә, сәламәтлек кыйммәте – физик тәрбия, хезмәт кыйммәте хезмәт тәрбиясе нигезенә салынган. Тәрбиянең этик-эстетик юнәлеше нигезендә матурлык, гомумкешелек һәм милли мәдәният кыйммәтләре ята.

«Милли мәдәниятне, үз халкының рухи кыйммәтләрен үзләштерү, аны шушы җирдә яшәүче башка халыклар мәдәнияте белән баету, баланың мәдәнияткә карашы киләчәктә аңа бөтендөнья мәдәниятен аңларга ярдәм итәчәк. Бары тик үз халкының мәдәниятенә мондый киң караш, аны колачлы мәдәни процесслар контекстында кабул итә белү генә иҗади шәхес формалаштыруга һәм үстерүгә нигез булып торачак, бу, үз чиратында, балага милли мәдәнияткә пассив рәвештә карамыйча, аңа шәхсән үз өлешен кертергә, мәдәниятне тудыру процессына кушылып китәргә мөмкинлек бирәчәк» (Ф.Ф. Харисов).

Программа балачакны уникаль чор буларак тануны чагылдыра. Бу чорда янәшә яшәүче халыклар белән дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыру һәм аралашу нигезендә туган як тарихын, мәдәниятен, әдәбиятын һәм сәнгатен, гореф-гадәтләрен һәм көнкүрешен, туган як табигатен, туган телне танып белү гомумкешелек мәдәниятен үзләштерүгә нигез сала.

ФДМББС таләпләренә туры китереп, Программаның эчтәлеге өч төп бүлектән – максатлар, эчтәлек һәм оештыру бүлекләреннән тора.

*Максатлар* бүлеге Программаның максатын, бурычларын, принципларын, аны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләрен, шул нәтиҗәләргә ирешүнең педагогик диагностика алымнарын билгели.

Программаның *Эчтәлек* бүлеге барлык яшь төркемнәре өчен һәр белем бирү өлкәсенең (иҗтимагый-коммуникатив, танып белү, сөйләм үсеше, сәнгати-эстетик, физик үсеш) белем бирү (укыту һәм тәрбия) бурычларын һәм эчтәлеген үз эченә ала.

*Оештыру* бүлеге Программа максатларына, аны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле белем бирү эшчәнлегенең гамәлгә ашырылу шартларын, шулай ук әлеге эшчәнлекне оештыру үзенчәлекләрен тасвирлый.

Программа буенча фикер алышуда катнашкан һәм аны эшләүдә ярдәм күрсәткән: музыкаль репертуар сайлаган өчен, Казан шәһәре Идел буе районы 23 нче балалар бакчасының музыка җитәкчесе З.Г. Ибраһимовага; балалар әдәбиятының якынча исемлеген төзегән өчен, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы К.В. Закировага; Татарстан Республикасы сынлы сәнгать әсәрләренең якынча исемлеген төзегән өчен, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәктәпкәчә белем бирү бүлегенең әйдәп баручы консультанты Т.А. Сидоровага; «Татармультфильм» берләшмәсенең мультипликацион фильмнары исемлеген төзегән өчен, «Татармультфильм» берләшмәсенең башкарма директоры А.Т. Низамиевага; Программаны апробацияләүдә катнашкан өчен, Казан шәһәренең 78 нче һәм 101 нче мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең педагогик коллективларына; тәрҗемә итүдә күрсәткән ярдәмнәре өчен, Казан шәһәре Совет районы 415 нче балалар бакчасы мөдире Р.Ә. Кадыйровага; Казан шәһәре Совет районы 109 нчы балалар бакчасының татар теленә өйрәтү тәрбиячесе Л.Н. Шәйдәевага; Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 365 нче балалар бакчасының татар теленә өйрәтү тәрбиячесе М.С. Нургалиевага рәхмәт белдерәм.

*Хөрмәтле коллегалар! «Куаныч» төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы сезгә җәмгыятькә уңышлы яраклашу өчен шартлар тудыруда, балаларның туган як тарихы һәм мәдәниятен, әйләнә-тирә табигатьне танып белүләрен мавыктыргыч һәм куанычлы итүдә ярдәмгә килер, шулай ук мәктәпкәчә белем бирү эчтәлегенең вариативлыгын һәм төрлелеген тәэмин итәр, дип ышанабыз. Бу алга таба иҗтимагый-мәдәни һәм милли кыйммәтләрне үзләштерү, дөнья мәдәниятен танып белү, шәхеснең рухи яктан баюы, Татарстан Республикасының үсеп килүче буынына патриотик тәрбия бирүе өчен нигез булачак.*

Р.К. Шәехова,
«Казан (Идел буе) федераль университеты»
Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен
күтәрү һәм белем арттыру үзәгенең мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү
бүлеге доценты, педагогика фәннәре кандидаты

# 1. МАКСАТЛАР БҮЛЕГЕ

## 1.1. АҢЛАТМА ЯЗУЫ

### 1.1.1. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның **максаты** – мәктәпкәчә балалык чорында, яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы халыкларының гомумкешелек һәм милли кыйммәтләре, тарихи һәм милли культура традицияләре нигезендә баланың төрле яклап үсешен тәэмин итү.

Куелган максатка түбәндәге **бурычларны** хәл итү аша ирешергә мөмкин:

– яшәү урыны, җенесе, милләте, теле, иҗтимагый статусына бәйсез рәвештә, мәктәпкәчә балачак чорында һәр баланың тулы үсеше өчен тигез мөмкинлекләр булдыру;

– балаларның гомуми культурасын формалаштыру, аларның физик, шәхси, әхлакый сыйфатларын, ватанпәрвәрлек нигезләрен, интеллектуаль һәм сәнгати-иҗади сәләтләрен, инициативалылыгын, мөстәкыйльлеген һәм җаваплылыгын үстерү, уку эшчәнлегенә алшартлар формалаштыру;

– аралашу һәм культура чарасы буларак, сөйләм телен үстерүдә, мәктәпкәчә һәм башлангыч гомуми белем бирү максатлары, бурычлары һәм эчтәлегенең күчүчәнлеген, мәктәпкәчә белем бирү оешмасы чыгарылыш баласының «Туган (татар) тел» уку предметын өйрәнүгә әзерлеген тәэмин итү;

– Россия Федерациясенең дәүләт теле буларак, рус телен үзләштерү, аралашу күнекмәләрен үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру;

– белем һәм тәрбия бирүне татар халкының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә бербөтен белем бирү процессына берләштерү;

– төбәкнең милли үзенчәлекләрен исәпкә алып, балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләренә туры килгән социомәдәни мохит формалаштыру;

– гаиләгә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү, гаилә тәрбиясе мәсьәләләрендә һәм Оешманың мәктәпкәчә белем бирү сыйфатына бәя бирүдә ата-ананың (законлы вәкилләрнең) компетентлылыгын арттыруны тәэмин итү.

Программа белем бирү эшчәнлегенең түбәндә күрсәтелгән ике төп оештыру моделендә алып барылуын тәэмин итә:

– өлкән кеше һәм балаларның уртак эшчәнлеге;

– балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге.

Программа, 6 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларга белем бирү процессын оештырганда (мәктәпкәчә белем бирүнең соңгы этабында), яшь үзенчәлекләренә туры килгән укыту моделен кертүне күз уңында тота.

Эчтәлек бүлегендә белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырыла торган мәктәпкәчә мәгарифнең төп белем бирү программасы эчтәлегенең бер өлеше бирелгән. Әлеге бүлек бер-берсен үзара баетучы барлык биш белем бирү өлкәсендә (иҗтимагый-коммуникатив, танып белү, сөйләм, сәнгати-эстетик һәм физик үсеш) балаларның үсешен тәэмин итә торган мәдәни-тарихи, эшчәнлекле һәм шәхси якын килүне күздә тота.

**«Иҗтимагый-коммуникатив үсеш»** белем бирү өлкәсе эчтәлегенә шәхесне социальләштерү, әхлак һәм әдәп кагыйдәләрен, балаларның туган (татар) телендә аралашуын һәм үзара мөнәсәбәтләрен, башка милләт вәкилләренә дустанә мөнәсәбәтен дә кертеп, җәмгыятьтә кабул ителгән норма һәм кыйммәтләрне үзләштерү керә. Аралашуның уңышы бер-береңне аңлауда, дуслык һәм низагсыз үзара мөнәсәбәтләрдә чагылыш таба.

Бала тарафыннан милли кыйммәтләрне үзләштерү, үз гаиләсенә, туган ягына, Ватанына мәхәббәт тәрбияләүдә татар телендә аралашу, мәдәни өлкәдә балалар эшчәнлегенең төрлелеге төп шарт булып тора.

**«Танып белү үсеше»** белем өлкәсе эчтәлегендә иң мөһиме булып балада туган як һәм Ватан, социомәдәни кыйммәтләр, татар халкының традицияләре һәм көнкүреше, туган як табигатенең үзенчәлекләре турында беренчел күзаллаулар формалаштыруда баланың кызыксынуын, күбрәк белергә теләвен, танып белүгә омтылышын үстерү тора. Эзләнү һәм туган якны өйрәнү эшчәнлеген, балалар өчен танып белү туризмын оештыру балада экологик культура, туган җиргә һәм аның табигый ресурсларына сакчыл караш формалаштыру мөмкинлеген бирәчәк. Балаларны танып белү, мәдәни, төбәкне өйрәнү проектларына, тыюлыклар, туган шәһәр, башкала буйлап виртуаль экскурсияләрдә катнашуга җәлеп итү, шулар белән беррәттән, мавыктыргыч укулар, музейларга йөрү үсеп килүче буында дөнья һәм җәмгыять төзелеше турында фәнни танып белүләр белән кызыксыну уятырга булышачак.

**«Сөйләм үсеше»** белем бирү өлкәсе эчтәлегендә иң мөһиме булып туган (татар) телне үзләштерүгә тотрыклы кызыксыну үстерү, аны үз фикерләреңне, хис һәм теләкләреңне чагылдыру өчен файдалану тора.

Балаларны табигый тел мохитенә кертеп җибәрү, алдынгы үстерешле һәм цифрлы технологияләрне, укыту-методик комплектларын куллану, аудио- һәм видеоязмалар тыңлау, «Татармультфильм» берләшмәсе мультфильмнарын карау, балаларның төрле төр эшчәнлеген оештыру, дөрес язарга өйрәтүгә алшарт буларак, ана телендәге сүз байлыгын арттыруга, бәйләнешле, грамматик яктан дөрес диалогик һәм монологик сөйләм, интонацион культура үстерүгә, татар балалар әдәбияты һәм шигърияте белән танышуга, авазның аналитик-синтетик активлыгын формалаштыруга ярдәм итәчәк. Балалар эшчәнлегенең үзенчәлекле төрлелеге һәм аларның интеграциясе нәкъ менә бала сөйләменең баюына һәм камилләшүенә булыша да инде.

**«Сәнгати-эстетик үсеш»** белем бирү өлкәсе балада дөньяга эстетик мөнәсәбәт формалаштыру һәм милли мәдәният чаралары ярдәмендә баланы сәнгати яктан үстерү берлегендә карала. Мәктәпкәчә белем бирү системасына милли мәдәният чараларын кертү аның элементлары – халык авыз иҗаты, фольклор, музыка, рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать, театр, халык уеннары, җыр-биюләре һ.б. педагогик потенциалы аша гамәлгә ашырыла.

**«Физик үсеш»** белем бирү өлкәсе эчтәлегенә сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру башлангычы салынган. Балаларны туган җирләрендә хәлләреннән килгәнчә хезмәткә җәлеп итү, сәламәт туклану, халык уеннары һәм бәйрәмнәрендә катнашу, сәламәтлекләрен исәпкә алып, физик культура һәм милли спорт төрләре белән даими шөгыльләнүләре сәламәт буын тәрбияләү мөмкинлеге бирәчәк.

Татар халкының гасырлар буе тупланган зирәк акылы һәм мәдәниятенең иң кыйммәтле җәүһәрләре мәктәпкәчә мәгариф системасының бер өлеше булып тора.

Белем бирү өлкәләренең якынча эчтәлеге балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләренә бәйле һәм эшчәнлекнең түбәндәге төрләрендә гамәлгә ашырыла:

– уен (хәрәкәтле халык уеннары, әйлән-бәйлән һ.б.);

– коммуникатив (яшьтәшләре белән туган (татар) телдә үзара аралашу, уйнау);

– танып белү-тикшеренү һәм экспериментлар уздыру (туган як тарихын, мәдәни байлыкларын, табигатен өйрәнү);

– татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләре, фольклорның милли-мәдәни колориты үзенчәлекләре белән укып танышу;

– хезмәт (үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, иң гади көнкүреш хезмәте һәм туган җирдә хәлдән килгәнчә хезмәт күрсәтү);

– рәсем сәнгате (татар декоратив-гамәли сәнгатен һәм татар рәссамнары картиналары белән танышуны да кертеп);

– төрле материаллардан конструкцияләү;

– музыкаль эшчәнлек (татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлау һәм кабул итү, татар халык җырларын җырлау, татар халык биюләрен башкару, халык музыка уен коралларында уйнау);

– хәрәкәт активлыгы (төбәк һәм муниципаль традицияләр исәпкә алынган активлык формалары).

### 1.1.2. Программаны формалаштыру принциплары һәм ысуллары

Барлык белем бирү өлкәләре эчтәлеген гамәлгә ашыру түбәндәге **принципларга** нигезләнә:

• *балачак төрлелеген саклау* әлеге төрлелекне кыйммәтлелек, белем бирү ресурсы итеп карый һәм белем бирү процессын баетуны күз алдында тота. Оешма белем бирү эшчәнлеген төбәк һәм муниципаль үзенчәлекләрен, һәр бала үсешенең социомәдәни вазгыятен, аның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен, кыйммәтләрен, фикерләрен һәм аларны чагылдыру ысулларын исәпкә алып төзи;

• *балалык чорының уникальлеген һәм үзкыйммәтен саклау* сабыйның балачакның барлык этапларын (сабыйлык, иртә һәм мәктәпкәчә чор) тулы рәвештә үтүен, бала үсешен баетуны (амплификация) күздә тота;

• *җәмгыятькә позитив яраклашуы* баланың культура нормаларын, эшчәнлек чараларын һәм ысулларын, үз-үзеңне культуралы тоту үрнәкләрен һәм туган (татар) телендә аралашуын, гаилә, җәмгыять, дәүләт традицияләрен үзләштерүе өлкәннәр һәм башка балалар белән үзара бәйләнеш процессында бара, бу исә үзгәрүчән дөньяда баланың тулы кыйммәтле эшчәнлеге өчен алшартлар тудыра;

• өлкәннәр һәм балалар арасындагы үзара *мөнәсәбәтләрнең шәхси-үстерешле гуманлы характеры* һәр катнашучының абруена нигезле юнәлеш бирүне, яшь, җенес, милли, этник үзенчәлекләренә карамастан, баланың шәхесен хөрмәтләү һәм берсүзсез кабул итүне, сабыйга, аның халәтенә, кәефенә, ихтыяҗларына, мәнфәгатьләренә уңай һәм игътибарлы карашны күз алдында тота. Шәхси-үстерешле үзара мөнәсәбәт Оешмада бала үсешенең социаль хәленең аерылгысыз өлеше, аның эмоциональ иминлеге һәм тулы кыйммәтле үсеше өчен шарт булып тора;

• *балалар һәм өлкәннәр арасында хезмәттәшлек һәм үзара ярдәм, баланы белем бирү мөнәсәбәтләрендә тулы хокуклы катнашучы (субъект) дип тану* өлкән кеше белән баланың партнёрлык мөнәсәбәтләрен, белем бирү процессында катнашучылар арасында диалогик аралашу характерын күздә тота, балаларга үз мөнәсәбәтен, фикерен, карашларын белдерергә, якларга, карарлар кабул итәргә, мөмкинчелекләреннән чыгып, җаваплылыкны үз өстенә алырга мөмкинлек бирә;

• *Оешманың гаилә белән хезмәттәшлеге* гаиләгә карата ачыклыкны, гаилә кыйммәтләрен һәм гореф-гадәтләрен хөрмәт итүне, аларның белем бирү эшчәнлегендә исәпкә алынуын күздә тота. Эчтәлек һәм оештыру мәсьәләләрендә гаилә белән хезмәттәшлекнең төрле формалары каралган. Оешма хезмәткәрләре гаиләдә баланың тормыш шартлары турында белергә, проблемаларын аңларга, тәрбияләнүчеләрнең гаилә кыйммәтләрен һәм традицияләрен хөрмәт итәргә тиеш;

• *оешмалар белән челтәрле үзара аралашу* балаларның гаиләләре белән генә түгел, ә аларның социаль һәм мәдәни тәҗрибәсен баетуга, аларда милли гореф-гадәтләр, туган

шәһәрнең (авылның) барлыкка килү тарихы һәм үсеше, туган як табигате белән кызыксыну уятуга, танып белү проектлары, акцияләр, экскурсияләр, милли бәйрәмнәр уздыруга, балаларның курчак театры, күргәзмә, музейларга йөрүенә, шулай ук аларның аерым ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә ярдәм итә ала торган башка оешмалар һәм аерым затлар белән дә партнёрлык мөнәсәбәтләре урнаштыруын күздә тота;

• *белем бирүне индивидуальләштерү* белем бирү эшчәнлеген индивидуальләштерү, һәр баланың шәхси үсеш траекториясен чагылдыру, аның мәнфәгатьләрен, мотивларын, сәләтләрен, бу балага хас үсеш үзенчәлекләрен һәм үсеш тизлеген исәпкә алу мөмкинлекләрен ача торган белем бирү эшчәнлеген төзүне күздә тота. Бер үк яшьтәге балаларның сөйләм үсешендәге индивидуаль аермалыклар зур булу сәбәпле, аларның шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алу зарур. Киләсе үсеш этабына күчү алдагыларын тәмамлау түгел, ә аларны алга таба интенсивлаштыру һәм катлауландыру дигән сүз. Шул ук вакытта бала үзе дә белем бирү эчтәлеген, активлык формаларын сайлап алуда актив катнаша;

• *белем бирүнең яшь адекватлыгы* педагог тарафыннан төбәк һәм муниципаль үзенчәлекләрне, балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән метод һәм чараларны исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү эчтәлеген сайлап алуны күз алдында тота;

• *үстерешле вариатив белем бирү* баланың актуаль һәм потенциаль мөмкинлекләрен, мәнфәгатьләрен, мотивларын һәм сәләтләрен исәпкә алып, балалар эшчәнлеге һәм активлыгының төрле төрләре аша балага мәктәпкәчә белем бирү эчтәлеген тәкъдим итүне күзаллый. Әлеге принцип педагогның бала белән якын үсеш зонасына ориентлашкан эшен күз алдында тота (Л.С. Выготский);

• *аерым белем бирү өлкәләре эчтәлегенең тулылыгы һәм интеграциясе* балаларда иҗтимагый чынбарлыкны аңлауның диалектик нигезләре барлыкка килүне, төрле белем бирү өлкәләрендә (иҗтимагый-коммуникатив, танып белү, сөйләм, сәнгати-эстетик, физик үсеш) этнокультура юнәлешен карау мөмкинлеген һәм аны балалар эшчәнлегенең төрле төрләрендә һәм активлыгында тормышка ашыруны күздә тота;

• *куелган максатларга ирешү һәм аларны тормышка ашыру чараларының вариативлыгы булганда, кыйммәтләрнең һәм максатларның инвариантлыгы* Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандартының һәм Федераль белем бирү программасының инвариант кыйммәтләрен һәм ориентирларын билгеләвен күз уңында тота. Оешма үзенең төп белем бирү программасын шуларны исәпкә алып эшләргә тиеш. Шул ук вакытта Оешмага, төбәкнең конкрет социомәдәни, география, климат үзенчәлекләрен, тәрбияләнүчеләрнең төрлелеген, аларның үзенчәлекләрен һәм мәнфәгатьләрен, ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) теләкләрен, педагогларның мәнфәгатьләрен һәм өстенлекләрен исәпкә алып, Программаның вариатив өлешен, аны тормышка ашыруның форма, ысул һәм чараларын эшләү, куелган максатларга ирешү юлларын сайлау хокукы бирелә;

• *мәдәниятка ярашлылык һәм төбәкчелек* милли мәдәният һәм бу төбәктә яшәүче халыкларның мәдәнияте нигезендә бала үзаңының төрле өлкәләре формалашуны, ул халыкларның милли кыйммәтләренә ихтирамлы мөнәсәбәтне, төбәкнең тарихи-географик, этник һәм туган якны өйрәнүгә бәйле үзенчәлекләрен, социомәдәни чынбарлыкны танып белүне тәэмин итә.

## 1.2. ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘР

Мәктәпкәчә мәгарифнең Федераль дәүләт белем бирү стандартлары һәм Федераль белем бирү программасы буенча, мәктәпкәчә балачак спецификасы һәм мәктәпкәчә белем бирүнең системалы үзенчәлекләре мәктәпкәчә яшьтәге баладан белем бирүдә конкрет казанышлар таләп итүне законга каршы килә дип билгели. Шуңа күрә программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре мәктәпкәчә яшьтәге балаларның төрле яшь этапларында бала ирешергә мөмкин булган казанышларны яшь ягыннан тасвирлаудан гыйбарәт.

Тормыш шартларының төрлелеге һәм конкрет баланың шәхси үсешендәге үзенчәлекләре аркасында, яшь характеристикаларының реаль үсеш дәрәҗәсе һәм балаларның аларны күрсәтә белү сәләте шактый төрле булырга мөмкин.

**Программаны үзләштерү нәтиҗәләре буенча**
***өч яшьлек бала:***

• өлкәннәр белән кызыксынуын сиздерә, аларга ышаныч белдерә, туган (татар) телендә аралашуга актив кушылып китә;

• гаилә кыйммәтләрен таный, үзенең гаилә әгъзаларын атый, исемнәрен әйтә ала;

• яшьтәшләре белән кызыксына, аларның гамәлләрен күзәтә, аларга охшарга тырыша;

• сюжетлы-сурәтләү уенында рольләрне бүләргә омтылыш ясый, аларның берсен үзенә ала, уен хәрәкәтләрен, андагы гамәлләрне, сүзләрне кабатларга мөмкин;

• әйләнә-тирәдәге предметлар белән кызыксына, өйрәнү-тикшерену активлыгын белдерә, предметларның социаль билгеләнешенә ярашлы рәвештә, алар белән аңлап эш итә;

• күзәтә, «бу кем?», «нәрсә ул?», «нишли?» кебек сораулар бирә һәм аларга җавап көтә;

• туган ягының тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кызыксына, табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында күзаллый;

• өлкән кешенең сүзен аңлый, ул кушканнарны үти, үтенечен башкара;

• төп грамматик категорияләрне һәм сөйләм теле сүзлеген кулланып, туган (татар) телен үзләштерә;

• китаплар белән кызыксына, гади татар халык әкиятләрен, кыска шигырьләрне, аерым сүзләр, сүтезмәләр, эш-гамәлләр кертү юлы белән өлкәннәр сөйләгәнне, беренче татар халык әкиятләрен, кыска шигырьләрне истә калдыруын күрсәтә;

• бик гади сурәтләр ясый, нәрсә килеп чыкканын әйтеп бирә;

• балчык, пластилин кулланып, җәю, кисәкләрне өзү, тоташтыру, формасын үзгәртү ысулларын үзләштерә;

• музыканы эмоциональ кабул итә, бик теләп хәрәкәтләнә, татар композиторларының әсәрләрен тыңлый;

• охшату-кабатлау характерындагы хәрәкәтләрне бик теләп башкара, өлкән кеше оештырган сюжетлы хәрәкәтле уеннарда катнаша;

• шәхси гигиена әйберләренең (кулъяулык, тарак, теш щёткасы һ.б.) ни өчен кулланылганын белә һәм алардан файдалана ала;

***дүрт яшьлек бала:***

• үзе, гаилә әгъзалары турында башлангыч күзаллауларга ия, үзләре яши торган адресны, үз исемен һәм фамилиясен, якыннарының исемнәрен белә, аларга ихтирам белән карый;

• табигать һәм социаль дөнья, балалар бакчасындагы, туган шәһәрендәге (авылындагы) вакыйгалар турында күптөрле мәгълүмат чыганагы буларак, өлкән кеше белән аралашуга ихтыяҗ тоя;

• туган (татар) телендә иркен сөйләшә, аралашуда инициатива белдерә, яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән әңгәмәдә катнаша, үз хисләрен, теләкләрен белдерә;

• әңгәмәдәшенең нинди милләттән булуына карамастан, үзе белеп исәнләшә, хушлаша, сый өчен рәхмәт әйтә;

• үзешчән уенда татар халкының көнкүрешен чагылдырган предметлы уен мохитен мөстәкыйль оештыра: милли кием, зәркән бизәнү әйберләреннән, көнкүреш предметларыннан (кәрзин, сөлге, ашъяулык һ.б.), савыт-сабадан (агач кашык, самавыр һ.б.), шартлы алмаш предметлардан файдалана;

• әйләнә-тирәдә (шәһәр яки бистә инфраструктурасының төп объектларында) ориентлаша, әйләнә-тирә мохит предметлары, аларның ни өчен кулланылуы турында күзаллауларга ия;

• милли мәдәниятнең кайбер атрибутлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли кухня, кием-салым, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, кече фольклор формалары) турында башлангыч күзаллауларга ия;

• туган шәһәрен (авылын, бистәсен), үзе яши торган урамны атый;

• туган як табигатенең кыйммәтләрен таный, туган ягындагы тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кызыксына, аларга карата сакчыл мөнәсәбәт күрсәтә;

• табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр, йорт хайваннары һәм кыргый хайваннар турында күзаллауларга ия;

• үз җирлегендәге транспорт чараларын аера, юлда үз-үзеңне тотуның төп кагыйдәләрен белә;

• әти-әнисенең кайда эшләве турында мәгълүматы бар, берничә һөнәр төрен атый ала;

• туган (татар) телендә иркен сөйләшә, өлкәннәр белән аралашуда инициатива белдерә, әңгәмә темасын дәвам итә ала, сорауларга җавап бирә;

• татар халык әкиятләрен, татар язучылары һәм шагыйрьләренең әдәби әсәрләрен тыңлаганда, уңай хисләр кичерә;

• китаплар, иллюстрация материаллары белән кызыксына, әдәби әсәрләрнең геройларын белә, аларны атый ала, эш-гамәлләргә бәя бирә ала;

• үз теләге белән кыска шигырьләр, кече фольклор жанрларын истә калдыра һәм кабатлап сөйли;

• татар милли киемендәге курчаклар белән кызыксына;

• халык музыка уен коралларында уйнауны бик теләп тыңлый, татар композиторларының музыкаль әсәрләрен, халык җырларын эмоциональ кабул итә;

• этюдларны сәхнәләштерүгә, такмазаларны уйнап башкаруга, биюләргә кушылып китә, бәйрәмнәрдә катнаша;

• алган тәэсирләрен уен, рәсем ясау, музыка һ.б. кебек махсус оештырылган эшчәнлектә чагылдыра;

• шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәргә тырыша;

• татар халык уеннарында кагыйдәләрне үзләштерергә һәм үтәргә тырыша;

***биш яшьлек бала:***

• үзе, гаиләсе (составы, милләте, гаиләдәге тәртип кагыйдәләре, мавыгу, кызыксынулары), гаилә әгъзаларына кайгыртучан мөнәсәбәт кирәклеге турында күзаллауларга ия;

• табигать һәм социаль дөнья, балалар бакчасындагы, туган шәһәрендәге (авылындагы), республикадагы вакыйгалар турында күптөрле мәгълүмат чыганагы буларак, өлкән кеше белән аралашуга ихтыяҗ тоя;

• туган (татар) телендә иркен сөйләшә, аралашуда инициатива күрсәтә, өлкәннәр белән аралашканда сөйләшү темасыннан читкә китми, сорауларга җавап бирә һәм үтенечне игътибар-

сыз калдырмый, яшьтәшләре белән ныклы элемтәләр урнаштырырга сәләтле, уртак тел таба белә;

• элементар аралашу культурасына ия, өлкән кеше исенә төшермичә дә, әңгәмәдәшенең милләтенә карап, шул телдә сәлам бирә һәм хушлаша, күрсәтелгән хезмәт, ярдәм, сый өчен рәхмәт әйтә, кирәк очракта гафу үтенә;

• яшьтәшләре белән дуслыкның, дустанә мөнәсәбәтләрнең кыйммәтен таный, балалар белән, шул исәптән башка милләт балалары белән дуслаша һәм аралаша;

• башка телдә сөйләшүче кешеләрнең мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән кызыксына, аларның әңгәмәсенә колак сала, рус телендә башлангыч дәрәҗәдә аралаша, сөйләм теле күнекмәләрен үзләштерә;

• туган шәһәре (исеме, төп урамнары), республика (исеме, башкаласы) турында беренчел күзаллауларга ия;

• туган ягының кыйммәтләрен таный, туган җире (шәһәре, авылы) турында мәгълүмат белән кызыксына;

• милли мәдәниятнең кайбер элементлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли кухня, кием-салым, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, кече фольклор формалары) белән кызыксына;

• туган якның тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кызыксына, аларның үзара бәйләнеше, сезонлы үзгәрешләре турында кайбер күзаллаулары бар;

• Казан шәһәрендәге метрополитен, «Тукай мәйданы» станциясенең үзенчәлекләре турында күзаллауларга ия;

• өлкәннәрнең һөнәри эшчәнлеге турында күзаллаулары бар, берничә һөнәрне атарга мөмкин;

• үз җирлегендәге транспорт чараларында ориентлаша, тукталыш урыннарын, аларның исемнәрен белә, гомум кабул ителгән символик билгеләрнең мәгънәсен аңлый;

• таныш булмаган шартларда сакланучан, алдын-артын уйлап эш итә, имгәнү-җәрәхәтләнүләрдән саклана (таныш булмаган кеше белән аралашмый, хайваннарның үз-үзләрен ничек тотачагын белеп булмаганын аңлый һ.б.);

• туган (татар) телен таный, аның белән даими кызыксына, телгә җиңел өйрәнә;

• телне сиземли, тел күренешләре белән кызыксына һәм аларны үзара чагыштыра, татар телен үзләштерүгә омтылышы бар;

• үзенә эндәшүләрен аңлый, аралашу ситуациясенә туры килгән репликалар кулланып, мөрәҗәгатькә дөрес җавап бирә;

• өлкәннәр белән үзе өчен гадәти әйләнә-тирә мохиткә карамаган предмет, күренеш, вакыйгалар турында әңгәмә кора ала;

• яшьтәшләре белән туган (татар) телендә җылы аралаша;

• «Татармультфильм» берләшмәсенең мультфильмнарын, балалар өчен татар телендә теле-тапшыруларны («Кучтәнәч») бик теләп карый, җырлар тыңлый;

• татар халык әкиятләре геройларына карата борчылуын, теләктәшлеген белдерә, үзенең һәм яшьтәшләренең тәртибен бәяләгәндә, шул геройларга ориентлаша;

• татар милли киемен башка халыкларның киемнәреннән аера белә;

• татар бизәгендәге чәчәк-үсемлек мотивлары турында күзаллаулары бар, декоратив бизәк ясауның иң гади техникасын белә, милли бизәк элементларын мөстәкыйль иҗади эшчәнлектә куллана;

• халык музыка уен коралларында уйнауны бик теләп тыңлый, татар композиторларының музыка әсәрләрен, халык җырларын эмоциональ кабул итә;

• татар халык бәйрәмнәрендә бик теләп катнаша, татар җыр-биюләрен башкара;

• алынган мәгълүматны үз инициативасы һәм өлкән кеше инициативасы белән төрле эшчәнлек төрләрендә (коммуникатив, уен, танып белү-тикшеренү эшчәнлекләре), шулай ук активлыкның төрле төрләрендә (матур әдәбиятны һәм фольклорны кабул итү, музыка, сурәтләү, конструкцияләү һ.б.) куллана;

• шәхси гигиена кагыйдәләрен үти;

• сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре турында башлангыч күзаллауларга ия;

• татар халык уеннарында кагыйдәләрне үти;

***алты яшьлек бала:***

• үзен гаиләсе, җенесе, милләте вәкилләре белән дөрес тәңгәлләштерә, гаилә әгъзаларының иҗтимагый функцияләрен аңлый, ерак һәм якын туганнар, алар арасындагы туганлык бәйләнешләре, нәсел намусын саклау турында күзаллый, гаилә һәм нәсел кыйммәтләрен таный;

• гаилә эшләре белән кызыксына, алда торган эшләр турында бергәләп фикер алышуда катнашырга омтыла;

• табигать һәм социаль дөнья, туган шәһәрендәге (авылындагы), республикадагы, илнең бер төбәгендәге вакыйгалар турында күптөрле мәгълүмат чыганагы буларак, өлкән кеше белән аралашуга ихтыяҗ тоя;

• туган (татар) телендә иркен сөйләшә, сөйләмне әңгәмә вакытында үз фикерләрен, хис-тойгыларын һәм теләкләрен белдерү, гыйбарәләрне формалаштырып бирү өчен куллана, яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән әңгәмәгә иркен кушылып китә, уртак тел табып, килешергә сәләтле;

• татар һәм рус телләрендә сөйләшүче кешеләрнең мәдәниятенә, йолаларына, гореф-гадәтләренә карата кызыксыну һәм хөрмәт белдерә, аралашуга ихтыяҗ тоя;

• хезмәтнең кыйммәтен таный, яфраклар коелгач, участокны җыештыру, шәһәрдә яши торган кошларны ашату кебек коллектив хезмәткә булышлык күрсәтә, экологик акцияләрдә катнаша;

• туган ягының тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кызыксына, аларның үзара бәйләнеше, сезонлы үзгәрешләр турында күзаллаулары бар, әйләнә-тирә табигатькә сакчыл карый;

• табигатьтән дөрес файдалану күнекмәләре бар (дару үләннәрен тамыры белән йолкып алмау, сулыкларны чисталыкта тоту һ.б.);

• Казанның республика башкаласы, бөтен дөнья татарлары башкаласы икәнлеген күзаллый;

• республиканың, аның башкаласының символикасын ялгышмыйча танып ала һәм әйтеп бирә;

• Казан шәһәренең метрополитен станцияләре, аларның үзенчәлекләре, исемнәренең тарихы турында күзаллый;

• туган шәһәренең (авылының) мәдәни байлыгы, төп тарихи вакыйгалары, истәлекле урыннары турында башлангыч күзаллаулары бар, андагы урам атамаларының тарихы белән кызыксына;

• милли мәдәният кыйммәтләрен таный, милли мәдәният атрибутлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли кухня, кием-салым, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, кече фольклор формалары) белән кызыксына, сораулар бирә;

• башка милләт вәкилләренең мәдәнияте белән кызыксына, җылы мөнәсәбәтен һәм хөрмәтен белдерә, башка милләт вәкилләре белән аралашырга омтыла;

• Татарстан Республикасының күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең тормышы һәм иҗаты турында кызыксынып тыңлый, аларның исемнәрен әйтеп бирә ала;

• туган ягын ярата, авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәткәрләренең һөнәри эшчәнлеге турында белемнәргә ия, берничә һөнәрне атый ала;

• үз җирлегендәге транспорт чараларында һәм аларның маршрутларында ориентлаша, гомум кабул ителгән символик билгеләрнең мәгънәсен аңлый, урамда һәм җәмәгать транспортында куркынычсызлык кагыйдәләрен үти;

• үз фикерләре, тәэсирләре, белемнәре белән уртаклаша;

• сыйфатка исемнәр, охшаш һәм капма-каршы мәгънәле сүзләр сайлый;

• туган (татар) телнең барлык авазларын дөрес, сүз һәм гыйбарәләрне анык һәм аңлаешлы итеп әйтә белә;

• сүздә авазның урынын (башта, уртада, ахырда) билгели; сүз басымын аера һәм аның сүздәге урынын ачыклый;

• сүзләрне, сүзтезмәләрне татар теленнән русчага тәрҗемә итә;

• «Татармультфильм» берләшмәсе мультфильмнарын, «Шаян ТВ» балалар телеканалы тапшыруларын бик теләп карый, тавышлы модульле китаплар, татар җырларын тыңлый;

• табигый аралашу шартларында рус һәм татар телләрендә сөйләшә, инициатива һәм сөйләм активлыгы күрсәтә;

• дидактик (лексик) уен биременең нәтиҗәсенә ирешергә омтыла;

• фольклор әсәрләренең һәркемгә аңлаешлы теле белән татар халык әкиятләрен сөйли белә, табышмаклар, мәкальләр, әйтемнәрне урынлы куллана ала;

• үз сөйләмен үстерү мөмкинлекләре белән кызыксына;

• Татарстан Республикасының күренекле сынлы сәнгать әсәрләре белән кызыксына, сәнгать турында башлангыч белемнәргә ия;

• рус милли киеменең үзенчәлекләре турында белә;

• туган шәһәренең (район үзәге, бистә, авылының) кайбер архитектура корылмалары турында күзаллаулары бар;

• татар милли бизәге элементларын аера ала, декоратив бизәк ясау техникасын белә, өс киеме, аяк киеме, баш киемнәре силуэтларында милли бизәк элементларын куллана;

• рельефлы сурәт ясау техникасын, көнкүреш әйберләрен милли рухта бизәү өчен, өзү-ерту һәм күләмле аппликация ысулларын белә;

• аппликациядә, әвәләп ясаганда, рәсем ясаганда татар халык әкиятләре мотивлары буенча сюжетларны сурәтли;

• халык музыкасын, татар композиторларының музыка әсәрләрен бик теләп тыңлый, аларны эмоциональ кабул итә;

• ТР Дәүләт гимны башкарылуын таный, кушылып җырларга тырыша;

• татар җыр-биюләрен бик теләп башкара, татар халык бәйрәмнәрендә катнаша, әйлән-бәйлән уеннарында уйный;

• алынган мәгълүматны өлкәннәр һәм үзенең инициативасы белән эшчәнлекнең төрле төрләрендә (коммуникатив, уен, танып белү-тикшеренү эшчәнлеге), шулай ук активлыкның төрле төрләрендә (матур әдәбиятны һәм фольклорны кабул итү, музыка, сурәтләү, конструкцияләү һ.б.) куллана;

• сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре турында күзаллаулары бар;

• гәүдә төзелеше һәм физик мөмкинлекләре турында башлангыч күзаллауларга ия;

• спортның кайбер җәйге төрләре, 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына төзелгән спорт комплекслары, 2015 елда узган су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты, 2018 елда узган футбол буенча дөнья чемпионаты, 2019 елда узган нәфис гимнастика буенча дөнья кубогы этабы, 2022 елда булган спорт гимнастикасы буенча Россия чемпионаты, башка халыкара һәм Россия күләмендәге спорт ярышлары турында күзаллый;

• хәрәкәтчән, төп хәрәкәтләрне ясый белә, үз хәрәкәтләрен контрольдә тотарга, алар белән идарә итәргә тырыша;

• хәрәкәтле милли уеннарда, ярышлы уеннарда бик теләп катнаша;

**Программаны үзләштерүнең соңгы этабында (мәктәпкәчә яшь ахырына) бала:**

• үз гаиләсенең тарихы һәм культурасы белән кызыксына;

• гаиләдә кабул ителгән кагыйдәләрне үти, гаилә традицияләрен саклый, гаилә тантаналарында, бәйрәмнәрдә, алда торган эшләр һәм чыгымнар турында бергәләп фикер алышуларда теләп катнаша; гаилә әгъзалары белән туган (татар) телендә аралашырга тырыша;

• гомумкешелек мәдәнияте кыйммәтләрен таный, әйләнә-тирәдәгеләргә уңай караштa, кешеләргә (аларның социаль чыгышына, расасына, теленә, диненә, җенесенә һәм яшенә карамастан) ихтирамлы мөнәсәбәттә, башка кешеләрнең хисләренә, фикерләренә, теләкләренә, карашларына хөрмәт күрсәтә, үзенең килешмәвен дәлилли, ышандыра белә һ.б. Төрле ил һәм этнос кешеләре белән уңай рухта аралашуның, хезмәттәшлек итүнең әһәмиятен аңлатып бирә;

• табигать һәм социаль дөнья, дөньякүләм вакыйгалар, илдәге, республикадагы, туган шәһәрендәге (район үзәгендәге, авылындагы) вакыйгалар турында күптөрле мәгълүмат чыганагы буларак, өлкән кеше белән аралашуга ихтыяҗ тоя;

• коммуникатив сәләтләре күренә, сөйләмне аңлый, аралашу шартларына яраклаша, әңгәмәдәшенең социаль ролен исәпкә алып, татар һәм рус телләрендә аралаша;

• үзен туган шәһәренең (авылының), республикасының, иленең гражданы итеп тоя;

• шәһәр, республика, дәүләт символикасына (флаг, герб, гимн) ихтирамлы мөнәсәбәттә;

• Идел буе халыклары мәдәниятенең аерым элементлары (тел, кием, сәнгать, гореф-гадәтләр, милли кухня, уеннар, уенчыклар), кешеләр арасында милли һәм этник аермалыклар турында күзаллауларга ия;

• башка милләт вәкилләренең мәдәнияте белән кызыксынуын һәм ихтирамлы мөнәсәбәтен ачык белдерә, алар белән аралашырга омтыла;

• төбәктәге эре шәһәрләрнең мәдәни байлыгы, төп тарихи вакыйгалары, истәлекле урыннары, символикасы турында беренчел күзаллаулары бар, әлеге шәһәр исемнәренең килеп чыгышы белән кызыксына;

• ТР Кызыл китабына кертелгән, дәүләт тыюлыкларында яшәүче хайваннар, республиканың елга-күлләрендә яшәүче тереклек ияләре белән кызыксына, табигатьне сакларга кирәклеген аңлый;

• Ватан кыйммәтләрен таный, Россия турында туган иле буларак күзаллый, дәүләт символикасын (флаг, герб, гимн) белә һәм хатасыз әйтеп бирә ала;

• татар һәм рус халыклары мәдәниятләренең үзара бәйләнешен аңлый;

• Россиянең бер өлеше буларак, туган ягы, туган шәһәре тарихы, анда яшәүче күренекле кешеләр, төп истәлекле урыннар, гореф-гадәтләр, кешеләрнең хезмәте турында күзаллауларга ия;

• Татарстан тарихы һәм аның башкаласының төп истәлекле урыннарына бәйле мәсьәләләрдә кызыксынучанлык күрсәтә;

• музыка һәм театр сәнгате, күренекле фән эшлеклеләренең тормышы һәм иҗаты турында кызыксынып тыңлый, аларның исемнәрен әйтеп бирә ала, аларга хөрмәт белән карый;

• Бөек Ватан сугышында катнашучыларга рәхмәт һәм хөрмәт белән карый, сугыш геройларының батырлыклары турында белә;

• әхлакый-этик, милли, хокукый мәдәнияттә кабул ителгән үзеңне имин тоту кагыйдәләрен белә, аларны аңлы рәвештә үти;

• җөмләләрне татар теленнән русчага тәрҗемә итә ала;

• исемгә сыйфатлар, охшаш һәм капма-каршы мәгънәле сүзләр сайлый;

• табышмаклар, әкиятләр иҗат итә, үзе турында, бер зат сурәтләнгән ситуатив рәсемнәр сериясе, сюжетлы рәсемнәр, репродукция, шәхси күзәтүләр нигезендә зур булмаган (3–8 җөмләлек) хикәяләр төзи;

• сүзләрдәге авазларга анализ ясый, хәрефләрне таный, иҗекләрне һәм кыска сүзләрне укырга тырыша;

• ТР рәссамнары картиналарын караганда сораулар бирә, үз фикерләрен монолог формасында әйтеп бирә;

• татар язучыларының әдәби әсәрләрен озаклап тыңларга, аерым этюдларын кабат сөйләп чыгарга, аларның гомуми эчтәлеген әйтеп бирергә сәләтле, сәхнәләштерүләрдә катнаша;

• дидактик (лексик) уен биременең нәтиҗәсенә ирешә;

• аралашу шартларына карап ориентлаша һәм яңа шартларда, тиешле сүзләр һәм грамматик чараларны сайлап алып, мөстәкыйль рәвештә хәл итә ала;

• реаль тел мохитендә, рус (татар) телен чикле дәрәҗәдә белгән хәлдә дә, коммуникатив максатка ирешә;

• татар телен алга таба тагын да аңлабрак өйрәнүгә кызыксыну тоя;

• татар халкының әдәби мирасы белән даими кызыксына, әлеге белемнәрен үзенчәлекле эш төрләрендә, көндәлек аралашуда, конкурсларда файдалануга өстенлек бирә;

• милли мәдәниятне үстерүдә кешенең ролен аңлый, кеше эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак, мәдәният элементларына карата кызыксыну белдерә, мәдәни мирасны баетуда (арттыруда) үзенең катнашу мөмкинлеген алдан күрә;

• ТР мәдәният эшлеклеләренең рәсем, скульптура, музыка һәм башка сәнгатькә бәйле чараларына карата кызыксыну белдерә;

• туган шәһәренең (район үзәге, бистә, авылының) архитектура корылмалары турында күзаллаулары бар;

• симметрик («тормыш агачы») һәм асимметрик букет ясау ысулларын белә;

• декор ясаганда, рельефлы сурәтләү техникасын, предметларны милли рухта бизәгәндә, симметрияле, силуэтлы, күп катламлы ысулларны, челтәрләп кисү техникасын куллана;

• татар композиторлары иҗат иткән вокаль, инструменталь, оркестр музыкасын бик теләп тыңлый;

• Россия Федерациясе Дәүләт гимны башкарылуын таный, кушылып җырларга тырыша;

• татар җыр-биюләрен, Идел буе халыкларының биюләрен матур итеп башкара, татар халык бәйрәмнәрендә бик теләп катнаша;

• алынган мәгълүматны өлкән кеше һәм үз инициативасы белән эшчәнлекнең төрле төрләрендә (коммуникатив эшчәнлек, уен, танып белү-тикшеренү эшчәнлеге), шулай ук активлыкның төрле төрләрендә (матур әдәбиятны һәм фольклорны кабул итү, музыка, сурәтләү, конструкцияләү һ.б.) куллана;

• сәламәт туклану, сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре турында күзаллаулары бар;

• гәүдәсе һәм физик мөмкинлекләре турында күзаллый ала;

• спортның кайбер төрләре, шул исәптән милли спорт төре – «бил алыш» (татарча көрәш) турында күзаллауларга ия;

• ярышлы милли уеннарда, Сабан туе бәйрәмендә бик теләп катнаша;

• хәрәкәтчән, чыдам, төп хәрәкәтләрне ясый, үз хәрәкәтләрен контрольдә тота һәм алар белән идарә итә ала.

## 1.3. ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРГӘ ИРЕШҮНЕҢ ПЕДАГОГИК ДИАГНОСТИКАСЫ

Планлаштырылган нәтиҗәләрнең педагогик диагностикасы татар телендә тәрбия һәм белем бирүче төркем балаларының эшчәнлектә алган белемнәрен, аларның мәнфәгатьләрен, нәрсәгә өстенлек бирүләрен, һәвәслекләрен, шәхси үзенчәлекләрен, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу ысулларын өйрәнүгә юнәлтелгән. Ул һәр баланың үзенчәлекләрен һәм үсеш динамикасын ачыкларга, алынган мәгълүматлар нигезендә Программа үзләштерүнең шәхси белем бирү маршрутларын төзергә, белем бирү эшчәнлеген планлаштыруга, эчтәлегенә һәм аны оештыруга вакытында үзгәрешләр кертергә мөмкинлек бирә.

Педагогик диагностика (мониторинг) ярдәмендә педагогик гамәлләрнең нәтиҗәлелеге бәяләнә. Ул, ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) теләгеннән бәйсез рәвештә, барлык төркем балалары белән үткәрелә. Аның нәтиҗәләре алга таба белем бирү эшчәнлеген оптимальләштерү яки белем бирүне индивидуальләштерү (бала үсешенең индивидуаль траекториясен төзү, аның үсеш үзенчәлекләрен профессиональ коррекцияләү) өчен файдаланылырга мөмкин.

Баланың шәхси үсешенең педагогик диагностикасы педагог тарафыннан бик үк формаль булмаган диагностик методлар: күзәтүләр, балалар белән ирекле әңгәмәләр, бала эшчәнлеге нәтиҗәләренә анализ ясау, махсус диагностик ситуацияләр нигезендә ирекле формада уздырыла. Кирәк чакта педагог махсус диагностик инструментарий куллана ала.

Педагогик диагностиканың төп методы булып күзәтү тора. Педагогик күзәтү системасы махсус инструментарий таләп итми. Бала үсешенең яшь характеристикалары күзәтү өчен ориентир булып тора. Алар тиешле белем бирү өлкәләрендә мәктәпкәчә балачакның төрле этапларында бала ирешергә мөмкин булган гомумиләштерелгән күрсәткечләр булып торалар. Эшчәнлек барышында педагог баланың үз-үзен ни дәрәҗәдә һәм никадәр еш күрсәтә алуына, мөстәкыйльлегенә һәм инициативалылыгына игътибар итә. Үз-үзен никадәр күрсәтә алуы күрсәткечнең ешлыгын һәм тотрыклылык дәрәҗәсен билгели. Эш-гамәлләрне мөстәкыйль башкару бала үсешенең актуаль һәм иң якын тирәлеген ачыкларга мөмкинлек бирә. Баланың инициативалылыгы аның субъект буларак эшчәнлегендә һәм аралашуында үз-үзен күрсәтүе турында сөйли.

Тәҗрибәле педагог кайсы баланың нормада үсүен, ә кайсының башкаларны узып китүен яки педагогик ярдәмгә, коррекция-үстерү эшчәнлегенә мохтаҗ булуын җиңел билгеләячәк.

Педагогик диагностиканы уздыру ешлыгы МББО тарафыннан билгеләнә. Баланың чынбарлыкта үз-үзен тотышы аның ирешергә мөмкин булган күрсәткечләре белән тәңгәл килә (1 нче таблица). Бала үсеше дәрәҗәсенең мөмкин булган казанышлар күрсәткечләренә туры килмәве ачыкланган очракларда, килеп чыккан проблемаларны үз вакытында коррекцияләүгә юнәлдерелгән шәхси маршрут эшләнә.

Сөйләм үсешенә педагогик диагностика ясаганчы, «сөйләмне үстерү» һәм «сөйләм үсеше» төшенчәләренең бердәй кыйммәтле булу-булмавын ачыкларга кирәк. «Сөйләмне үстерү» күнегелгәнчә тоела, әмма мәктәпкәчә белем бирү стандарты, «сөйләмне үстерү»нең әһәмиятен инкяр итмичә, «сөйләм үсеше»нә өстенлек бирә. Төркемдәге балаларның сөйләм үсеше дәрәҗәсен өйрәнеп, педагог һәр тәрбияләнүченең үз фикерләрен, хис-тойгыларын, теләкләрен белдерү өчен сөйләмне ни дәрәҗәдә куллануын, коммуникатив сәләтенең ни дәрәҗәдә үсеш алуын билгели. Сөйләм үстерү дөрес оештырылган очракта, балаларга сөйләмне генә түгел, аларның коммуникатив сәләтләрен дә уңышлы үстерергә мөмкинлек туа.

**Сөйләм осталыгына** яхшы вербаль хәтер, тел сизгерлеге, ягъни тел чараларын сайлый белү, җөмләләрне логик яктан дөрес төзү һәм әйтү, әңгәмәдәшнең сүзләренә колак салу, гомуми эрудиция кирә.

**Коммуникатив сәләтләрне** үстерүгә аралашу процессын фаразлау һәм программалаштыру, коммуникатив шартларга «керү», инициатива күрсәтү, актив аралашу, партнёрның социаль ролен исәпкә алу һәм аралашу культурасы кирә.

Баланың өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуда активлык күрсәтүе өчен кирәкле ситуацияләр тудыру сөйләм үсешенең мәҗбүри шарты булып тора. Аралашу кытлыгы булганда, баланың сөйләм үсеше бозыла. Шуңа күрә, сөйләмне үстерү буенча махсус оештырылган шөгыльләр белән генә чикләнмичә, туган (татар) телендә гадәти аралашу өчен шартлар тудыру җиңелрәк булган режим моментларында балаларның коммуникатив үсешен оештыру тәкъдим ителә. Нәтиҗәдә бала, педагог биргән сорауларга җавап биреп кенә калмыйча, «сөйләшеп килешергә, башкаларның мәнфәгатьләрен һәм хисләрен исәпкә алырга, башкаларның уңышсызлыгына көенергә һәм уңышларына сөенергә, үз хисләрен адекват рәвештә белдерергә, конфликтларны хәл итәргә тырышырга» сәләтле була.

Көндәлек тормышта, рус теле  шөгыльләре барышында, педагог «Изучаем русский язык» УМК кысаларында кайсы лексик материалның бала тарафыннан үзләштерелүен, ә кайсының үзләштерелмәвен бернинди кыенлыкларсыз бәяләргә сәләтле. Шик туган очракта тәрбияче махсус эшләнгән диагностик ситуацияләр, әңгәмәләр яисә уен биремнәре ярдәмендә балаларның башлангыч тел белемендәге казанышларын һәрвакыт ачыклый ала.

Сөйләм үсеше динамикасын күзәтеп бару өчен, педагог балалар үзләштергән дәрәҗәне билгели торган диагностика карталарын тутыра ала. Карталарны тутыру ешлыгы балаларның сөйләм үсеше динамикасы мониторингының үзе сайлап алган системасы буенча педагог тарафыннан хәл ителә. Әмма баланың сөйләм үсеше карталары гына түгел, шәхси үсешнең төрле шкалалары да, балаларның портфолиолары да белем бирү эшчәнлеге барышында педагогка баланың казанышларын теркәп куярга ярдәм итә.

Бәлки, ике типтагы карта тутыру мөмкиндер: конкрет баланың сөйләм үсеше дәрәҗәсе билгеләнә торган шәхси һәм барлык балаларның казанышлары билгеләнә торган төркем картасы. Педагогик күзәтүләрнең нәтиҗәләрен исәпкә алу педагогка балалар төркеме белән эшне оптимальләштерергә, үсешнең киләсе этабына күчәргә мөмкинлек бирәчәк. Бу алдагы этапларның тәмамлануын аңлатмый, бәлки аларны алга таба интенсивлаштыру һәм катлауландыруга этәргеч күрсәтә.

Педагогик диагностика педагогның балаларның үзара аралашуын һәм аларның актив иҗади эшчәнлеген мотивлаштыра торган үстерешле предметлы тирәлек мохитен оештыруы, индивидуаль белем бирү маршрутлары төзүе, белем бирү процессын аңлы һәм максатчан рәвештә проектлаштыруы нигезендә алынган нәтиҗәләргә анализ ясау белән төгәлләнә.

# «КУАНЫЧ» ТӨБӘКНЕҢ МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРУ ПРОГРАММАСЫН ҮЗЛӘШТЕРҮ ДӘРӘҖӘСЕ

## БЕРЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ

*1 нче таблица*

| Белем бирү өлкәсе | Югары дәрәҗә (2 балл) | Уртача дәрәҗә (1 балл) | Түбән дәрәҗә (0 балл) |
|---|---|---|---|
| **Иҗтимагый-коммуникатив үсеш** | Өлкәннәргә карата кызыксынуы сизелә, аларга ышаныч белдерә, туган (татар) телендә аралашуга актив кушылып китә | Өлкәннәргә карата кызыксынуы сизелә, аларга ышаныч белдерә, алар белән туган (татар) телендә аралашырга һәм үзара бәйләнешкә керергә омтыла | Әти-әнисеннән аерылуны авыр кичерә, барлык өлкәннәргә дә ышаныч белдерми һәм үзара бәйләнешкә керергә омтылмый |
| | Гаилә кыйммәтләрен таный, үзенең гаилә әгъзаларын атый, исемнәрен әйтә ала | Гаилә кыйммәтләрен тануы үсеш стадиясендә генә, үзенең гаилә әгъзаларын санап бирә ала | Гаилә кыйммәтләрен тануы формалашу стадиясендә, әти-әнисен (законлы вәкилләрне) санап бирә ала |
| | Яшьтәшләре белән кызыксына, аларның гамәлләрен күзәтә, аларга охшарга тырыша | Яшьтәшләре белән кызыксына, кайвакыт аларның гамәлләрен күзәтә, аларга охшарга тырыша | Яшьтәшләре белән кызыксынмый |
| | Сюжетлы-сурәтләү уенында рольләрне бүләргә омтылыш ясый, аларның берсен үзенә ала, уен хәрәкәтләрен, андагы гамәлләрне, сүзләрне кабатларга мөмкин | Сюжетлы-сурәтләү уенында үзенә роль ала, уен хәрәкәтләрен, андагы гамәлләрне, сүзләрне кабатларга мөмкин | Сурәтләү уенына хас гамәл-хәрәкәтләре күзәтелә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Танып белү үсеше** | Әйләнә-тирәдәге предметлар белән кызыксына, өйрәнү-тикшеренү активлыгын белдерә, предметларның социаль билгеләнешенә ярашлы рәвештә, алар белән аңлап эш итә | Әйләнә-тирәдәге предметлар белән кызыксына, өйрәнү-тикшеренү активлыгын белдерә, предметларның социаль билгеләнешенә ярашлы рәвештә, алар белән эш итә | Әйләнә-тирәдәге предметлар белән уйный, алар белән кулланылышларын аңламыйча эш итә |
| | Күзәтә, экспериментлар ясарга омтыла, «бу кем?», «нәрсә ул?», «нишли?» кебек сораулар бирә һәм аларга җавап көтә | Күзәтә, «бу кем?», «нәрсә ул?», «нишли?» кебек сораулар бирә һәм аларга җавап көтә | Дәшмичә генә күзәтә |
| | Туган ягының тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кызыксына, табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында кызаллый, сораулар бирә | Туган ягының тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кызыксына, табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында кызаллый | Туган ягының тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләренә карата кызыксыну белдерми |
| **Сөйләм үсеше** | Өлкән кешенең сүзен аңлый, ул кушканнарны үти, үтенечен башкара | Өлкән кешенең сүзен аңлый, аның күрсәтмәләрен, үтенечләрен үтәгәндә, игътибарын читкә юнәлтергә мөмкин | Өлкән кешенең сүзен аңлый, ләкин аның күрсәтмәләрен, үтенечләрен һәрвакытта да үтәми |
| | Төп грамматик категорияләрне һәм сөйләм теле сүзлеген кулланып, туган (татар) телен үзләштерә | Төп грамматик категорияләрне һәм сөйләм теле сүзлеген кулланып, туган (татар) телен үзләштерергә тырыша | Сөйләме пассив, туган (татар) телен начар үзләштерә |
| | Китаплар белән кызыксына, аерым сүзләр, сүзтезмәләр, эш-гамәлләр керту юлы белән өлкәннәр сөйләгән беренче татар халык әкиятләрен, кыска шигырьләрне истә калдыруын күрсәтә | Китаплар белән кызыксына, аерым сүзләр, эш-гамәлләр керту юлы белән өлкәннәр сөйләгән беренче татар халык әкиятләрен, кыска шигырьләрне истә калдыруын күрсәтә | Китап белән кызыксынуы тиз сүрелә, игътибарын читкә юнәлтә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Сәнгати-эстетик үсеш** | Бик гади сурәтләр барлыкка килә, бала нәрсә килеп чыкканын әйтеп бирә | Бик гади сурәтләр барлыкка килә | Сурәтләү чаралары кулланып, манипуляцияләр ясый, аңлаешсыз сурәтләр төшерә |
| | Балчык, пластилин кулланып, җәю, кисәкләрне өзү, тоташтыру, формасын үзгәртү ысулларын үзләштерә | Балчык, пластилин кулланып, җәю, кисәкләрне өзү, тоташтыру ысулларын үзләштерә | Сыгылмалы материалларга, аларның үзлекләренә кызыксыну белдерми |
| | Татар халык музыкасын эмоциональ кабул итә, бик теләп хәрәкәтләнә, татар композиторларының әсәрләрен тыңлый, кушылып җырлый | Татар халык музыкасын эмоциональ кабул итә, бик теләп хәрәкәтләнә, татар композиторларының әсәрләрен тыңлый | Музыкага тәэсирләнә, бик теләп хәрәкәтләнә |
| **Физик үсеш** | Охшату-кабатлау характерындагы хәрәкәтләрне бик теләп башкара, өлкән кеше оештырган сюжетлы хәрәкәтле уеннарда катнаша, уен кагыйдәләрен үти | Охшату-кабатлау характерындагы хәрәкәтләрне бик теләп башкара, өлкән кеше оештырган гади сюжетлы хәрәкәтле уеннарда катнаша | Хәрәкәтле уеннарның сюжетына катнашып китми |
| | Шәхси гигиена әйберләренең (кулъяулык, тарак, теш щёткасы һ.б.) ни өчен кулланылганын белә һәм алардан файдалана ала | Шәхси гигиена әйберләренең (кулъяулык, тарак, теш щёткасы һ.б.) ни өчен кулланылганын белә, өлкәннәр искә төшергәндә генә, алардан файдалана | Шәхси гигиена әйберләре белән (кулъяулык, тарак, теш щёткасы һ.б.) манипуляция ясый |
| Барлык белем бирү өлкәләре буенча үсеш дәрәҗәсен билгеләү педагогик диагностика нәтиҗәсендә алынган баллар суммасы нигезендә гамәлгә ашырыла: **0–6 балл** – түбән дәрәҗә, **7–24 балл** – уртача дәрәҗә, **25–30 балл** – югары дәрәҗә. | | | |

## ИКЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ

| Белем бирү өлкәсе | Югары дәрәҗә (2 балл) | Уртача дәрәҗә (1 балл) | Түбән дәрәҗә (0 балл) |
|---|---|---|---|
| **Иҗтимагый-коммуникатив үсеш** | Үзе, гаилә әгъзалары турында башлангыч күзаллауларга ия, үзләре яши торган адресны, үз исемен һәм фамилиясен, якыннарының исемнәрен белә, аларга ихтирам белән карый | Үзе, гаилә әгъзалары турында башлангыч белемнәргә өлешчә ия, үзләре яши торган адресны, үз исемен һәм фамилиясен белә, якыннарының исемнәрен бутый, аларга ихтирам белән карый | Һәрвакыт дөрес булмаса да, үзе, гаилә әгъзалары турында кайбер беренчел күзаллауларга ия, үз исемен белә, фамилиясен, үзләре яши торган адресны һәрчакта да әйтеп бирә алмый, якыннарының исемнәрен белми |
| | Табигать һәм социаль дөнья, балалар бакчасындагы, туган шәһәрендәге (авылындагы) вакыйгалар турында күптөрле мәгълүмат чыганагы буларак, өлкән кеше белән аралашуга ихтыяҗ тоя | Өлкән кеше инициативасы белән аралаша; табигать һәм социаль дөнья, балалар бакчасындагы, туган шәһәрендәге (авылындагы) вакыйгалар турында күптөрле мәгълүмат белән кайбер очракларда гына кызыксыну белдерә | Өлкәннәр белән аралашудан кача, табигать һәм социаль дөнья, балалар бакчасындагы, туган шәһәрендәге (авылындагы) вакыйгалар турында мәгълүмат белән кызыксынмый |
| | Туган (татар) телендә иркен сөйләшә, аралашуда инициатива белдерә, яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән әңгәмәдә катнаша, үз хисләрен, теләкләрен белдерә | Туган (татар) телен белә, башка кешеләр белән аралашуга омтылышы очраклы характерда | Башка кешеләр белән аралашуга омтылышы юк, бала үз эченә бикләнгән, ялгызлыкка өстенлек бирә |
| | Әңгәмәдәшенең нинди милләттән булуына карамастан, үзе белеп исәнләшә, хушлаша, сый өчен рәхмәт әйтә | Өлкән кеше исенә төшергәндә яки читләтеп әйткәндә, исәнләшә, хушлаша, сый өчен рәхмәт әйтә | Өлкәннәр кушканга исәнләшә, хушлаша, сый өчен рәхмәт әйтә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Үзешчән уенда татар халкының көнкүрешен чагылдырган предметлы уен мохитен мөстәкыйль оештыра: милли кием, зәркән бизәнү әйберләреннән, көнкүреш предметларыннан (кәрзин, сөлге, ашъяулык һ.б.), савыт-сабадан (агач кашык, самавыр һ.б.), шартлы алмаш предметлардан файдалана | Өлкән кеше җитәкчелегендә үзешчән уенда татар халкының көнкүрешен чагылдырган предметлы уен мохитен мөстәкыйль оештыра: милли кием, зәркән бизәнү әйберләреннән, көнкүреш предметларыннан (кәрзин, сөлге, ашъяулык һ.б.), савыт-сабадан (агач кашык, самавыр һ.б.), шартлы алмаш предметлардан файдалана | Өлкән кеше кушканга һәм аның җитәкчелегендә татар халкының көнкүрешен чагылдырган предметлы уен мохитен оештыра: өлкән кеше ярдәме белән милли кием, зәркән бизәнү әйберләреннән, көнкүреш предметлары (кәрзин, сөлге, ашъяулык һ.б.), савыт-сабалар (агач кашык, самавыр һ.б.) сайлый, шартлы алмаш предметлар кулланмый |
| **Танып белү үсеше** | Әйләнә-тирәдә (шәһәр яки бистә инфраструктурасының төп объектларында) ориентлаша, әйләнә-тирә мохит предметлары, аларның ни өчен кулланылуы турында күзаллауларга ия | Әйләнә-тирәдә (шәһәр яки бистә инфраструктурасының төп объектларында) кайбер шартлар булганда ориентлаша, әйләнә-тирә мохитнең кайбер предметлары, аларның ни өчен кулланылуы турында күзаллауларга ия | Әйләнә-тирәдә (шәһәр яки бистә инфраструктурасының төп объектларында) ориентлаша алмый, тирә-юньдәге предметлар турында берникадәр күзаллауга ия, аларның ни өчен кулланылуын өлешчә белә |
| | Милли мәдәниятнең кайбер атрибутлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли кухня, кием-салым, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, кече фольклор формалары) турында башлангыч күзаллауларга ия | Милли мәдәниятнең кайбер атрибутлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли кухня, кием-салым, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, кече фольклор формалары) турында башлангыч күзаллауларга өлешчә ия | Милли мәдәниятнең аерым атрибутлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли кухня, кием-салым, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, кече фольклор формалары) турында кайчак дөрес булмаган кайбер күзаллауларга ия |
| | Туган шәһәрен (авылын, бистәсен), үзе яши торган урамны атый | Туган шәһәрен (авылын, бистәсен) атый ала, үзе яши торган урамны атаганда кыенлык тоя | Туган шәһәрен (авылын, бистәсен), үзе яши торган урамны әйтеп бирә алмый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Туган як табигатенең кыйммәтләрен таный, туган ягындагы тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кызыксына, аларга карата сакчыл мөнәсәбәт күрсәтә | Туган як табигатенең кыйммәтләрен тану үсеш стадиясендә, кайбер очракта туган ягындагы тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кызыксына, аларга карата сакчыл мөнәсәбәт күрсәтә | Туган як табигатенең кыйммәтләрен тану формалашу стадиясендә, туган ягындагы тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән бик үк кызыксынмый, аларга сакчыл карарга тырышмый |
| | Табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр, йорт хайваннары һәм кыргый хайваннар турында күзаллауларга ия | Табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр, кайбер йорт хайваннары һәм кыргый хайваннар турында күзаллауларга ия | Табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр, йорт хайваннары һәм кыргый хайваннар турында күзаллаулары юк |
| | Үз җирлегендәге транспорт чараларын аера, юлда үз-үзеңне тотуның төп кагыйдәләрен белә | Үз җирлегендәге транспорт чараларын кайбер очракларда аера, юлда үз-үзеңне тотуның төп кагыйдәләрен белә | Үз җирлегендәге транспорт чараларын аермый, юлда үз-үзеңне тотуның төп кагыйдәләрен белми |
| | Әти-әнисенең кайда эшләве турында мәгълүматы бар, берничә һөнәр төрен атый ала | Әти-әнисенең кайда эшләве турында тулысынча хәбәрдар түгел, берничә һөнәр төрен атый ала | Әти-әнисенең кайда эшләвен белми, һөнәр төрләрен әйтеп бирә алмый |
| **Сөйләм үсеше** | Туган (татар) телендә иркен сөйләшә, өлкәннәр белән аралашуда инициатива белдерә, әңгәмә темасын дәвам итә ала, сорауларга җавап бирә | Туган (татар) телен белә, өлкән кеше инициативасы белән аралаша, әңгәмә темасын дәвам итә ала, сорауларга җавап бирә | Туган (татар) телен аңлый, бу телдә начар сөйләшә, өлкәннәр белән аралашудан кача, әңгәмә темасын дәвам итә алмый, сорауларга җавап бирә |
| | Татар халык әкиятләрен, татар язучылары һәм шагыйрьләренең әдәби әсәрләрен тыңлаганда, уңай хисләр кичерә | Татар халык әкиятләрен, татар язучыларының һәм шагыйрьләренең әдәби әсәрләрен тыңлаганда уңай хис-тойгылар уянуына өлкән кеше этәргеч бирә | Татар халык әкиятләрендәге, татар язучыларының һәм шагыйрьләренең әдәби әсәрләрендәге геройларның төрле эмоциональ халәтләренә адекват булмаган мөнәсәбәт белдерә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Китаплар, иллюстрация материаллары белән кызыксына, әдәби әсәрләрнең геройларын белә, аларны атый ала, эш-гамәлләргә бәя бирә ала | Кайвакыт китаплар, иллюстрация материаллары белән кызыксына, әдәби әсәрләрнең геройларын таный, аларны атый ала | Китап, иллюстрация материаллары белән кызыксынмый, әдәби әсәрләрнең геройларын белми |
| | Үз теләге белән кыска шигырьләр, кече фольклор жанрларын истә калдыра һәм кабатлап сөйли | Өлкән кеше инициативасы белән кыска шигырьләр, кече фольклор жанрларын истә калдыра һәм кабатлап сөйли | Кыска гына шигырь юлларын, кече фольклор жанрларын истә калдыру һәм кабатлап сөйләүдә авырлык тоя |
| **Сәнгати-эстетик үсеш** | Татар милли киемендәге курчаклар белән кызыксына | Кайчагында татар милли киемендәге курчаклар белән кызыксына | Татар милли киемендәге курчаклар белән кызыксынмый |
| | Халык музыка уен коралларында уйнауны бик теләп тыңлый, татар композиторларының музыкаль әсәрләрен, халык җырларын эмоциональ кабул итә | Халык музыка уен коралларында уйнауны өлкән кеше кушканга гына тыңлый, татар композиторларының музыкаль әсәрләрен, халык җырларын тыңлаганда, ачык чагылып торган хисләр кичерми | Халык музыка уен коралларында уйнауны өлкән кеше кушканга теләмичә генә тыңлый, татар композиторларының музыкаль әсәрләрен, халык җырларын тыңлаганда, хисләр кичерми |
| | Этюдларны сәхнәләштерүгә, такмазаларны уйнап башкаруга, биюләргә кушылып китә, бәйрәмнәрдә катнаша | Өлкән кеше кушканга, этюдларны сәхнәләштерүгә, такмазаларны уйнап башкаруга, биюләргә кушылып китә, бәйрәмнәрдә катнаша | Өлкән кеше кушканга, этюдларны сәхнәләштерүгә, такмазаларны уйнап башкаруга, биюләргә теләмичә генә кушылып китә, бәйрәмнәрдә теләп катнашмый |
| | Алган тәэсирләрен уен, рәсем ясау, музыка кебек махсус оештырылган эшчәнлектә чагылдыра | Алган тәэсирләрен уен, рәсем ясау, музыка кебек махсус оештырылган эшчәнлектә тулысынча чагылдырмый | Уен, рәсем ясау, музыка кебек махсус оештырылган эшчәнлектә үзендә булган күзаллауларын чагылдыруда авырлык тоя |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Физик үсеш** | Шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәргә тырыша | Өлкәннәр исенә төшергәч кенә, шәхси гигиена кагыйдәләрен үти | Шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәми |
| | Татар халык уеннарында кагыйдәләрне үзләштерергә һәм үтәргә тырыша | Татар халык уеннары кагыйдәләрен үзләштерергә тырыша, әмма аларны һәр очракта да үтәми | Татар халык уеннары кагыйдәләрен өйрәнергә тырышмый |
| Барлык белем бирү өлкәләре буенча үсеш дәрәҗәсен билгеләү педагогик диагностика нәтиҗәсендә алынган баллар суммасы нигезендә гамәлгә ашырыла: **0–9 балл** – түбән дәрәҗә, **10–35 балл** – уртача дәрәҗә, **36–44 балл** – югары дәрәҗә. | | | |

**УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ**

| Белем бирү өлкәсе | Югары дәрәҗә (2 балл) | Уртача дәрәҗә (1 балл) | Түбән дәрәҗә (0 балл) |
|---|---|---|---|
| **Иҗтимагый-коммуникатив үсеш** | Үзе, гаиләсе (составы, милләте, гаиләдәге тәртип кагыйдәләре, мавыгу, кызыксынулары), гаилә әгъзаларына карата кайгыртучан мөнәсәбәт кирәклеге турында күзаллауларга ия | Үзе, гаиләсе (составы, милләте, гаиләдәге тәртип кагыйдәләре, мавыгу, кызыксынулары), гаилә әгъзаларына карата кайгыртучан мөнәсәбәт кирәклеге турында беренчел күзаллауларга ия | Үзе, гаиләсе (составы, милләте, гаиләдәге тәртип кагыйдәләре, мавыгу, кызыксынулары), гаилә әгъзаларына карата кайгыртучан мөнәсәбәт кирәклеге турында вакыты белән ялгыш булган кайбер күзаллауларга ия |
| | Табигать һәм социаль дөнья, балалар бакчасындагы, туган шәһәрендәге (авылындагы), республикадагы вакыйгалар турында күптөрле мәгълүмат чыганагы буларак, өлкән кеше белән аралашуга ихтыяҗ тоя | Өлкәннәр инициативасы белән әңгәмәгә кушыла, табигать һәм социаль дөнья, балалар бакчасындагы, туган шәһәрендәге (авылындагы), республикадагы вакыйгалар турында мәгълүмат белән кайбер очракларда кызыксына | Өлкәннәр белән аралашудан кача, табигать һәм социаль дөнья, балалар бакчасындагы, туган шәһәрендәге (авылындагы), республикадагы вакыйгалар турында мәгълүмат белән кызыксынмый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Туган (татар) телендә иркен сөйләшә, аралашуда инициатива күрсәтә, өлкәннәр белән аралашканда сөйләшү темасыннан читкә китми, сорауларга җавап бирә һәм үтенечне игътибарсыз калдырмый, яшьтәшләре белән ныклы элемтәләр урнаштырырга сәләтле, уртак тел таба белә | Туган (татар) телендә сөйләшә, өлкән кеше инициативасы белән башланган әңгәмәне дәвам итә, сорауларга җавап бирә, үтенечләрне тыңлый, яшьтәшләре белән ныклы элемтәләр урнаштырырга сәләтле, килешеп, уртак тел табарга тырыша | Башка кешеләр белән аралашырга омтылышы аз, сорауларга җавап бирә, үз эченә бикләнгән, ялгызлыкка өстенлек бирә |
| | Элементар аралашу культурасына ия, өлкән кеше исенә төшермичә дә, әңгәмәдәшенең милләтенә карап, шул телдә сәлам бирә һәм хушлаша, күрсәтелгән хезмәт, ярдәм, сый өчен рәхмәт әйтә, кирәк очракта гафу үтенә | Исенә төшергәндә, әңгәмәдәшенең милләтенә карап, шул телдә сәлам бирә һәм хушлаша, күрсәтелгән хезмәт, ярдәм, сый өчен рәхмәт әйтә, өлкән кеше читләтеп әйткәндә, гафу үтенә | Өлкәннәр кушканга исәнләшә, хушлаша, күрсәтелгән хезмәт, ярдәм, сый өчен рәхмәт әйтә, гафу үтенә |
| | Яшьтәшләре белән дуслыкның, дустанә мөнәсәбәтләрнең кыйммәтен таный, балалар белән, шул исәптән башка милләт балалары белән дуслаша һәм аралаша | Дуслыкның, дустанә мөнәсәбәтләрнең кыйммәтен тануы үсеш стадиясендә, балалар белән, шул исәптән башка милләт балалары белән бәхәскә керә ала, әмма каршылыкларны тыныч юл белән хәл итә | Яшьтәшләре белән дуслыкның, дустанә мөнәсәбәтләрнең кыйммәтен тану формалашу стадиясендә, балалар белән бәхәскә керә ала |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Башка телдә сөйләшүче кешеләрнең мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән кызыксына, аларның әңгәмәсенә колак сала, рус телендә башлангыч дәрәҗәдә аралаша, сөйләм теле күнекмәләрен үзләштерә | Башка телдә сөйләшүче кешеләрнең мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән кайбер очракларда кызыксына, аларның әңгәмәсенә колак сала, рус телендә башлангыч дәрәҗәдә аралашырга тырыша, беренчел дәрәҗәдәге сөйләм теле күнекмәләрен үзләштерә | Башка телдә сөйләшүче кешеләрнең мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән кызыксынмый, аларның әңгәмәсенә колак сала, рус телендә, икенче телдә беренчел сөйләм күнекмәләре юк |
| **Танып белү үсеше** | Туган шәһәре (исеме, төп урамнары), республика (исеме, башкаласы) турында беренчел күзаллауларга ия | Туган шәһәре (исеме, төп урамнары), республика (исеме, башкаласы) турында кайбер беренчел күзаллауларга ия | Туган шәһәре (исеме, төп урамнары), республика (исеме, башкаласы) турында беренчел күзаллаулары юк |
| | Туган ягының кыйммәтләрен таный, туган җире (шәһәре, авылы) турында мәгълүмат белән кызыксына | Туган ягының кыйммәтләрен тануы үсеш стадиясендә, кайбер очракларда туган җире (шәһәре, авылы) турында мәгълүмат белән кызыксына | Туган ягының кыйммәтләрен тануы формалашу стадиясендә, туган җире (шәһәре, авылы) турында мәгълүматка карата кызыксыну белдерми |
| | Милли мәдәниятнең кайбер элементлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли кухня, кием-салым, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, кече фольклор формалары) белән кызыксына | Милли мәдәниятнең кайбер элементлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли кухня, кием-салым, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, кече фольклор формалары) белән өлешчә кызыксына | Милли мәдәниятнең элементларына (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли кухня, кием-салым, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, кече фольклор формалары) карата кызыксыну белдерми |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Туган якның тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кызыксына, аларның үзара бәйләнеше, сезонлы үзгәрешләре турында кайбер күзаллаулары бар | Туган якның тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кайбер очракларда кызыксына, аларның үзара бәйләнеше, сезонлы үзгәрешләр турында кайбер күзаллаулары бар | Туган якның тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән бик үк кызыксынмый, аларның үзара бәйләнеше, сезонлы үзгәрешләр турында күзаллаулары юк |
| | Казан шәһәрендәге метрополитен, «Тукай мәйданы» станциясенең үзенчәлекләре турында күзаллаулары бар | Казан шәһәрендәге метрополитен, «Тукай мәйданы» станциясенең үзенчәлекләре турында өлешчә күзаллый | Казан шәһәрендәге метрополитен, «Тукай мәйданы» станциясенең үзенчәлекләре турында күзаллаулары юк |
| | Өлкәннәрнең һөнәри эшчәнлеге турында күзаллаулары бар, берничә һөнәрне атарга мөмкин | Өлкәннәрнең һөнәри эшчәнлеге турында үз яшенә туры килгән кадәр күзаллаулары бар, берничә һөнәрне атарга мөмкин | Өлкәннәрнең һөнәри эшчәнлегенең әһәмиятен аңламый, һөнәрләрне атый алмый |
| | Үз җирлегендәге транспорт чараларында ориентлаша, тукталыш урыннарын, аларның исемнәрен белә, гомум кабул ителгән символик билгеләрнең мәгънәсен аңлый | Үз җирлегендәге транспорт чараларында ориентлаша, тукталыш урыннарын, аларның исемнәрен белә, гомум кабул ителгән символик билгеләрне кайчак бутый | Үз җирлегендәге транспорт чараларын аермый, тукталыш урыннарын, аларның исемнәрен белми, гомум кабул ителгән символик билгеләрнең мәгънәсен аңламый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Таныш булмаган шартларда сакланучан, алдын-артын уйлап эш итә, имгәнү-җәрәхәтләнүләрдән саклана (таныш булмаган кеше белән аралашмый, хайваннарның үз-үзләрен ничек тотачагын белеп булмаганын аңлый) | Таныш булмаган шартларда кайчак саклык чаралары күрми, алдын-артын уйлап бетерми, имгәнү-җәрәхәтләнүдән сакланырга тырыша (таныш булмаган кеше белән аралашканда саклык күрсәтә, хайваннарның үз-үзләрен ничек тотачагын белеп булмаганын истә тота) | Таныш булмаган шартларда саклык чаралары күрми, алдын-артын уйламый (ышанучан, таныш булмаган кеше белән элемтәгә бик җиңел керә, хайваннарның үз-үзләрен ничек тотачагын белеп булмаганын исәпкә алмый) |
| **Сөйләм үсеше** | Туган (татар) телен таный, аның белән даими кызыксына, телгә җиңел өйрәнә | Туган (татар) телен таный, кайвакыт туган (татар) телен өйрәнүгә кызыксынуын белдерә | Туган (татар) телен өйрәнүгә кызыксынуы юк |
| | Телне сиземли, тел күренешләре белән кызыксына һәм аларны үзара чагыштыра, татар телен үзләштерүгә омтылышы бар | Телне сиземләвен һәрвакытта да белдерми, тел күренешләрен үзара чагыштыру белән бик аз кызыксына, татар телен үзләштерүгә омтылышы бар | Телне сиземләве юк, тел күренешләрен үзара чагыштыру белән бик аз кызыксына, телне өйрәнүгә теләк-омтылышы юк |
| | Үзенә эндәшүләрен аңлый, аралашу ситуациясенә туры килгән репликалар кулланып, мөрәҗәгатькә дөрес җавап бирә | Үзенә эндәшүләрен аңлый, һәрвакытта да аралашу ситуациясенә туры килгән репликалар кулланып, мөрәҗәгатькә җавап бирә алмый | Үзенә эндәшүләрен аңламый, мөрәҗәгатькә җавап бирми |
| | Өлкәннәр белән үзе өчен гадәти әйләнә-тирә мохитенә карамаган предмет, күренеш, вакыйгалар турында әңгәмә кора ала | Өлкәннәр белән кайчак үзе өчен гадәти әйләнә-тирә мохитенә карамаган предмет, күренеш, вакыйгалар турында әңгәмә кора ала | Өлкәннәр белән үзе өчен гадәти әйләнә-тирә мохитенә карамаган предмет, күренеш, вакыйгалар турында әңгәмәгә кушылмый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Яшьтәшләре белән туган (татар) телендә җылы аралаша | Яшьтәшләре белән туган (татар) телендә аралаша, бәхәскә керә ала | Яшьтәшләре белән аралашканда бәхәскә керә ала |
| | «Татармультфильм» берләшмәсенең мультфильмнарын, балалар өчен татар телендә телетапшыруларны («Күчтәнәч») бик теләп карый, җырлар тыңлый | «Татармультфильм» берләшмәсенең мультфильмнарын, балалар өчен татар телендә телетапшыруларны («Күчтәнәч») карый, җырлар тыңлый | «Татармультфильм» берләшмәсенең мультфильмнарын, балалар өчен татар телендә телетапшырулар («Күчтәнәч») карау, җырлар тыңлау белән кызыксынмый |
| | Татар халык әкиятләре геройларына карата борчылуын, теләктәшлеген белдерә, үзенең һәм яшьтәшләренең тәртибен бәяләгәндә, шул геройларга ориентлаша | Татар халык әкиятләре геройларына карата кайбер очракта борчылуын белдерә, яшьтәшләренең тәртибен бәяләгәндә, шул геройларга ориентлаша | Татар халык әкиятләре геройларына карата борчылуы, кайгыруы сизелми, яшьтәшләренең тәртибен бәяләгәндә, ул геройлар белән чагыштырмый диярлек |
| **Сәнгати-эстетик үсеш** | Татар милли киемен башка халыкларның киемнәреннән аера белә | Өлкән кеше әйтеп җибәргәндә, татар милли киеме белән башка халыклар киеме арасындагы аерманы күрсәтә ала | Татар милли киеме белән башка халыклар киеме арасындагы аерманы күрми |
| | Татар бизәгендәге чәчәк-үсемлек мотивлары турында күзаллаулары бар, декоратив бизәк ясауның иң гади техникасын белә, милли бизәк элементларын мөстәкыйль иҗади эшчәнлектә куллана | Татар бизәгендәге чәчәк-үсемлек мотивлары турында күзаллаулары бар, декоратив бизәк ясауның иң гади техникасын өлешчә белә, кайвакыт милли бизәк элементларын мөстәкыйль иҗади эшчәнлектә куллана | Татар бизәгендәге чәчәк-үсемлек мотивлары турында, декоратив бизәк ясауның иң гади техникасын белми, милли бизәк элементларын мөстәкыйль иҗади эшчәнлектә кулланмый диярлек |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Халык музыка уен коралларында уйнауны бик теләп тыңлый, татар композиторларының музыка әсәрләрен, халык җырларын эмоциональ кабул итә | Халык музыка уен коралларында уйнауны тыңлый, татар композиторларының музыка әсәрләрен, халык җырларын эмоциональ кабул итә | Халык музыка уен коралларында уйнауны теләмичә генә тыңлый, татар композиторларының музыка әсәрләрен, халык җырларын тыңлаганда, бернинди дә хисләр кичерми |
| | Бик теләп татар халык бәйрәмнәрендә катнаша, татар җыр-биюләрен башкара | Татар халык бәйрәмнәрендә катнаша, татар җыр-биюләрен башкара | Татар халык бәйрәмнәрендә катнашудан читләшә, татар җырларын, биюләрен теләмичә генә башкара |
| | Алынган мәгълүматны үз инициативасы һәм өлкән кеше инициативасы белән төрле эшчәнлек төрләрендә (коммуникатив, уен, танып белү-тикшеренү, музыка, рәсем ясау, конструкторлаштыру һ.б. эшчәнлекләр) куллана | Алынган мәгълүматны өлкән кеше инициативасы белән төрле эшчәнлек төрләрендә (коммуникатив, уен, танып белү-тикшеренү, музыка, рәсем ясау, конструкторлаштыру һ.б. эшчәнлекләр) куллана | Алынган мәгълүматны төрле эшчәнлек төрләрендә (коммуникатив, уен, танып белү-тикшеренү, музыка, рәсем ясау, конструкторлаштыру һ.б. эшчәнлекләр) куллануда кыенлык тоя |
| **Физик үсеш** | Шәхси гигиена кагыйдәләрен үти | Шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәргә тырыша | Өлкәннәр искә төшергәч, шәхси гигиена кагыйдәләрен үти |
| | Сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре турында башлангыч күзаллауларга ия | Сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре турында берникадәр башлангыч күзаллауларга ия | Сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре турында белми |
| | Татар халык уеннарында кагыйдәләрне үти | Татар халык уеннарының кагыйдәләрен үтәргә тырыша | Татар халык уеннарының кагыйдәләрен үзләштерергә тырыша, әмма аларны үтәми |

Барлык белем бирү өлкәләре буенча үсеш дәрәҗәсен билгеләү педагогик диагностика нәтиҗәсендә алынган баллар суммасы нигезендә гамәлгә ашырыла: **0–12 балл** – түбән дәрәҗә, **13–45 балл** – уртача дәрәҗә, **46–58 балл** – югары дәрәҗә.

**ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ**

| Белем бирү өлкәсе | Югары дәрәҗә (2 балл) | Уртача дәрәҗә (1 балл) | Түбән дәрәҗә (0 балл) |
|---|---|---|---|
| **Иҗтимагый-коммуникатив үсеш** | Үзен гаиләсе, җенесе, милләте вәкилләре белән дөрес тәңгәлләштерә, гаилә әгъзаларының иҗтимагый функцияләрен аңлый, ерак һәм якын туганнар, алар арасындагы туганлык бәйләнешләре, нәсел намусын саклау турында күзаллый, гаилә һәм нәсел кыйммәтләрен таный | Гаилә әгъзасы, теге яки бу җенес, милләт вәкиле буларак, үзе турында буленмәгән, дәлилләнмәгән күзаллауларга ия, гаилә әгъзаларының социаль функцияләре турында белә, якын һәм ерак туганнары арасындагы туганлык бәйләнешләрен аңлатуда кыенлык тоя | Гаилә әгъзасы, теге яки бу җенес, милләт вәкиле буларак, үзе турында башлангыч, дәлилләнмәгән күзаллауларга ия, гаилә әгъзаларының социаль функцияләре турында белә, якын һәм ерак туганнары арасындагы туганлык бәйләнешләрен аңлатканда, ялгышлык җибәрә |
| | Гаилә эшләре белән кызыксына, алда торган эшләр турында бергәләп фикер алышуда катнашырга омтыла | Кайчагында гаилә эшләре белән кызыксына, алда торган эшләр турында бергәләп фикер алышуда катнашырга омтыла | Гаилә эшләре белән сирәк кызыксына, алда торган эшләр турында бергәләп фикер алышуда катнашмый |
| | Табигать һәм социаль дөнья, туган шәһәрендәге (авылындагы), республикасындагы, илнең бер төбәгендәге вакыйгалар турында күптөрле мәгълүмат чыганагы буларак, өлкән кеше белән аралашуга ихтыяҗ тоя | Өлкәннәр инициативасы белән әңгәмәгә кушыла, табигать һәм социаль дөнья, туган шәһәрендәге (авылындагы), республикадагы, илнең бер төбәгендәге вакыйгалар турында мәгълүмат белән беркадәр кызыксына | Өлкәннәр белән аралашудан читләшә, табигать һәм социаль дөнья, туган шәһәрендәге (авылындагы), республикадагы, илнең бер төбәгендәге вакыйгалар турында мәгълүмат белән кызыксынмый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Туган (татар) телендә иркен сөйләшә, сөйләмне әңгәмә вакытында үз фикерләрен, хис-тойгыларын һәм теләкләрен белдерү, гыйбарәләрне формалаштырып бирү өчен куллана, яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән әңгәмәгә иркен кушылып китә, уртак тел табып килешергә сәләтле | Туган (татар) телен белә, сөйләмне әңгәмә вакытында үз фикерләрен, хис-тойгыларын һәм теләкләрен белдерү, гыйбарәләрне формалаштырып бирү өчен куллана, яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән әңгәмәгә кушыла, уртак тел табып килешергә сәләтле | Туган (татар) телен белә, башка кешеләр белән аралашуга кызыксыну белдерми, сорауларга җавап бирә, аз аралашучан, үз эченә бикләнгән, ялгызлыкны өстен күрә |
| | Татар һәм рус телләрендә сөйләшүче кешеләрнең мәдәниятенә, йолаларына, гореф-гадәтләренә карата кызыксыну һәм хөрмәт белдерә, аралашуга ихтыяҗ тоя | Татар һәм рус телләрендә сөйләшүче кешеләрнең мәдәниятенә, йолаларына, гореф-гадәтләренә карата күпмедер кызыксыну һәм хөрмәт белдерә, татар (рус) телен чикле күләмдә белгән хәлдә дә, аралашуга ихтыяҗ тоя | Башка милләт вәкилләренә карата битараф яисә агрессив мөнәсәбәттә, өлкәннәр һәм балалар белән аралашуга ихтыяҗ тоймый |
| | Хезмәтнең кыйммәтен таный, яфраклар коелгач, участокны җыештыру, шәһәрдә яши торган кошларны ашату кебек коллектив хезмәткә булышлык күрсәтә, экологик акцияләрдә катнаша | Хезмәт кыйммәтләрен тану үсеш стадиясендә, яфраклар коелгач, участокны җыештыру белән бәйле хезмәт йөкләмәләрен үти, үсемлекләрне карый, кошларны ашата | Хезмәт кыйммәтләрен тану формалашу стадиясендә, хезмәт йөкләмәләрен теләмичә генә үти |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Танып белү үсеше** | Туган ягының тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кызыксына, аларның үзара бәйләнеше, сезонлы үзгәрешләр турында күзаллаулары бар, әйләнә-тирә табигатькә сакчыл карый | Туган ягының кайбер тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кызыксына, аларның үзара бәйләнеше, сезонлы үзгәрешләр турында кайбер күзаллаулары бар, әйләнә-тирә табигатькә сакчыл карый | Туган ягының тере һәм терек булмаган табигать объектлары һәм күренешләре белән кызыксынмый, сезонлы үзгәрешләр арасындагы үзара бәйләнешне билгели алмый, әйләнә-тирә табигатькә карата кайгыртучанлыгы чикле |
| | Табигатьтән дөрес файдалану күнекмәләре бар (дару үләннәрен тамыры белән йолкып алмау, сулыкларны чисталыкта тоту һ.б.) | Табигать байлыкларыннан дөрес файдалану турында белә (дару үләннәрен тамыры белән йолкып алмау, сулыкларны чисталыкта тоту һ.б.) | Табигатьтән дөрес файдалану күнекмәләре юк (дару үләннәрен тамыры белән йолкып алмау, сулыкларны чисталыкта тоту һ.б.) |
| | Казанның республика башкаласы, бөтен дөнья татарлары башкаласы икәнлеген күзаллый | Казанның республика башкаласы, бөтен дөнья татарлары башкаласы икәнлеге турында күпмедер дәрәҗәдә күзаллый | Казанның республика башкаласы, бөтен дөнья татарлары башкаласы икәнлеге турында күзаллаулары чикле |
| | Республиканың, аның башкаласының символикасын ялгышмыйча танып ала һәм әйтеп бирә | Республиканың, аның башкаласының символикасын танып ала һәм әйтеп бирә | Республиканың, аның башкаласының символикасын танырга һәм әйтеп бирергә тырышмый |
| | Казан шәһәренең метрополитен станцияләре, аларның үзенчәлекләре, исемнәренең тарихы турында күзаллый | Казан шәһәренең метрополитен станцияләре, аларның үзенчәлекләре, исемнәренең тарихы турында кайбер күзаллауларга ия | Казан шәһәренең метрополитен станцияләре, аларның үзенчәлекләре, исемнәренең тарихы турында күзаллаулары юк |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Туган шәһәренең (авылының) мәдәни байлыгы, төп тарихи вакыйгалары, истәлекле урыннары турында башлангыч күзаллаулары бар, андагы урам атамаларының тарихы белән кызыксына | Туган шәһәренең (авылының) мәдәни байлыгы, төп тарихи вакыйгалары, истәлекле урыннары турында башлангыч күзаллаулары бар, андагы кайбер урам атамаларының тарихы белән кызыксына | Туган шәһәренең (авылының) мәдәни байлыгы, төп тарихи вакыйгалары, истәлекле урыннарына карата битарафлык күрсәтә, андагы урам исемнәренең тарихын белми |
| | Милли мәдәният кыйммәтләрен таный, милли мәдәният атрибутлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли кухня, кием-салым, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, кече фольклор формалары) белән кызыксына, сораулар бирә | Милли мәдәниятнең кыйммәтләрен тану үсеш стадиясендә, милли мәдәният атрибутлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли кухня, кием-салым, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, кече фольклор формалары) белән кайбер очракларда кызыксына, сораулар бирә | Милли мәдәният кыйммәтләрен тану формалашу стадиясендә, милли мәдәният атрибутлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли кухня, кием-салым, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, кече фольклор формалары) белән кызыксынмый, сораулар бирми |
| | Башка милләт вәкилләренең мәдәнияте белән кызыксына, җылы мөнәсәбәтен һәм хөрмәтен белдерә, башка милләт вәкилләре белән аралашырга омтыла | Башка милләт вәкилләренең мәдәнияте белән күпмедер кызыксына, җылы мөнәсәбәтен һәм хөрмәтен белдерә, башка милләт вәкилләре белән аралашырга омтыла | Башка милләт вәкилләренең мәдәнияте белән кызыксынмый, алар белән аралашудан читләшә |
| | Татарстан Республикасының күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең тормышы һәм иҗаты турында кызыксынып тыңлый, аларның исемнәрен әйтеп бирә ала | Татарстан Республикасының күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең тормышы һәм иҗаты турында аерып алып тыңлый, аларның исемнәрен әйтеп бирә ала | Татарстан Республикасының күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең тормышы һәм иҗаты турында мәгълүмат алу белән кызыксынмый, аларның исемнәрен әйтеп бирә алмый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Туган ягын ярата, авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәткәрләренең һөнәри эшчәнлеге турында белемнәргә ия, берничә һөнәрне атый ала | Туган якның кыйммәтен тану үсеш стадиясендә, авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәткәрләренең һөнәри эшчәнлеге турында берникадәр күзаллауларга ия, берничә һөнәрне атый ала | Туган җирнең кыйммәтен тану формалашу стадиясендә, авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәткәрләренең һөнәри эшчәнлеге турында күзаллаулары юк, һөнәр исемнәрен атый алмый |
| | Үз җирлегендәге транспорт чараларында һәм аларның маршрутларында ориентлаша, гомум кабул ителгән символик билгеләрнең мәгънәсен аңлый, урамда һәм җәмәгать транспортында куркынычсызлык кагыйдәләрен үти | Үз җирлегендәге транспорт чараларында ориентлаша, гомум кабул ителгән символик билгеләрнең мәгънәсен аңлый, урамда һәм җәмәгать транспортында куркынычсызлык кагыйдәләрен үти | Үз җирлегендәге транспорт чараларында ориентлаша алмый, тукталыш урыннарын, аларның исемнәрен белми, гомум кабул ителгән символик билгеләрнең мәгънәсен аңламый, урамда һәм җәмәгать транспортында куркынычсызлык кагыйдәләрен начар белә |
| **Сөйләм үсеше** | Үз фикерләре, тәэсирләре, белемнәре белән уртаклаша | Өлкәннәр инициативасы белән үз фикерләрен, тәэсирләрен, белемнәрен уртаклаша | Үз фикерләре, тәэсирләре, белемнәре белән уртаклашмый |
| | Сыйфатка исемнәр, охшаш һәм капма-каршы мәгънәле сүзләр сайлый | Сыйфатка исемнәр сайлый, охшаш һәм капма-каршы мәгънәле сүзләр сайлаганда, кыенлык тоя | Сыйфатка исемнәр, охшаш һәм капма-каршы мәгънәле сүзләр сайлауда кыенлык тоя |
| | Туган (татар) телнең барлык авазларын дөрес, сүз һәм гыйбарәләрне анык һәм аңлаешлы итеп әйтә белә | Туган (татар) телнең кайбер авазларын бозып әйтә, сүз һәм гыйбарәләрнең барысын да анык һәм аңлаешлы итеп әйтә белми | Туган (татар) телнең кайбер авазларын бозып, сүз һәм гыйбарәләрне аңлаешсыз итеп әйтә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Сүздә авазның урынын (башта, уртада, ахырда) билгели; сүз басымын аера һәм сүздәге урынын ачыклый | Сүздә авазның урынын (башта, уртада, ахырда) билгеләгәндә, сүз басымын аергaнда һәм сүздәге урынын ачыклаганда, ялгышлыклар җибәрә | Сүздә авазның урынын (башта, уртада, ахырда), сүз басымын һәм аның сүздәге урынын билгели алмый |
| | Сүзләрне, сүзтезмәләрне татар теленнән русчага тәрҗемә итә | Өлкәннәр әйтеп җибәргәндә, сүзләрне, сүзтезмәләрне татар теленнән русчага тәрҗемә итә ала | Сүзләрне, сүзтезмәләрне татар теленнән русчага тәрҗемә иткәндә, кыенлык тоя |
| | «Татармультфильм» берләшмәсе мультфильмнарын, «Шаян ТВ» балалар телеканалы тапшыруларын бик теләп карый, тавышлы модульле китаплар, татар җырларын тыңлый | «Татармультфильм» берләшмәсе мультфильмнарын, «Шаян ТВ» балалар телеканалының тапшыруларын карый, тавышлы модульле китаплар, татар җырларын тыңлый | «Татармультфильм» берләшмәсе мультфильмнарын, «Шаян ТВ» балалар телеканалының тапшыруларын караганда, игътибары читкә китә, тавышлы модульле китапларны, татар җырларын игътибар белән тыңламый |
| | Табигый аралашу шартларында рус һәм татар телләрендә сөйләшә, инициатива һәм сөйләм активлыгы күрсәтә | Табигый аралашу шартларында рус һәм татар телләрендә сөйләшә, ләкин инициатива һәм сөйләм активлыгы күрсәтми | Башкалар белән аралашу ихтыяҗы юк, моңа омтылмый, табигый аралашу шартларында кирәк булган очракта гына мөрәҗәгать итә, ялгызлыкны өстен күрә |
| | Дидактик (лексик) уен биременең нәтиҗәсенә ирешергә омтыла | Дидактик (лексик) уен биременең нәтиҗәсенә ирешергә тырыша, хаталар җибәрә | Дидактик (лексик) уен биременең нәтиҗәсенә ирешү белән кызыксынмый |
| | Фольклор әсәрләренең һәркемгә аңлаешлы теле белән татар халык әкиятләрен сөйли белә, табышмаклар, мәкальләр, әйтемнәрне урынлы куллана ала | Фольклор әсәрләренең һәркемгә аңлаешлы теле белән татар халык әкиятләрен сөйләргә, табышмаклар, мәкальләр, әйтемнәрне урынлы кулланырга тырыша | Фольклор әсәрләре теле белән татар халык әкиятләрен сөйләргә, сөйләмендә табышмаклар, мәкальләр, әйтемнәр кулланырга тырышмый |

| | Үз сөйләмен үстерү мөмкинлекләре белән кызыксына | Үз сөйләмен үстерү белән кызыксына | Үз сөйләмен үстерү белән кызыксынмый |
|---|---|---|---|
| **Сәнгати-эстетик үсеш** | Татарстан Республикасының күренекле сынлы сәнгать әсәрләре белән кызыксына, сәнгать турында башлангыч белемнәргә ия | Татарстан Республикасының күренекле сынлы сәнгать әсәрләренә беркадәр кызыксынуын белдерә | Татарстан Республикасының күренекле сынлы сәнгать әсәрләре белән кызыксынмый |
| | Рус милли киеменең үзенчәлекләре турында белә | Өлкән кеше бераз әйтеп җибәргәндә, рус милли киеменең аермаларын күрсәтә ала | Рус милли киеменең башка халыклар киеменнән аермасын күрми |
| | Туган шәһәренең (район үзәге, бистә, авылының) кайбер архитектура корылмалары турында күзаллаулары бар | Туган шәһәренең (район үзәге, бистә, авылының) кайбер архитектура корылмалары турында күпмедер дәрәҗәдә күзаллаулары бар | Туган шәһәренең (район үзәге, бистә, авылының) архитектура корылмалары турында күзаллаулары юк |
| | Татар милли бизәге элементларын аера ала, декоратив бизәк ясау техникасын белә, өс киеме, аяк киеме, баш киемнәре силуэтларында милли бизәк элементларын куллана | Татар милли бизәгенең кайбер элементларын аера ала, декоратив бизәк ясау техникасын өлешчә белә, өс киеме, аяк киеме, баш киемнәре силуэтларында милли бизәк элементларын куллана | Татар милли бизәге элементлары турында начар белә, декоратив бизәк ясау техникасын, өс киеме, аяк киеме, баш киемнәре силуэтларында милли бизәк элементларын кулланмый диярлек |
| | Рельефлы сурәт ясау техникасын, көнкүреш әйберләрен милли рухта бизәү өчен, өзү-ертулы һәм күләмле аппликация ысулларын белә | Рельефлы сурәт ясау техникасын, көнкүреш әйберләрен милли рухта бизәү өчен, өзү-ертулы һәм күләмле аппликация ысулларын өлешчә белә | Рельефлы сурәт ясау техникасын, көнкүреш әйберләрен милли рухта бизәү өчен өзү-ертулы һәм күләмле аппликация ысулларын белми |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Аппликациядә, әвәләп ясаганда, рәсем ясаганда, татар халык әкиятләре мотивлары буенча сюжетларны сурәтли | Аппликациядә, әвәләп ясаганда, рәсем ясаганда, татар халык әкиятләре мотивлары буенча сюжетларны кайчак сурәтли | Аппликациядә, әвәләп ясаганда, рәсем ясаганда, татар халык әкиятләре мотивлары буенча сюжетларны сурәтләми |
| | Халык музыкасын, татар композиторларының музыка әсәрләрен бик теләп тыңлый, аларны эмоциональ кабул итә | Халык музыкасын, татар композиторларының музыка әсәрләрен тыңлый, аларны эмоциональ кабул итә | Халык музыкасын, татар композиторларының музыка әсәрләрен теләмичә генә тыңлый, бернинди хисләр кичерми |
| | ТР Дәүләт гимны башкарылуын таный, кушылып җырларга тырыша | ТР Дәүләт гимны башкарылуын таный, кушылып җырларга омтылмый | ТР Дәүләт гимны башкарылуын башка музыка әсәрләре белән бутый |
| | Татар җыр-биюләрен бик теләп башкара, татар халык бәйрәмнәрендә катнаша, әйлән-бәйлән уеннарында уйный | Татар җыр-биюләрен башкара, татар халык бәйрәмнәрендә катнаша, әйлән-бәйлән уеннарында уйный | Татар халык бәйрәмнәрендә катнашмый, әйлән-бәйлән уеннарын теләмичә генә уйный, татар җыр-биюләрен башкармый |
| | Алынган мәгълүматны өлкәннәр һәм үзенең инициативасы белән эшчәнлекнең төрле төрләрендә (коммуникатив, уен, танып белү-тикшеренү, музыка, рәсем ясау, конструкцияләү һ.б. эшчәнлекләр) куллана | Алынган мәгълүматны өлкән кеше инициативасы белән эшчәнлекнең төрле төрләрендә (коммуникатив, уен, танып белү-тикшеренү, музыка, рәсем ясау, конструкцияләү һ.б.) куллана | Алынган мәгълүматны эшчәнлекнең төрле төрләрендә (коммуникатив, уен, танып белү-тикшеренү, музыка, рәсем ясау, конструкцияләү һ.б. эшчәнлекләр) чагылдыруда кыенлык тоя |
| **Физик үсеш** | Сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре турында күзаллаулары бар | Сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре турында өлешчә күзаллый | Сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре турында күзалламый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Гәүдә төзелеше һәм физик мөмкинлекләре турында башлангыч күзаллаулары бар | Гәүдә төзелеше һәм физик мөмкинлекләре турында берникадәр башлангыч күзаллаулары бар | Гәүдә төзелеше турында башлангыч күзаллаулары бар, ләкин үз физик мөмкинлекләре турында күз алдына китерә алмый |
| | Спортның кайбер җәй-ге төрләре, 2013 ел-гы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына төзелгән спорт ком-плекслары, 2015 ел-да узган су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты, 2018 елда узган футбол буенча дөнья чемпионаты, 2019 елда узган нәфис гимнастика буенча дөнья кубогы этабы, 2022 елда булган спорт гимнастикасы буенча Россия чемпионаты, башка халыкара һәм Россия күләмендәге спорт ярышлары турында күзаллый | Спортның кайбер җәйге төрләре, 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына төзелгән кайбер спорт комплекслары, төрле спорт төрләре буенча узган кайбер чемпионатлар турында күзаллый | Спортның кайбер җәй-ге төрләре, 2013 ел-гы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына төзелгән спорт комплекслары турында чикле күләмдә белә |
| | Хәрәкәтчән, төп хәрәкәтләрне ясый белә, үз хәрәкәтләрен контрольдә тотарга, алар белән идарә итәргә тырыша | Хәрәкәтчән, төп хәрәкәтләрне ясый белә, үз хәрәкәтләрен контрольдә тотарга, алар белән идарә итәргә тырыша | Аз хәрәкәтчән, төп хәрәкәтләрне начар белә, хәрәкәтләрне башкарганда, һәрчакта да контрольдә тота алмый |
| | Хәрәкәтле милли уеннарда, ярышлы уеннарда бик теләп катнаша | Хәрәкәтле милли уеннарда, ярышлы уеннарда актив катнаша | Хәрәкәтле милли уеннарда, ярышлы уеннарда активлык күрсәтми |
| Барлык белем бирү өлкәләре буенча үсеш дәрәҗәсен билгеләү диагностика нәтиҗәсендә алынган баллар суммасы нигезендә гамәлгә ашырыла: **0–17 балл** – түбән дәрәҗә, **18–66 балл** – уртача дәрәҗә, **67–84 балл** – югары дәрәҗә. | | | |

**Программаны үзләштерүнең соңгы этабында (мәктәпкәчә яшь ахырына) бала**

| Белем бирү өлкәсе | Югары дәрәҗә (2 балл) | Уртача дәрәҗә (1 балл) | Түбән дәрәҗә (0 балл) |
|---|---|---|---|
| **Иҗтимагый-коммуникатив үсеш** | Үз гаиләсенең тарихы һәм культурасы белән кызыксына | Үз гаиләсенең тарихы һәм культурасына бәйле кайбер мәгълүмат белән кызыксына | Үз гаиләсенең тарихы һәм культурасы турында мәгълүмат белән кызыксынмый |
| | Гаиләдә кабул ителгән кагыйдәләрне үти, гаилә традицияләрен саклый, гаилә тантаналарында, бәйрәмнәрдә, алда торган эшләр һәм чыгымнар турында бергәләп фикер алышуларда теләп катнаша, гаилә әгъзалары белән туган (татар) телендә аралашырга тырыша | Гаиләдә кабул ителгән кагыйдәләрне кайчак боза, гаилә традицияләрен саклый, гаилә тантаналарында, бәйрәмнәрдә, алда торган эшләр һәм чыгымнар турында бергәләп фикер алышуларда катнашырга, гаилә әгъзалары белән туган (татар) телендә аралашырга тырыша | Гаиләдә кабул ителгән кагыйдәләрне еш боза, гаилә традицияләрен сакламый, гаилә тантаналарында, бәйрәмнәрдә, алда торган эшләр һәм чыгымнар турында бергәләп фикер алышуларда катнашмый; гаилә әгъзалары белән туган (татар) телендә аралашудан читләшә |
| | Гомумкешелек мәдәнияте кыйммәтләрен таный, әйләнә-тирәдәгеләргә уңай караштa, кешеләргә (аларның социаль чыгышына, расасына, теленә, диненә, җенесенә һәм яшенә карамастан) ихтирамлы мөнәсәбәттә, башка кешеләрнең хисләренә, фикерләренә, теләкләренә, карашларына хөрмәт күрсәтә, үзенең килешмәвен дәлилли, ышандыра белә һ.б. Төрле ил һәм этнос кешеләре белән уңай рухта аралашуның, хезмәттәшлек итүнең әһәмиятен аңлатып бирә | Гомумкешелек мәдәнияте кыйммәтләрен тануы үсеш стадиясендә, әйләнә-тирәдәгеләргә уңай караштa, социаль чыгышы, расасы, теле, дине, җенесе һәм яше башка булган кешеләргә карата битараф мөнәсәбәт саклый, башка кешеләрнең фикерләренә, теләкләренә, карашларына колак сала белә, үзенең килешмәвен дәлилләргә, ышандырырга тырыша һ.б. | Гомумкешелек мәдәнияте кыйммәтләрен тануы формалашу стадиясендә, төрле ил һәм этнос вәкилләренә карата битараф яки агрессив мөнәсәбәттә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Табигать һәм социаль дөнья, дөньякүләм вакыйгалар, илдәге, республикадагы, туган шәһәрендәге (район үзәгендәге, авылындагы) вакыйгалар турында күптөрле мәгълүмат чыганагы буларак, өлкән кеше белән аралашуга ихтыяҗ тоя | Табигать һәм социаль дөнья, дөньякүләм вакыйгалар, илдәге, республикадагы, туган шәһәрендәге (район үзәгендәге, авылындагы) вакыйгалар турында күптөрле мәгълүмат чыганагы буларак, өлкән кеше белән аралаша | Табигать һәм социаль дөнья, дөньякүләм вакыйгалар, илдәге, республикадагы, туган шәһәрендәге (район үзәгендәге, авылындагы) вакыйгалар турында мәгълүмат белән кызыксынмый |
| | Коммуникатив сәләтләре күренә, сөйләмне аңлый, аралашу шартларына яраклаша, әңгәмәдәшенең социаль ролен исәпкә алып, татар һәм рус телләрендә аралаша | Коммуникатив сәләтләре күренә, сөйләмне аңлый, аралашу шартларына яраклаша, әңгәмәдәшенең социаль ролен исәпкә алып, татар һәм рус телләрендә аралашырга тырыша | Сөйләмне аңлый, аралашу шартларына җайлашмый, әңгәмәдәшенә кушылып сөйләшми |
| | Үзен туган шәһәренең (авылының), республикасының, иленең гражданы итеп тоя, шәһәр, республика, дәүләт символикасына (флаг, герб, гимнга) ихтирамлы мөнәсәбәттә | Үзен туган шәһәренең (авылының), республикасының гражданы итеп тоя, шәһәр, республика, символикасына (флаг, герб, гимнга) ихтирамлы мөнәсәбәттә | Үзен туган шәһәренең (авылының) гражданы итеп тоя, шәһәр символикасына ихтирамлы мөнәсәбәттә |
| **Танып белү үсеше** | Идел буе халыклары мәдәниятенең аерым элементлары (тел, кием, сәнгать, гореф-гадәтләр, милли кухня, уеннар, уенчыклар), кешеләр арасында милли һәм этник аермалыклар турында күзаллауларга ия | Идел буе халыклары мәдәниятенең аерым элементлары (тел, кием, сәнгать, гореф-гадәтләр, милли кухня, уеннар, уенчыклар), кешеләр арасында кайбер милли һәм этник аермалыклар турында күзаллауларга ия | Идел буе халыклары мәдәниятенең аерым элементлары (тел, кием, сәнгать, гореф-гадәтләр, милли кухня, уеннар, уенчыклар), кешеләр арасында милли һәм этник аермалыклар турында күзаллый алмый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Башка милләт вәкилләренең мәдәнияте белән кызыксынуын һәм ихтирамлы мөнәсәбәтен ачык белдерә, алар белән аралашырга омтыла | Башка милләт вәкилләренең мәдәнияте белән кызыксынуын һәм ихтирамлы мөнәсәбәтен белдерә, аралашканда, бәхәскә керергә мөмкин | Башка милләт вәкилләренең мәдәниятенә карата кызыксынуы һәм ихтирамы юк, аралашканда, бәхәсләшә, социаль хис-тойгылары тискәре |
| | Төбәктәге эре шәһәрләрнең мәдәни байлыгы, төп тарихи вакыйгалары, истәлекле урыннары, символикасы турында беренчел күзаллаулары бар, әлеге шәһәр исемнәренең килеп чыгышы белән кызыксына | Төбәктәге эре шәһәрләрнең исемнәрен, кайбер үзенчәлекләрен белә, аларның мәдәни байлыгы, төп тарихи вакыйгалары, истәлекле урыннары, символикасы турында беренчел күзаллаулары бар, шәһәр атамасын ул урнашкан урын белән бәйләп карамый | Төбәктәге кайбер шәһәрләрнең исемнәрен, кайбер истәлекле урыннарын белә, шәһәр атамасын ул урнашкан урын белән бәйләп карамый |
| | ТР Кызыл китабына кертелгән, дәүләт тыюлыкларында яшәүче хайваннар, республиканың елга-күлләрендә яшәүче тереклек ияләре белән кызыксына, табигатьне сакларга кирәклеген аңлый | ТР Кызыл китабына кертелгән, дәүләт тыюлыкларында яшәүче хайваннар, республиканың елга-күлләрендә яшәүче тереклек ияләре турында мәгълүмат белән сайлап кына кызыксына, табигатьне сакларга кирәклеген аңлый | ТР Кызыл китабына кертелгән, дәүләт тыюлыкларында яшәүче хайваннар, республикадагы елгалар һәм күлләр турында мәгълүмат белән кызыксынмый, табигатьне саклау турында уйламый |
| | Ватан кыйммәтләрен таный, Россия турында туган иле буларак күзаллый, дәүләт символикасын (флаг, герб, гимн) белә һәм хатасыз әйтеп бирә ала | Ватан кыйммәтләрен тануы үсеш стадиясендә, Россия турында туган иле буларак күзаллый, дәүләт символикасын (флаг, герб, гимн) белә һәм әйтеп бирә ала | Ватан кыйммәтләрен тануы формалашу стадиясендә, Россия турында туган иле буларак берникадәр күзаллаулары бар, дәүләт символикасын (флаг, герб, гимн) белми |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Татар һәм рус халкы мәдәниятләренең үзара бәйләнешен аңлый | Татар һәм рус халкы мәдәниятләренең үзара бәйләнешен билгеләгәндә, кыенлык тоя | Татар һәм рус халкы мәдәниятләренең үзара бәйләнешен аңламый |
| | Россиянең бер өлеше буларак, туган ягы, туган шәһәре тарихы, анда яшәүче күренекле кешеләр, төп истәлекле урыннары, гореф-гадәтләр, кешеләрнең хезмәте турында күзаллауларга ия | Россиянең бер өлеше буларак, туган ягы, туган шәһәре тарихы турында өйрәну теләге белән кайбер очракларда кызыксынуын белдерә, анда яшәүче танылган кешеләр, төп истәлекле урыннар, гореф-гадәтләр, кешеләрнең хезмәте турында белә | Россиянең бер өлеше буларак, туган ягы, туган шәһәре тарихы турында өйрәнүгә кызыксынуы юк, анда яшәүче кешеләр, аларның хезмәте турында аз белә |
| | Татарстан тарихы һәм аның башкаласының төп истәлекле урыннарына бәйле мәсьәләләрдә кызыксынучанлык күрсәтә | Татарстан тарихы һәм аның башкаласының төп истәлекле урыннары белән берникадәр кызыксына | Татарстан тарихы, аның башкаласының төп истәлекле урыннары белән кызыксынмый |
| | Музыка һәм театр сәнгате, күренекле фән эшлеклеләренең тормышы һәм иҗаты турында кызыксынып тыңлый, аларның исемнәрен әйтеп бирә ала, аларга хөрмәт белән карый | Музыка һәм театр сәнгате эшлеклеләренең, күренекле фән эшлеклеләренең тормышы һәм иҗаты турында тыңлый, аларның исемнәрен әйтеп бирә ала | Музыка һәм театр сәнгате эшлеклеләренең, күренекле фән эшлеклеләренең тормышы һәм иҗаты турында мәгълүмат белән кызыксынмый |
| | Бөек Ватан сугышында катнашучыларга рәхмәт һәм хөрмәт хисе белән карый, сугыш геройларының батырлыклары турында белә | Бөек Ватан сугышында катнашучыларга рәхмәт һәм хөрмәт хисе белән карый, кайбер сугыш геройларының батырлыклары турында белә | Бөек Ватан сугышында катнашучыларга карата битараф мөнәсәбәттә, сугыш геройларының батырлыклары турында белми |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Әхлакый-этик, милли, хокукый мәдәнияттә кабул ителгән үзеңне имин тоту кагыйдәләрен белә, аларны аңлы рәвештә үти | Әхлакый-этик, милли, хокукый мәдәнияттә кабул ителгән үзеңне имин тоту кагыйдәләрен белә, ләкин аларны өлкән кеше искә төшергәндә генә үти | Әхлакый-этик, милли, хокукый мәдәнияттә кабул ителгән үзеңне имин тоту кагыйдәләренең кайберләрен белә, ләкин аларны өлкән кеше кушканда гына үти |
| **Сөйләм үсеше** | Җөмләләрне татар теленнән русчага тәрҗемә итә ала | Өлкән кеше бераз әйтеп җибәргәндә, җөмләләрне татар теленнән русчага тәрҗемә итә ала | Җөмләләрне татар теленнән русчага тәрҗемә итүдә кыенлык тоя |
| | Исемгә сыйфатлар, охшаш һәм капма-каршы мәгънәле сүзләр сайлый | Исемгә сыйфатлар сайлый, охшаш һәм капма-каршы мәгънәле сүзләр сайлаганда, кыенлык тоя | Исемгә сыйфатлар, охшаш һәм капма-каршы мәгънәгә ия сүзләр сайлаганда, кыенлык тоя |
| | Табышмаклар, әкиятләр иҗат итә, үзе турында, бер үк зат сурәтләнгән ситуатив рәсемнәр сериясе, сюжетлы рәсемнәр, репродукция, шәхси күзәтүләр нигезендә зур булмаган (3–8 җөмләлек) хикәяләр төзи | Өлкән кеше ярдәме белән табышмаклар, әкиятләр иҗат итә, үзе турында, бер үк зат сурәтләнгән ситуатив рәсемнәр сериясе, сюжетлы рәсемнәр, репродукция, шәхси күзәтүләр нигезендә зур булмаган (3–8 җөмләлек) хикәяләр төзи | Табышмаклар, әкиятләр иҗат итүдә, үзе турында, бер зат сурәтләнгән ситуатив рәсемнәр сериясе, сюжетлы рәсемнәр, репродукция, шәхси күзәтүләр нигезендә зур булмаган (3–8 җөмләлек) хикәяләр төзүдә кыенлык тоя |
| | Сүзләрдәге авазларга анализ ясый, иҗекләр, сүзләр укый | Сүзләрдәге авазларга анализ ясаганда, хаталар җибәрә, иҗекләп укырга тырыша | Сүзләрдәге авазларга анализ ясый белми, укуга теләк белдерми |
| | ТР рәссамнарының картиналарын караганда, сораулар бирә, үз фикерләрен монолог формасында әйтеп бирә | ТР рәссамнарының картиналарын караганда, сораулар бирә, үз фикерләрен монолог формасында әйтеп бирүдә кыенлык тоя | ТР рәссамнарының картиналарын караганда, сораулар бирергә мөмкин, монолог формасында әйтеп бирә алмый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Татар язучыларының әдәби әсәрләрен озаклап тыңларга, аерым этюдларын кабат сөйләп чыгарга, аларның гомуми эчтәлеген әйтеп бирергә сәләтле, сәхнәләштерүләрдә катнаша | Татар язучыларының әдәби әсәрләрен озаклап тыңлаганда, аерым этюдларын кабат сөйләп чыкканда, аларның гомуми эчтәлеген сөйләгәндә, кыенлык тоя, сәхнәләштерүләрдә катнаша | Татар язучыларының әдәби әсәрләрен озаклап тыңлый алмый, аерым этюдларны кабат сөйләп чыга, гомуми мәгънәсен әйтеп бирә алмый, сәхнәләштерүләрдә теләмичә генә катнаша |
| | Дидактик (лексик) уен биременең нәтиҗәсенә ирешә | Дидактик (лексик) уен биременең нәтиҗәсенә ирешергә тырыша, хаталар җибәрә, аларны мөстәкыйль рәвештә таба, төзәтә | Дидактик (лексик) уен биременең нәтиҗәсенә ирешү белән кызыксынмый |
| | Аралашу шартларына карап ориентлаша һәм яңа шартларда, тиешле сүзләр һәм грамматик чараларны сайлап алып, мөстәкыйль рәвештә хәл итә ала | Аралашу шартларына карап ориентлаша белә, яңа шартларда мәсьәләне мөстәкыйль рәвештә хәл итүдә авырлык кичерә, тиешле сүзләр һәм грамматик чараларны табарга тырыша | Табигый аралашу шартларына начар җайлаша, яңа шартларда мәсьәләне мөстәкыйль рәвештә хәл итүдә авырлык кичерә |
| | Реаль тел мохитендә, рус (татар) телен чикле дәрәҗәдә белгән хәлдә дә, коммуникатив максатка ирешә | Реаль тел мохитендә, рус (татар) телен чикле дәрәҗәдә белгән хәлдә дә, коммуникатив максатка ирешә диярлек | Рус (татар) телен чикле дәрәҗәдә белгән хәлдә, реаль тел мохитендә коммуникатив максатка ирешүдә авырлык кичерә |
| | Татар телен алга таба тагын да аңлабрак өйрәнүгә кызыксыну тоя | Үзенең сөйләмен үстерү белән кызыксына | Үзенең сөйләмен үстерү белән кызыксынмый |
| | Татар халкының әдәби мирасы белән даими кызыксына, әлеге белемнәрен үзенчәлекле эш төрләрендә, көндәлек аралашуда, конкурсларда файдалануга өстенлек бирә | Татар халкының әдәби мирасы белән кызыксына, кайвакыт аны үзенчәлекле эш төрләрендә, көндәлек аралашуда куллана | Татар халкының әдәби мирасы белән кызыксынмый, аны үзенчәлекле эш төрләрендә кулланмый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Сәнгати-эстетик үсеш** | Милли мәдәниятне үстерүдә кешенең ролен аңлый, кеше эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак, мәдәният элементларына карата кызыксыну белдерә, мәдәни мирасны баетуда (арттыруда) үзенең катнашу мөмкинлеген алдан күрә | Милли мәдәният элементларына соклана, татар халкының мәдәни кыйммәтләрен билгеләүдә кыенлык тоя, аның мәдәни эшчәнлеге нәтиҗәләренә битараф, мәдәни мирасны баетуда (арттыруда) үзенең катнашу мөмкинлеген күз алдына китерми | Милли мәдәниятне үстерүдә кешенең ролен аңламый, мәдәният элементлары белән сирәк соклана, мәдәни мирасны баетуда (арттыруда) үзенең катнашу мөмкинлеген күз алдына китерми |
| | ТР мәдәният эшлеклеләренең рәсем, скульптура, музыка һәм башка сәнгатькә бәйле чараларына карата кызыксыну белдерә | ТР мәдәният эшлеклеләренең рәсем, скульптура, музыка һәм башка сәнгатькә бәйле чараларына берникадәр кызыксыну белдерә | ТР мәдәният эшлеклеләренең рәсем, скульптура, музыка һәм башка сәнгатькә бәйле чараларын танып белергә омтылмый |
| | Туган шәһәренең (район үзәге, бистә, авылының) архитектура корылмалары турында күзаллаулары бар | Туган шәһәренең (район үзәге, бистә, авылының) архитектура корылмалары турында берникадәр күзаллаулары бар | Туган шәһәренең (район үзәге, бистә, авылының) архитектура корылмалары турында күзаллаулары юк |
| | Симметрик («тормыш агачы») һәм асимметрик букет ясау ысулларын белә | Симметрик («тормыш агачы») һәм асимметрик букет ясау ысулларын белә, ләкин аларны сирәк файдалана | Симметрик («тормыш агачы») һәм асимметрик букет ясау ысулларын белми |
| | Милли декор ясаганда, рельефлы сурәтләү техникасын, предметларны милли рухта бизәгәндә симметрияле, силуэтлы, күпкатламлы ысулларны, челтәрләп кисү техникасын куллана | Милли декор ясаганда, рельефлы сурәтләү техникасын, предметларны милли рухта бизәгәндә симметрияле, силуэтлы, күпкатламлы, челтәрләп кисү техникасын өлешчә куллана | Милли декор ясаганда, рельефлы сурәтләү техникасын белми, предметларны милли рухта бизәгәндә симметрик, силуэтлы, күпкатламлы, челтәрләп кисү техникасын кулланмый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Татар композиторлары иҗат иткән вокаль, инструменталь, оркестр музыкасын бик теләп тыңлый | Татар композиторлары иҗат иткән вокаль, инструменталь, оркестр музыкасын тыңлый | Татар композиторлары иҗат иткән вокаль, инструменталь, оркестр музыкасын теләмичә генә тыңлый |
| | Россия Федерациясе Дәүләт гимны башкарылуын таный, кушылып җырларга тырыша | Россия Федерациясе Дәүләт гимны башкарылуын таный, кушылып җырларга омтылмый | Россия Федерациясе Дәүләт гимны башкарылуын таный |
| | Татар җыр-биюләрен, Идел буе халыкларының биюләрен матур итеп башкара, татар халык бәйрәмнәрендә бик теләп катнаша | Татар җыр-биюләрен, Идел буе халыкларының биюләрен башкара, татар халык бәйрәмнәрендә бик теләп катнаша | Татар халык бәйрәмнәрендә катнашудан читләшә, татар җыр-биюләрен, Идел буе халыкларының биюләрен теләмичә генә башкара |
| | Алынган мәгълүматны өлкән кеше һәм үз инициативасы белән эшчәнлекнең төрле төрләрендә (коммуникатив эшчәнлек, уен, танып белү-тикшеренү, музыка, рәсем ясау, конструкцияләү һ.б. эшчәнлекләр) куллана | Алынган мәгълүматны өлкән кеше инициативасы белән эшчәнлекнең төрле төрләрендә (коммуникатив эшчәнлек, уен, танып белү-тикшеренү, музыка, рәсем ясау, конструкцияләү һ.б. эшчәнлекләр) куллана | Алынган мәгълүматны эшчәнлекнең төрле төрләрендә (коммуникатив эшчәнлек, уен, танып белү-тикшеренү, музыка, рәсем ясау, конструкцияләү һ.б. эшчәнлекләр) чагылдыруда авырлык тоя |
| **Физик үсеш** | Сәламәт туклану, сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре турында күзаллаулары бар | Сәламәт туклану, сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре турында берникадәр күзаллауларга ия | Сәламәт яшәү рәвеше, сәламәт туклану кыйммәтләре турында күзаллаулары юк |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Гәүдәсе һәм физик мөмкинлекләре турында күзаллый ала | Гәүдәсе һәм физик мөмкинлекләре турында башлангыч күзаллаулары бар | Гәүдәсе һәм кайбер физик мөмкинлекләре турында башлангыч күзаллаулары бар |
| | Спортның кайбер төрләре, шул исәптән милли спорт төре – «бил алыш» (татарча көрәш) турында күзаллауларга ия | Спортның кайбер төрләре, шул исәптән милли спорт төре – «бил алыш» (татарча көрәш) турында күзаллауларга ия | Спортның кайбер төрләре турында берникадәр күзаллаулары бар, татарча көрәш белән кызыксынмый |
| | Ярышлы милли уеннарда, Сабан туе бәйрәмендә бик теләп катнаша | Ярышлы милли уеннарда, Сабан туе бәйрәмендә актив катнаша | Ярышлы милли уеннарда актив катнашмый, Сабан туе бәйрәмендә үзен сүлпән тота |
| | Хәрәкәтчән, чыдам, төп хәрәкәтләрне ясый, үз хәрәкәтләрен контрольдә тота һәм алар белән идарә итә ала | Хәрәкәтчән, төп хәрәкәтләрне ясый белә, үз хәрәкәтләрен контрольдә тотарга тырыша, алар белән идарә итә ала | Аз хәрәкәтчән, төп хәрәкәтләрне җиренә җиткереп башкара белми, аларны башкарганда, үз-үзен контрольдә тотмый |

Барлык белем бирү өлкәләре буенча үсеш дәрәҗәсен билгеләү диагностика нәтиҗәсендә алынган баллар суммасы нигезендә гамәлгә ашырыла: **0–17 балл** – түбән дәрәҗә, **18–66 балл** – уртача дәрәҗә, **67–84 балл** – югары дәрәҗә.



# 2. ЭЧТӘЛЕК БҮЛЕГЕ

## 2.1. БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘЛӘРЕ БУЕНЧА БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ (УКУ ҺӘМ ТӘРБИЯ) БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ЭЧТӘЛЕГЕ

## БЕРЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ

(2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

### • ИҖТИМАГЫЙ-КОММУНИКАТИВ ҮСЕШ

**Балаларның өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуы, алар белән уртак эшчәнлеккә әзерлек булдыру, социаль һәм эмоциональ үсешкә шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең иҗтимагый-коммуникатив үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Өлкән кеше белән аралашу өлкәсендә***

Баланы туган телендә аралашуга актив кушылып китәргә этәрергә, өлкән кешенең сорауларына һәм тәкъдимнәренә җавап бирергә, баланың шәхси һәм якын кешеләренең тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, аңа якын темаларга үз инициативасы белән сөйләшергә теләк булдыру. Өлкән кеше белән вазгыятьтән тыш диалогка этәрү.

Өлкән кешене туган телендә сөйләшүче һәм үз-үзен тотышында үрнәк буларак эшчәнлекне оештыручы һәм аның нәтиҗәсен бәяли торган партнёр итеп кабул итәргә булышу.

Балаларның гаиләгә үзенә күрә бер хәзинә итеп каравын формалаштыру, аларның гаилә әгъзаларын, исемнәрен санап чыгуын активлаштыру. Балага мөстәкыйль булырга ярдәм итү, аның өлкән кеше кебек булырга теләвен – эшкә кушылуын, якын кешеләренә ярдәм итүен яклау. Баланың өлкән кешегә китапларны, уенчыкларны җыярга булышу омтылышын хуплау.

Үзенә якын социаль тирәлектәге кешеләргә карата уңай мөнәсәбәт тудыру.

***Социаль мөнәсәбәтләрне үстерү һәм яшьтәшләре белән аралашу өлкәсендә***

Баланы, исемнәре белән атап, башка балалар белән таныштыру. Балаларда бер-берсенә карата кызыксыну уяту.

Балаларны милли фольклор материалындагы тәртип үрнәкләре белән таныштыру. Төрле уен һәм/яисә көндәлек ситуацияләрдә балалар арасында үзеннән-үзе барлыкка килгән үзара бәйләнешләрне күзәтү; балалар арасында конфликт килеп чыккан очракта катнашырга ашыкмау. Балаларның игътибарын социаль аралашу процессында туган хисләргә юнәлтү, үпкәләгән очракта юату һәм кайбер гамәлләрнең үпкәләтә алу мөмкинлегенә игътибар итү.

Уртак уеннар оештыру, татар әкиятләрен, такмазаларын, җырларын сәхнәләштерү, «Татармультфильм» студиясе мультфильмнарын карау, татар көйләренә ияреп, бергә хәрәкәтләр ясау һ.б. өчен шартлар тудыру.

***Уен эшчәнлеген үстерү өлкәсендә***

Балалар арасында уен эшчәнлеге үсешенә һәм туган телне актив үзләштерергә ярдәм итә торган аралашуны хуплау, предметлы гамәлләрне үстерү. Уен вакытында балага яшьтәшләре белән аралашырга, аларга бер-берсе белән низагларсыз, тату уйнарга булышу.

Бала көнкүреш әйберләрен куллана торган сюжетлы сурәтләү уеннарын (өстәлгә эскәтер җәя, агач кашык белән аш ашый, чәйгә самавырдан су агыза, кулларын сөлге белән сөртә һ.б.) хуплау. Татар халкының көнкүрешен чагылдыра торган уенчыкларны, предметларны сайлап алганда, балаларның мөстәкыйльлеген хуплау.

Балага гади уен гамәлләрен үзләштерергә (курчакны ашатырга, аны йокларга яткырырга, кәстрүлдәге ботканы болгатырга) булышу, баланың роль (әти-әни) уйнарга тырышуын, берничә бала катнашында сюжетлы уеннар оештыруын хуплау.

Милли фольклор материалына нигезләнеп, баланың тәҗрибәсенә, аңа таныш вазгыятькә таянып, өлкәннәр белән уртак инсценировкалар оештыру. «Яхшы» белән «начар»ны аеру, аңлау һәм кабул итү сәләтен формалаштыру.

***Социаль һәм эмоциональ үсеш өлкәсендә***

Адаптация чорында балаларга якын кешеләреннән аерылуны җиңелрәк кичерергә ярдәм итү. Балага эзлекле рәвештә, үз көенә Оешманың пространствосына һәм режимына, яңа социаль шартларга ияләшергә мөмкинлек бирү.

Яшьтәшләре белән үзара симпатия тудыруга ярдәм итә торган аралашуны яклау. Балаларның хәлгә керү, кайгыртучанлык, игелеклелек кебек гамәлләрен хуплау.

Уңай «мин» образын формалаштыру, үз-үзенә уңай бәя бирү сыйфатын үстерү, уңышка ирешү ихтыяҗы барлыкка китерү өчен нигез булдыру.

## • ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ

**Балаларны әйләнә-тирә табигать күренешләре һәм предметлары белән таныштыру, предметлар белән эш-гамәлләрне үзләштерү, танып белү-тикшеренү активлыгын һәм танып белү сәләтләрен арттыру өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең танып белү үсеше өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балаларның әйләнә-тирә табигать күренешләре һәм предметлары белән таныштыру, предметлы эш-гамәлләрне үзләштерү өлкәсендә***

Иҗтимагый тормышның кайбер күренешләре һәм һөнәрләр белән таныштыру (хастаханәдә табиб дәвалый, урам себерүче шәһәр урамнарын чистарта, кибеттә сатучы азык-төлек сата, автобус йөртүче пассажирларны йөртә һ.б.).

«Хәзинәләр кәрзине»н кулланып, предметлар белән, аларның кулланылышы белән таныштыру (тарак, аш чүмече, кулчатыр, төймәләр, ачкычлар, шнурлар, күзлек һ.б.). Танып белү сәләтләрен үстерү.

Көндәлек тормышта су турында (су белән юыналар, кер юалар, коеналар), табигатьтә су турында (яңгыр ява, елга ага, күлләвек җыела һ.б.) күзаллаулар булдыру. Гади гомумиләштерүләр ясарга этәргеч бирү.

Хайваннар турында беренчел күзаллаулар формалаштыру: йорт хайваннары һәм аларның балалары турында (песи – песи баласы, кәҗә – кәҗә бәтие, эт – көчек, сыер – бозау һ.б.), йорт кошлары (тавык, әтәч, чеби, каз, үрдәк һ.б.), урман җәнлекләре (төлке, куян, аю, тиен һ.б.), кошлар (саескан, ала карга, чыпчык, күгәрчен һ.б.). Танып белүнең мәдәни ысулларына таянып, баланың кызыксынучанлыгын үстерү (рәсемле китаплар, йомшак пазллы китаплар, тавыш чыгара торган китаплар, ябыштыра торган рәсемнәре булган китаплар һ.б.).

Туган як табигатендә ел фасылларының үзгәрүчәнлеге турында беренчел күзаллаулар формалаштыру (кышын салкын, әйләнә-тирәдә кар, салкын җил исә; язын җылы, кар эри, гөрләвекләр ага, агачлар яфрак яра; җәен кызу, кояш кыздыра, җиләкләр пешә, чәчәкләр чәчәк ата; көзен салкынча, яңгырлар ява, сары яфраклар коела һ.б.). Күзәтүчәнлек сәләтен үстерү.

***Танып белү-тикшеренү активлыгын һәм танып белү сәләтләрен үстерү өлкәсендә***

Бай предметлы үсеш мохите булдыру аша балаларның тикшеренү эшчәнлегенә булышлык итү, аны төрле предметлар белән тулыландыру (кәстрүлләр, иләк, пластмассадан ясалган банкалар, шешәләр, әстерхан чикләвеге, кәстәнә (каштан), ком, таш, су һ.б.).

Әйләнә-тирә табигать дөньясына карата балалар кызыксыну белдергәндә, аларның сорауларына игътибарлы булу, ашыкмыйча җавап бирү, баланың гаҗәпләнүен һәм кызыксынучанлыгын аңлап кабул итү.

LEGO конструкторын һәм аксессуарларын, «Йорт хайваннары», «Кошлар ишегалдында», «Зоопарк» һ.б. уен җыелмаларын кулланып, уен эшчәнлегенә танып белү һәм конструктив хәрәкәткә этәрә торган максатчан төс бирү.

## • СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ

**Балаларның көндәлек тормышта сөйләмен үстерү, махсус оештырылган уеннар һәм шөгыльләр аша сөйләмнең төрле якларын үстерү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең сөйләм үсеше өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Көндәлек тормышта сөйләм үсеше өлкәсендә***

Балаларны табигый тел мохитенә кертү. Көндәлек тормыштагы вакыйгаларны, ситуацияләрне аңлатып бару, бала белән шул турыда сөйләшү, аның тормышында булган вакыйгалар, аның кызыксынулары һәм тәҗрибәсе турында сөйләшү.

Балаларның үз теләкләрен, хис-кичерешләрен, кызыксынуларын белдерүләренә, сорауларына игътибарлы булу, туган (татар) телендә сөйләшүче баланы сабырлык белән тыңлау, баланың актив сөйләмен хуплап, аның ни әйтергә теләгәнен аңларга омтылу.

Балалар белән диалог кору өчен төрле вазгыятьне куллану, балаларны актив сөйләмгә этәрә торган ачык сораулар бирү. Баланың хаталарын күрсәтми генә, аның артыннан сүзләрне дөрес итеп кабатлап, вазгыятьтән тыш диалогка алып килү.

***Сөйләмне төрле яклап үстерү өлкәсендә***

Сүзлек запасын предмет исемнәре, аларның үзенчәлекләре, алар белән бәйле хәрәкәтләрне (алъяпкыч кияргә, катык ашарга, яңа түбәтәй, агач кашык, җылы киез итекләр һ.б.), якын кешеләрнең һөнәрләрен атау (табиб, пешекче, тәрбияче) аша баету. Туган телдә уйламыйча да сөйләшү күнекмәсен булдыру.

Сөйләмдә авазларга охшатып ясалган сүзләр кергән уеннар уйнату, сүзнең аваз ягына игътибар итү (әтәч кычкыра – «кикрикүк», үрдәк бакылдый – «бак-бак», сәгать текелди – «келт-келт» һ.б.). Сөйләмне ишетеп истә калдыру.

Гади татар халык әкиятләрен, катлаулы булмаган фольклор әсәрләрен (такмаклар, җырлар), кыска шигырьләрне аңлап кабул итүләрен үстерү. Баланы әдәби һәм фольклор әсәрләрдән аерым сүзләрне һәм гыйбарәләрне кабатларга этәрү.

Кыска шигырьләрдә, такмазаларда, татар әкиятләрендә вакыйгалар үсешен күзәтергә өйрәтү, тыңлаганда, китаптагы рәсемнәрне күрсәтеп бару, ул рәсемнәрдә нәрсә сурәтләнгәнне аңлату. Рәсемнәрне караганда, шатлык хисләре уяту, «бу кем?», «нишли?», «ничек кычкыра?» һ.б. сорауларга җавап бирүләренә ирешү. Баланы китаптагы иллюстрацияләрне мөстәкыйль рәвештә карарга этәрү.

Уенны сәхнәләштерүләр вакытында, «Татармультфильм» берләшмәсенең мультфильмын караганда, сөйләмне аңлауларын камилләштерү.

Балаларның ритмик яктан көйләнгән юлларны кабатлауга һәм татар шагыйрьләренең зур булмаган шигырьләрен сөйләүгә омтылышын хуплау, сөйләмнең аһәңлелеген үстерү.

Балаларның сөйләм үсешен күзәтү.

Сөйләмнең планлаштыру һәм көйләү функцияләре үсешенә булышлык итү.

## ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ӘСӘРЛӘР

**Балаларга уку өчен**

***Җырлар, юаткычлар, эндәшләр, бармак уеннары:*** «Әлли-бәлли итәр бу»; «Әлли-бәлли бәү итә»; «Тор-тор, тургай…»; «Үчтеки, үчтеки»; «Кәккүк-чыпчык...»; «Үсә-үсә бәбкәем»; «Җиләк җыям, как коям»; «Салкын су, чиста су…»; «Бас, кызым Әпипә»; «Минем кызым кечкенә...»; «Чәбәк-чәбәк әбкәсе»; «Бу бармак – бабай…»; «Хайваннарны чакыру...»; «Бармак, бармак, кайда булдың?».

***Әкиятләр:*** «Кәҗә бәтиләре һәм бүре», «Калач», татар халык әкиятләре; «Шалкан», «Чуар тавык», «Теремкәй», рус халык әкиятләре.

***Шигырьләр:*** Р. Харис. «Үчти-үчти», «Бәлли-бәү»; Н. Измайлова. «Без чәбәкәй итәбез», «Йоклар алдыннан»; Мөҗәһит. «Булатны йоклатканда»; Җ. Тәрҗеманов. «Бәлли-бәү», «Минем кызым – курчагым», «Кикрикүк»; Б. Рәхимова. «Чулпанга бәллү»; Х. Халиков. «Чәбәкәй»; Г. Лотфи. «Әтәч»; Р. Миңнуллин. «Мияу»; Р. Корбан. «Бәти»; М. Җәлил. «Маэмай»; М. Хөсәен. «Чебиләр»; Ә. Кари. «Тавык», «Безнең сыер», «Кәккүк»; Д. Гарифуллин. «Йә, алар кемнәр икән?»; Җ. Дәрзаман. «Аюым»; Р. Арсланова. «Иртән»; Р. Харис. «Лап-лап»; Р. Сәлах. «Сары яфраклар»; В. Хәйруллина. «Яңгыр»; Ә. Ерикәй. «Беренче кар», «Тышта яз»; Ә. Бикчәнтәева. «Беренче адымнар», «Бии-бии үс, әйдә»; З. Туфайлова. «Ул зу-у-у-ур үскән»; Йолдыз. «Минем тубым», «Курчагым»; Б. Рәхмәт. «Су», «Әтәчем»; Л. Нурлы. «Зилә коймак пешерә»; С. Сөләйманова. «Ике»; Г. Таһирова. «Йокла, курчак».

***Әдәби әкиятләр һәм хикәяләр:*** Җ. Тәрҗеманов. «Җиләккә барганда», «Йокы бабай»; Батулла. «Нурбәк әкияте»; З. Хөснияр. «Зилә бакчага бара»; Г. Хәйдәрова. «Балалар бакчасында»; Г. Бакир. «Карлар ява»; С. Летова. «Кар бабай»; Л. Толстой. «Настяның курчагы»; К. Ушинский. «Мияубикә», «Казлар», А. Әхмәт тәрҗемәсе.

## • СӘНГАТИ-ЭСТЕТИК ҮСЕШ

**Балаларда әйләнә-тирә мохиткә карата эстетик мөнәсәбәт формалаштыру, эшчәнлекнең сурәтләү төрләренә, музыка сәнгатенә, театр эшчәнлегенә җәлеп итү белем бирү эшчәнлегенең сәнгати-эстетик үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балаларда әйләнә-тирә мохиткә карата эстетик мөнәсәбәт формалаштыру өлкәсендә***

Балаларның игътибарын милли костюм кигән курчакка юнәлтү. Хис-кичерешләрен баетуга, кызыксынуларына этәргеч бирү.

Балаларның игътибарын татар гамәли сәнгать бизәкләре төшерелгән көнкүреш предметларына юнәлтү. Халык иҗаты әсәрләренең гүзәллегенә карата уңай хисләр уяту.

Татар халык әкиятләре мотивлары, такмазалар, татар язучылары һәм шагыйрьләренең кыска әдәби әсәрләре буенча рәсемле китапларны укыганда, уңай хисләр уятырга булышлык итү. Бала эстетик хисләр кичергәндә, аңа теләктәшлек күрсәтү.

***Балаларны эшчәнлекнең сурәтләү төрләренә җәлеп итү өлкәсендә***

*Рәсем ясау*

Балаларга әзер рәсемгә буяу төшерү аша рәсемдә әйләнә-тирә табигатьнең матурлыгын күрсәтү (җир җиләге өлгерде, яңгыр ява, яфрак коела, кар ява һ.б.).

Татар бизәгенә хас төсләрнең исемнәре белән таныштыру (кызыл, зәңгәр, яшел, сары). Бер яки ике төс кулланып, сурәтләр ясарга өйрәтү.

Вертикаль һәм горизонталь сызыклар ясауны күрсәтеп бирү. Татар халкының көндәлек тормышта куллана торган предметларын сурәтләү күнекмәләрен үстерү (яулык, сөлге, кулъяулык һ.б.).

Балаларның сурәтләү эшчәнлегенә кызыксынуларын булдыру, мөстәкыйль иҗат итүләре өчен шартлар тудыру.

*Әвәләп ясау*

Пластилин, тозлы камыр, балчык үзлекләре һәм аларны әвәләү ысуллары белән таныштыру. Материал сайлауларын хуплау.

Сыгылмалы материалларны туры һәм әйләнүле хәрәкәтләр белән җәяргә, йомарланган кисәкне бармак белән өзеп алырга, рәвешен үзгәртергә, кисәкләрне кушарга өйрәтү. Гади формалы фигуралар әвәләргә этәрү (бавырсак, чәкчәк төшләре). Сыгылмалы материаллар белән пөхтә итеп эшләү күнекмәләрен үстерү (сыгылмалы материал кисәкләрен махсус тактага кую).

*Аппликация*

Балаларны аппликация сәнгатенә җәлеп итү, әлеге эшчәнлек төренә карата кызыксыну уяту. Кәгазь битенә татар чәчәк-үсемлек бизәкләре мотивлары (лалә, кыңгырау, ромашка чәчәкләре, гөлҗимеш, миләш җимешләре һ.б.) төшерелгән әзер детальләрне урнаштырырга, гади бизәкләр төшереп, аларны катлаулы булмаган ритмик тәртиптә төзергә өйрәтү.

Татар гамәли сәнгате мотивлары буенча коллектив композицияләр ясау күнекмәләре үстерү. Элек үзләштергән белем һәм күнекмәләрне кулланып, рәсем ясау, әвәләү, аппликация техникаларын берләштерү ярдәмендә ачык образлар тудырырга ярдәм итү.

***Балаларны музыка сәнгатенә җәлеп итү өлкәсендә***

Татар халык көйләрен һәм татар композиторлары иҗат иткән музыканы тыңлау, аның образлы эчтәлеген аңлау күнекмәләре формалаштыру. Хис-кичерешләрен чагылдырырга өйрәтү. Музыкага уен һәм бию хәрәкәтләре башкарырга этәрү.

Татар биюенә хас гади хәрәкәтләр: «гади адымнар», «бер аяк белән тыпырдау», «ике аяк белән тыпырдау», «урында сыгылмалы хәрәкәт» белән таныштыру. Биергә теләк уяту.

Балаларны ирекле биергә, җырларга, татар композиторлары җырларына кушылырга җәлеп итү. Төркемдә музыкаль мохит тудыру, балаларның көндәлек тормышына җайлап кына татар музыкасын кертеп җибәрү.

***Балаларны театральләштерү эшчәнлегенә җәлеп итү өлкәсендә***

Балаларны «театр», «курчак театры» төшенчәләре белән таныштыру. Балаларны театральләштерелгән тамашаны кабул итәргә әзерләү. Театр этикетының гади кагыйдәләрен формалаштыру.

## МУЗЫКАЛЬ ӘСӘРЛӘРНЕҢ ЯКЫНЧА ИСЕМЛЕГЕ

### Музыка тыңлау

«Әпипә», татар халык көе, Р. Еникиева эшкәрт.; «Бу – мин», Ә. Зиннурова муз., Р. Ураксина сүз.; «Курчак», татар халык көе, Ш. Монасыйпов эшкәрт.; «Курчагым», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Йокла, курчак», М. Мозаффаров муз., М. Таһирова сүз.; «Көз килде», Л. Хисмәтуллина муз. һәм сүз.; «Яңгыр», Л. Хисмәтуллина муз.; «Песи», Р. Ахиярова муз., Р. Харис сүз.; «Шылтыравык», М. Бикбова муз. һәм сүз.; «Кышкы җыр», Г. Гәрәева муз. һәм сүз.; «Ак куян», М. Бикбова муз. һәм сүз.; «Куян», «Шаян тавык», Ф. Шаймәрданова муз.; «Чыпчыклар», Д. Хәсәншин муз.; «Яз җитә», Җ. Фәйзи муз., Ф. Кәрим сүз.; «Тамчылар», Р. Ахиярова муз.; «Өй алдында чебиләр», Л. Батыр-Болгари муз., М. Хөсәен сүз.; «Әтәчкәй – алтын кикриккәй», Ф. Әхмәтов муз.; «Минем әтәчем»,

Җ. Фәйзи муз., Ә. Исхак сүз.; «Маэмай», Ф. Яруллин муз., М. Җәлил сүз.; «Сыер», М. Мозаффаров муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Бәтиләр», «Колын», Ә. Бакиров муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Атта», Ф. Әхмәтов муз.; «Күрсәт әле, үскәнем», татар халык уены, Р. Еникиева эшкәрт.

**Җырлау**

«Чәбәк-чәбәк», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз.; «Су», Ф. Җәләлетдинова муз., Б. Рәхмәт сүз.; «Бәү-бәү», Л. Хисмәтуллина муз., З. Ибраһимова сүз.; «Минем әтәчем», Җ. Фәйзи муз., Ә. Исхак сүз.; «Чыршы янында», Г. Гәрәева муз. һәм сүз., Р. Еникиева эшкәрт.; «Безнең нәни Әнисә», Л. Хисмәтуллина муз. һәм сүз.; «Яңгыр, яу!», «Кояш, чык!», балалар фольклорыннан, Ф. Җәләлетдинова эшкәрт.; «Тукран», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз., халык сүз.; «Кәк-күк», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз. һәм сүз., «Кошчык», Л. Хисмәтуллина муз., Р. Гыйләҗева сүз.; «Ми-яу!», Л. Хисмәтуллина муз., Р. Гыйләҗева сүз.; «Акбай», Т. Вафина муз., М. Шаһиҗиһанова сүз.; «Бәтиләр», Ә. Бакиров муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.

**Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр**

«Йөрибез», Н. Бакиева муз.; «Без бердәм атлыйбыз», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз. һәм сүз.; «Марш», «Йөгерергә өйрәнәбез», Л. Шиһабетдинова муз.; «Йөрибез – биибез», Р. Еникиева муз.; «Кошлар оча», М. Салихов муз.; «Мәче», татар халык көе, Р. Зарипов эшкәрт.; «Кайда безнең кулларыбыз?», Ф. Шәймәрданова муз. һәм сүз.; «Айгөлне йоклатабыз», «Кояш-кай», «Минем аюым», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз.; «Акбай белән уен», Л. Хисмәтуллина муз., халык сүз.; «Күрсәт әле, үскәнем», татар халык уены, Р. Еникиева эшкәрт.; «Чыршы янында җырлап бию», Т. Вафина муз., М. Әндерҗанова сүз.; «Ап-ак куян», Ф. Шәймәрданова муз., халык сүз.; «Өй алдында чебиләр», Л. Батыр-Болгари муз., М. Хөсәен сүз.; «Күңелле шылтыравык», Г. Гыйләҗетдинова муз. һәм сүз.; «Аерым бию», Ф. Шәймәрданова муз., Р. Гатина, Ф. Батыршина сүз.; «Биик бергәләп», «Шылтыравык белән уен», Л. Хисмәтуллина муз. һәм сүз.; «Курчак белән бию», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Әйдә», Г. Ильина муз. һәм сүз.; «Нинди матур түгәрәк», З. Ибраһимова муз. һәм сүз.; «Бармаклар – куллар», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.

**Музыкаль-дидактик уеннар**

*Ритмны тою сәләтен үстерү:* «Чәп-чәп, чәптеки», Г. Гыйләҗетдинова муз., халык сүз.; «Чәбәк-чәбәк», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз.

*Динамик төсмерләрне ишетү сәләтен үстерү:* «Акрын-көчле», Р. Еникиева муз.; «Атта», Ф. Әхмәтов муз.

**Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәре**

*Сәхнәләштерү һәм музыкаль спектакльләр:* «Өй алдында чебиләр», Л. Батыр-Болгари муз., М. Хөсәен сүз.; «Акбай белән уйныйбыз», Л. Хисмәтуллина муз., халык сүз.; «Ап-ак куян утыра», Ф. Шәймәрданова муз., халык сүз.; «Паровоз», Л. Шиһабетдинова муз., С. Әхмәтов сүз.; «Күрсәт әле, үскәнем», татар халык уены, Р. Еникиева эшкәрт.

*Курчак театры:* «Йә, алар кемнәр икән?», Д. Гарифуллин; «Гали белән Кәҗә», Г. Тукай; «Кәҗә бәтиләре һәм бүре», «Калач», татар халык әкиятләре.

*Бәйрәмнәр:* «Кыш бабай кунакка килгән».

## • ФИЗИК ҮСЕШ

**Балаларның сәламәтлеген ныгыту, сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен формалаштыру, актив хәрәкәтләнү төрләрен үстерү, үз-үзеңне тотуда куркынычсызлык күнекмәләре булдыру өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең физик үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балаларның сәламәтлеген ныгыту, сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен формалаштыру өлкәсендә***

Культура-гигиена процедураларын башкаруның төп алгоритмнары белән таныштыру. Балаларны аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә гигиена процедураларын башкарырга күнектерү: кранны ачарга, кулларны пөхтә итеп сабынлап юарга, бит юарга, сөлге белән корытырга, сөлгене урынына элеп куярга өйрәтү. Гигиена саклау күнекмәләрен формалаштыру.

Табында үз-үзеңне тотуның иң гади кагыйдәләрен формалаштыру: чынаякны, аш һәм чәй кашыкларын, салфетканы, тастымалны дөрес кулланырга, ризыкны тавышсыз гына чәйнәргә, ашап туйгач, рәхмәт әйтергә өйрәтү. Һәр ашап торганнан соң, авызны чиста су белән чайкарга күнектерү.

Суның, яшелчәләрнең, боткаларның кеше сәламәтлеге өчен файдасы турында сөйләү.

Балаларны аңлы рәвештә теш щёткасы, тарак, кулъяулык, бәдрәф кәгазе, юеш салфетка кулланырга өйрәтү.

***Актив хәрәкәт төрләрен үстерү өлкәсендә***

Актив хәрәкәт, шул исәптән мөстәкыйль хәрәкәтләр өчен шартлар тудыру. Физик күнегүләр белән шөгыльләнүдән канәгатьлек хисе алырга ярдәм итү.

Балаларның хәрәкәтләнүгә булган табигый ихтыяҗын канәгатьләндерү. Чана шуу, руль белән идарә итеп, өч тәгәрмәчле велосипедта йөрү мөмкинлеге бирү.

Өлкәннәр тарафыннан оештырылган хәрәкәтле татар уеннарында бергәләп катнашу, хәрәкәтләрнең килешле булуына ирешү.

Балаларны вак моторика үсешен тәэмин итә торган предметлы уеннарга җәлеп итү.

***Үз-үзеңне тотуның куркынычсызлык күнекмәләрен булдыру өлкәсендә***

Куркыныч тудырмый торган мохит булдыру, балаларны аларның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч яный торган гамәлләрдән саклау.

**ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР ИСЕМЛЕГЕ**

***Йөрү һәм йөгерүле уеннар.*** «Аю һәм балалар», «Атта йөрибез», «Эт һәм үрдәкләр», «Куышу», «Яңгыр, яу!» һ.б.

***Сикерүле уеннар.*** «Бау аша сикер!», «Кояшкай», «Матур уенчык», «Кошлар очалар» һ.б.

***Шуышу һәм үрмәләүле уеннар.*** «Шылтыравыкка кадәр», «Югарырак үрмәлә!» һ.б.

***Тупны тәгәрәтү һәм тотып алу уеннары.*** «Туп кемдә?», «Тупны тәгәрәт!», «Кем тизрәк?», «Төз ыргыт!».

***Тирәлектә ориентлашу уеннары.*** «Машиналар», «Кайда шылтырый?», «Соңга калма!», «Кәҗә».

***Тигезлекне саклау уеннары.*** «Инеш аша», «Сукмак буйлап».

***Татар халык уеннары.*** «Куянкай», «Песи».

## ИКЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ

(3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

### • ИҖТИМАГЫЙ-КОММУНИКАТИВ ҮСЕШ

**Балада үз-үзенә һәм башка кешеләргә карата уңай мөнәсәбәт формалашуын, уен эшчәнлеген үстерү өчен, коммуникатив һәм иҗтимагый, шул исәптән мәгълүмати-иҗтимагый компетентлыкны үстерү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең иҗтимагый-коммуникатив үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балада үз-үзенә һәм башка кешеләргә карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру өлкәсендә***

Балада үзенә карата уңай караш, үз мөмкинлекләренә ышаныч тудыруда ярдәм итү.

Гаилә составы турында күзаллау формалаштыру (әти, әни, әби, бабай, абый-энеләр, апа-сеңелләр), гаиләдәге кешеләрнең исемнәрен белү, гаилә әгъзалары турында кайгырту кирәклеген аңлату, балаларда гаилә кыйммәтләренә карата ихтирам хисләре тәрбияләү, гаилә кыйммәтләрен кабул итүгә ориентлаштыру.

Ата-аналар булышлыгында балага үзе яшәгән урынның адресын хәтерләп калырга ярдәм итү.

Гаиләдә һәм җәмгыятьтә хезмәтнең кыйммәтен аңлау өчен алшартлар тудыру, өлкәннәрнең үтенечләрен һәм кушкан эшләрен башкарырга теләк уяту, уртак эшчәнлеккә кушылырга этәрү.

Якын-тирәдәге кешеләргә уңай мөнәсәбәт формалаштыру һәм үстерү.

***Баланың коммуникатив һәм иҗтимагый, шул исәптән мәгълүмати-иҗтимагый компетентлыгын үстерү өлкәсендә***

Туган телдә социаль элемтәләр һәм үзара ышанычка нигезләнгән аралашу өчен шартлар тудыру. Әйләнә-тирәдә, балалар бакчасында, туган шәһәрдә (авылда) булган вакыйгалар турында, төрле мәгълүмат чыганагы буларак, өлкәннәр белән аралашу ихтыяҗын канәгатьләндерү.

Культуралы аралашуның башлангыч күнекмәләрен формалаштыру (әңгәмәдәшенең милләтенә карап исәнләшү, саубуллашу, дусларча мөнәсәбәттә үтенеч-тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итү, ярдәм өчен рәхмәт әйтү, яшьтәшенә исеме белән эндәшү, нәрсәдән дә булса баш тартуны, килешмәвен икенче берәүне үпкәләтмәслек итеп белдерү).

Балалар бакчасында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

Балаларны бакчаның туган көнен, шәһәрнең истәлекле көннәрен бәйрәм итәргә җәлеп итү. Балалар бакчасы, шәһәр тормышына катнашу теләген булдыру.

Көндәлек тормышта, табигатьтә куркыныч тудыра торган төп чыганаклар турында беренчел күзаллаулар формалаштыру (таныш булмаган хайваннар, бөҗәкләр, җимешләр, сулыклар һ.б.). Балаларның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян салу ихтималы булган гамәлләрне кисәтү, балаларның көндәлек тормышта һәм табигатьтә үз-үзләрен тотышында куркынычсызлык кагыйдәләрен үзләштерүләренә ярдәм итү.

***Уен эшчәнлеген үстерү өлкәсендә***

«Чәкчәк (бавырсак) пешерәбез», «Токмачка камыр җәябез» һ.б. уеннарда аларны башкару күнекмәләрен үстерүгә ярдәм итү. Балага ул тату уйный торган башка ике-өч бала белән бергә әйләнә-тирә тормыштан төрле темалар, татар әдәби әсәрләре мотивлары, мультфильмнар буенча уеннар оештыру өчен шартлар тудыру.

Татар халкының көнкүрешен чагылдырган сюжетлы-рольле уеннар аша балаларның тормыш тәҗрибәсен баету, балаларда уен культурасын булдыру максатыннан предметлы уен мохите тудыру. Балаларның мөстәкыйль рәвештә милли уенчыклар, бизәнү әйберләрен (милли кием, бизәнү әйберләре, читекләр һ.б.), көнкүреш предметларын (кәрзин, сөлге, ашъяулык һ.б.), савыт-саба (агач кашык, самавыр һ.б.), шартлы алмаш предметларны сайлап алуларын хуплау.

Персонаж белән беренче тапкыр аралашу (Алсу исемле курчак концерт күрсәтә), өлкәннәр белән элемтәләрне киңәйтү (әби авыл ишегалдына чакыра) юлын кулланып, балада театральләштерелгән уенга карата кызыксыну уяту.

Балаларга төрле авазлар-тавышлар кулланылган хәрәкәтле уеннарга кушылу, татар шигърияте әсәрләрендә һәм кече формадагы фольклор әсәрләрдә яңгыраган сүзләргә, татар композиторлары музыкасына ияреп, хайваннар һәм кошларның хәрәкәтләрен кабатлау мөмкинлеге бирү.

Балаларны буш вакытта халык уенчыклары, курчак театры персонажлары, музыкаль уенчыклар (курай, гармун һ.б.) белән уткәрелә торган уеннарга җәлеп итү.

Бәйрәмнәр вакытында катлаулы булмаган бәйрәм-карнавал уеннары оештыру (балаларның үзләре яраткан әкият геройлары, әдәби персонажлар булып киенеп йөрүләре), балалар һәм өлкәннәр арасында уртак бәйрәм хисен үстерү.

## • ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ

**Балаларның кызыксынучанлык, танып белүгә омтылучанлык сыйфатларын, әйләнә-тирә чынбарлыкның төрле юнәлешләрендәге белемнәрне тирәнәйтү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең танып белү үсеше өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балаларның кызыксынучанлык, танып белүгә омтылучанлык сыйфатларын үстерү өлкәсендә***

Балаларны әйләнә-тирә (шәһәр яки бистә инфраструктурасының төп объектлары) белән, әйләнә-тирә предметлары, аларның ни өчен кирәк булуы белән таныштыру. Кеше яши торган торак төзелеше, көндәлек кирәк-ярак предметлары турындагы күзаллауларны үстерү, аларның төрлелеге турында сөйләү.

Балаларны күз алдында торган предметларга кагылышлы сораулар бирергә этәрү. Туган өенә карата якынлык хисе формалашуга этәргеч бирү.

Төрле билгеләргә карап, балаларны табигатьнең тәүлек дәвамындагы һәм сезонлы үзгәрешләрен күрә белергә, шулай ук кешеләр тормышындагы алар белән бәйле үзгәрешләрне күзәтергә өйрәтү. Әйләнә-тирә табигатьтә булган закончалыкларга һәм бәйлелеккә игътибар иттерү: мәсәлән, караңгы булса – фонарь кабызырга, тайгак вакытта юлга ком сибәргә кирәк.

Шушы җирлектә үсә торган кайбер үсемлекләр: агачлар (каен, имән, чыршы), куаклар (сирень, гөлҗимеш), чәчәк ата торган үсемлекләр (тузганак, үги ана яфрагы), бүлмә гөлләре (яран, фикус) белән таныштыру. Балаларда табигать объектларына карата кызыксыну уятуга этәргеч бирү.

Практик шөгыльләр барышында балаларны бакчада (дачада) үстерелгән яшелчәләрнең, җиләк-җимешнең (кишер, шалкан, алма, чия һ.б.) сыйфатлары, шул исәптән тәме (әче, баллы) белән таныштыру, танып белү активлыгын үстерү.

Балаларның бөҗәкләр (чебен, күбәләк, бал корты, үрмәкүч, күбәләк корты) турындагы күзаллауларын киңәйтү, мөстәкыйль ачышларын хуплау: чебен, күбәләк, бал корты кагылуга – очып, ә күбәләк корты һәм үрмәкүч үрмәләп китә.

Йорт хайваннарының (эт, песи, ат, сыер, кәҗә), шушы җирлектә яшәүче кыргый хайваннарның (аю, төлке, бүре, тиен, керпе), күчмә һәм кышлаучы кошларның (чыпчык, күгәрчен, кара карга, сыерчык) үзенчәлекләре белән таныштыру. Хайваннар дөньясы белән кызыксыну, алар турында күбрәк белергә теләк уяту.

Әйләнә-тирә табигатьнең матурлыгына соклана белергә өйрәтү (салават күпере, агачларга сарган бәс, чәчәкләргә кунган күбәләк, тәүге умырзаялар чәчәк ату һ.б.).

***Әйләнә-тирә чынбарлыкның төрле юнәлешләрендә күзаллауларны үстерү өлкәсендә***

Милли мәдәниятнең кайбер атрибутлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли ризыклар, кием-салым, савыт-саба, музыка уен кораллары һ.б.) турында беренчел күзаллаулар формалаштыру.

Балаларга хәзерге заманның чынбарлыгын чагылдырган фотосурәтләрне, балалар журналларында («Салават күпере»), китапларындагы («Җиде энҗе бөртеге») һәм башка

иллюстрацияләрне мөстәкыйль рәвештә карап утыру мөмкинлеге бирү. Балаларның сорау бирү теләкләрен хуплау, күренешләргә, вакыйгаларга карата фикерләре белән уртаклашу.

Балаларның ял көннәрен ничек, кайда (үзәк мәйданда, шәһәрдә, шәһәрдән читтә) уткәрүләре турында сөйләтү. Вакыйгаларга карата эмоциональ яктан уңай мөнәсәбәт белдерергә этәрү, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән хис-кичерешләрен уртаклашуларын оештыру.

Балаларны туган шәһәренең (авыл, бистәнең), үзе яшәгән урамның исемен атарга өйрәтү.

Балаларда урам, транспорт чаралары, светофор сигналлары турында тулы күзаллаулар формалаштыру, юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү өчен, төрле ситуацияләргә һәм объектларга аерым игътибар бирү.

Шәһәрдәге җәмәгать транспорт чараларының исемнәре һәм төрләре белән таныштыру. Балаларның игътибарын кайбер транспорт чараларының (трамвай, троллейбус) охшашлыгына юнәлтү. Җиңел һәм йөк машиналарының охшаш һәм аермалы якларын табарга өйрәтү, төп аермаларын санау (җиңел автомобильләрдә – кабина, руль, тәгәрмәч, йөк машиналарында – кузов һ.б.).

Аваз чыганагының урынын билгеләргә (хәрәкәт итә торган транспорт авазлары, автомобиль сигналы, светофорда яшел ут янгандагы тавыш сигналы һ.б.), төрле яңгыраштагы авазларны кабул итәргә, очып барган самолётны, хәрәкәт иткән поездны, трамвайны һ.б.ны танырга өйрәтү. Ишетү игътибарын үстерү.

Балага аңлаешлы һөнәрләр (әти-әнисенең һөнәрләре, якын социаль тирәлектәге һөнәрләр: табиб, автобус йөртүче, аш-су остасы, урам себерүче һ.б.) белән таныштыру. Хезмәт кешеләренә карата ихтирам уяту һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәләре нигезендә хезмәтнең кыйммәтен бәяләргә ярдәм итү.

## • СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ

**Сөйләм һәм тел культурасы нигезләрен формалаштыру, бала сөйләмен төрле яклап камилләштерү, аны матур әдәбият әсәрләрен уку культурасына җәлеп итү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең сөйләм үсеше өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Бала сөйләмен төрле яклап камилләштерү өлкәсендә***

Балаларны табигый тел мохитенә кертү. Балага якын темаларга, аны кызыксындырган предметлар, туган як табигатенең күренешләре турында туган (татар) телендә аралашуны активлаштыру. Үз халкының әдәби телен үзләштерүгә нигезендә сөйләм телен формалаштыру һәм әңгәмәдәш белән сөйләшеп аралашу күнекмәләрен булдыру.

Бирелгән сорауга җавап бирергә өйрәтү («нәрсә?», «кем?», «нишли?», «нинди?», «кайда?», «кайчан?», «кая?», «каян?» һ.б.). Баланың өлкәннәргә сорау һәм тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итүен стимуллаштыру.

Балага таныш халык әкиятләреннән, шигырьләрдән, такмазалардан өзекләрне уйнап күрсәтергә җәлеп итү. 2–3 җөмләдән торган гыйбарәләр әйттерү, җөмләдә сүзләр бәйләнешен тәэмин итә торган кушымчаларны кулланырга өйрәтү. Сәнгатьле сөйләмне үстерү.

Яшьтәшләре белән уйнаган вакытта үзара дусларча аралашуларына ярдәм итү, уйнаганда, балаларның үз хәрәкәтләрен, уенчыкларның исемнәрен атарга, шартлы хәрәкәтләрне тасвирлап барырга этәргеч бирү. Сөйләмнең планлаштыру һәм көйләү функцияләре үсешенә ярдәм итү.

Сөйләмдә кыска гына итеп сөйләп бирү өчен нигез була торган фигыльләр куллануны активлаштыру. Туган телдә сүз яңгырашын тыңларга өйрәтү.

Баланың сөйләме формалашканда, коммуникатив-эшчәнлекле алым кулланып, сөйләм үсеше процессын контрольдә тоту.

***Матур әдәбият әсәрләрен уку культурасына җәлеп итү өлкәсендә***

Хис-кичерешләр чыганагы һәм өлкәннәр белән уңай рухта аралашуга бер этәргеч буларак, китапка уңай караш тәрбияләү.

Балаларда төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне тыңларга кызыксыну уяту, сөйләмнәрендә тыңлап үтелгән текстлардан кайбер гыйбарәләрне кабатларга этәрү (Йомры икмәк җыры, «Теремкәй» әкиятеннән персонажларның кайбер гыйбарәләре һ.б.).

Балаларны «Татармультфильм» берләшмәсе мультфильмнарындагы, татар халык әкиятләрендәге, татар язучыларының һәм шагыйрьләренең әдәби әсәрләрендәге вакыйгалар үсешен күзәтергә өйрәтү. «Бала» интерактив тавышлы мультимедиа китапханәсенең материалларын куллану. Катлаулы булмаган сорауларга җаваплар алуга ирешү, персонажларга карата мөнәсәбәтләрен белдерергә, рольләргә бүленеп, диалоглар оештыруга ярдәм итү.

Төрле әдәби басмалар алып карау мөмкинлеге булдыру, рәсемле китаплар карап утыру өчен урын әзерләү. Китаптагы рәсемнәргә карап, әдәби геройларны танырга ярдәм итү.

Татар шагыйрьләренең зур булмаган шигырьләрен ятларга теләкләрен хуплау.

Татар фольклоры үрнәкләре (җырлар, такмазалар, бармак уеннары) белән таныштыру. Көндәлек тормышта кече фольклор формаларын куллануны хуплау.

Балаларның өлкәннәрдән китап укуларын сорап мөрәҗәгать итүенә этәргеч бирү. Татар телендә китаплар чыгара торган нәшриятларның әдәбиятын файдалана алу мөмкинлекләрен арттыру.

Балаларга өйдә төрле әсәрләр уку эшен оештыруда, «Әкият» курчак театрында куелган спектакльләр («Мактанчык әтәч», «Теремкәй» һ.б.) белән беренчел таныштыруда әти-әниләргә ярдәм итү.

## ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ӘСӘРЛӘР

### Балаларга уку өчен

***Җырлар, юаткычлар, эндәшләр, бармак уеннары:*** «Әлли-бәлли итәрсең»; «Минем кызым дәү кебек»; «Әтисе дә ярата...»; «Тилгән...»; «Кояш, чык, болыт, кач...»; «Әйдә, әйдә, Зөбәйдә...»; «Көзгегә карыйм әле...»; «Минем кызым бик иркә»; «Гөлдергү»; «Там, там, тамчы, там...»; «Баш бармак, балан ияк...»; «Баш бармак бау ишә».

***Әкиятләр:*** «Кем нәрсә ярата?», «Төлке белән Каз», «Аю белән хатын», «Мәче белән Аю», татар халык әкиятләре; «Кыз һәм икмәк» (балалар матбугатыннан); «Өч аю», рус халык әкияте; Ш. Перро. «Кызыл калфак» (әкияттән өзек), З. Садыйкова тәрҗ.

***Шигырьләр:*** Р. Сәлах. «Көзге көндә»; Ә. Бикчәнтәева. «Минем бакчам», «Туп-туп тубыбыз»; Б. Рәхмәт. «Ләлә чана шуа»; Һ. Такташ. «Ләйлә»; Ә. Рәшит. «Кыш бабай»; З. Гомәрова. «Минем бүләк», «Ул шуңа кечкенә»; Х. Вахит. «Уңган сыерчык»; Ә. Исхак. «Чишмә»; Д. Гарифуллин. «Тавыклар белән Таһир»; М. Җәлил. «Әтәч»; Н. Каштан. «Безнең сыер»; М. Мазунов. «Кәҗә»; Э. Шәрифуллина. «Куян карыйм»; З. Туфайлова. «Шофёр булам»; Э. Мөэминова. «Үз телендә сөйләшә»; Ж. Дәрзаман. «Алмаз»; Р. Арсланова. «Эшлибез»; М. Фәйзуллина. «Тәти кул»; Ә. Кари. «Курчак», «Ике кыз»; С. Рәхмәтулла. «Битен юды»; Р. Вәлиева. «Сүз тыңлаучан булыгыз»; А. Барто. «Әни белән сөйләшү», Ә. Юныс тәрҗ.

***Әдәби әкиятләр һәм хикәяләр:*** А. Алиш. «Куян кызы», «Чукмар белән Тукмар»; Батулла. «Елак әтәч»; Ә. Гаффар. «Юынмый торган Балык»; Д. Аппаковадан. «Рөстәм»; Г. Бакир. «Сания инде зур үсте»; Р. Гыйззәтуллин. «Кечкенә Ринат»; Р. Ишморатова. «Яңа чана»; Г. Лотфи. «Песнәк белән Әнисә»; Г. Бакир. «Сания бакчага бара»; Г. Хәйдәрова. «Мәдинә һәм уенчыклар»; А. Әхмәт. «Минеке, тимә»; Л. Толстой. «Варя белән Песнәк», Ә. Камал тәрҗ.; К. Ушинский. «Әтәч үзенең гаиләсе белән», Ш. Шириязданов тәрҗ., «Дару», Ф. Басыйров тәрҗ., «Бергә җайсыз, аерым күңелсез».

**Яттан өйрәнү өчен**

*Татар халык авыз иҗаты:* «Яңгыр, яу, яу...»; «Бу бармак...»; «Песи-Нечкәбил...».

*Шигырьләр:* Г. Тукай. «Гали белән Кәҗә»; Ә. Ерикәй. «Көз»; Ә. Бикчәнтәева. «Туп», «Салкын, саф һава»; Ш. Маннур. «Яратам»; Б. Рәхмәт. «Кыш бабай», «Яз»; Н. Исәнбәт. «Куянкай»; З. Туфайлова. «Әни сүзе».

**Өстәмә әдәбият**

*Җырлар, юаткычлар, эндәшләр, бармак уеннары:* «Үсеп буйга җитәр бу...»; «Песи, кая барасың?»; «Үс-үс итә...»; «Йә, сандугач, күзең ач... »; «Тук, тук, тукран...»; «Паровоз».

*Шигырьләр:* М. Фәйзуллина. «Көзге яңгыр»; Ә. Бикчәнтәева. «Йокла инде, курчагым», «Бәтиләр»; Л. Нурлы. «Әниемә бүләк»; Э. Шәрифуллина. «Син – минем нәнием»; Д. Гарифуллин. «Мыраубикә»; Җ. Тәрҗеманов. «Маэмай»; С. Сөләйманова. «Кызыл әтәч».

*Әдәби әкият һәм хикәяләр:* И. Шәймөхәммәтов. «Мактанчык бака»; М. Әмир. «Бәби әйтә»; Р. Гыйззәтуллин. «Айсылу».

## • СӘНГАТИ-ЭСТЕТИК ҮСЕШ

**Балаларда чынбарлыкның эстетик ягына карата кызыксыну уяту, сәнгатьнең төрле төрләре һәм жанрлары белән, шул исәптән халык иҗаты (сүз сәнгате, музыка, сынлы сәнгать) белән танышу, чынбарлыкның сәнгати-эстетик төрләренә җәлеп итү, балаларның үзләрен иҗади яктан күрсәтү ихтыяҗын көчәйтү, сәнгати фикерләүләрен чынга ашырганда, аларның мөстәкыйльлеген үстерү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең сәнгати-эстетик үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балаларда чынбарлыкның эстетик ягына карата кызыксыну уяту, сәнгатьнең төрле төрләре һәм жанрлары белән, шул исәптән халык иҗаты белән танышу өлкәсендә***

Балаларны сәнгать әсәрләрен эстетик яктан танып белергә өйрәтү. Көндәлек тормышта кулланыла торган предметлардагы татар кулланма сәнгатенең гади бизәкләре белән таныштыру. Халык иҗаты әсәрләренең матурлыгы белән соклану хисләре уяту.

Балаларның кул астында булган (милли киемле курчак, Шәмәрдән, Актүбә уенчыклары һ.б.) халык, декоратив-гамәли сәнгать әсәрләренә карата кызыксыну уяту. Хисси тәҗрибә тупларга, хис-кичерешләрен баетырга ярдәм итү.

Балаларга аңлаешлы хисләр чагылдырылган халык әкиятләре, татар язучылары һәм шагыйрьләренең хикәяләре, шигырьләре мотивлары буенча балалар өчен рәсемле китаплар, сынлы сәнгать әсәрләре белән танышканда, эмоциональ бәя бирүләренә ирешү.

Кече фольклор жанрлары ярдәмендә балаларда хезмәт эшчәнлеге турында кайбер күз-аллаулар формалаштыру. Баланың үз-үзенә хезмәт күрсәтүе һәм ниндидер эш башкаруы барышында татар халык мәкальләрен куллану.

***Балаларның үзләрен иҗади яктан күрсәтү ихтыяҗын үстерү, сәнгати фикерләүләрен чынга ашырганда, аларның мөстәкыйльлеген үстерү өлкәсендә***

**Сынлы сәнгать эшчәнлеге**

*Рәсем ясау*

Балаларга әйләнә-тирә табигатьнең матурлыгын (миләш тәлгәше, җиргә коела торган төрле төстәге яфраклар һ.б.) рәсемдә ничек тасвирлап булуын күрсәтү.

Балаларны декоратив эшчәнлеккә җәлеп итү: милли орнамент элементларын (ромашка, күкчәчәк, кыңгырау чәчәк, яфраклар һ.б.) буяу ысулларын күрсәтү. Сурәтләнгән предметка ярашлы төс сайлауга игътибар итү. Татар бизәкләренә хас төсләрне атый белүне ныгыту (кызыл, зәңгәр, сары, ак, кара). Бер, ике яки берничә төс кулланып, рәсем ясарга өйрәтү.

Төрле юнәлештәге сызыкларны ничек сызарга икәнен күрсәтү (озын, кыска, вертикаль, горизонталь, авыш). Төрле формалы (түгәрәк, турыпочмаклы) предметларны сурәтләргә өйрәтү. Гади сурәтләр («Казан сөлгесе», кулъяулык, тәлинкә һ.б.) ясый белүләрен үстерү.

Татар гамәли сәнгате мотивлары буенча коллектив композицияләр эшләгәндә, уртак эшчәнлек тәҗрибәсен формалаштыру.

Балаларда сынлы сәнгать эшчәнлегенә кызыксыну уяту, мөстәкыйль иҗади эшчәнлекләре өчен шартлар тудыру.

*Әвәләү*

Балчык, пластилин, тозлы камыр үзлекләре һәм әвәләү ысуллары турында күзаллауларны ныгыту, материал сайлауларын хуплау.

Сыгылмалы материалларны туры һәм әйләнмәле хәрәкәтләр белән җәяргә, түгәрәкне уч табаны белән кысып җәлпәкләндерергә, бармак белән тишек ясарга өйрәтү. Уен уйнау өчен гади формалар (коймак, кабартма, мич күмәчләре) ясау. Сыгылмалы материалларны пөхтә итеп куллана белүләрен ныгыту, камыр, пластилин кисәкләрен, әвәләнгән предметларны махсус кечкенә такталарга куярга өйрәтү.

Әвәләп ясалган предметларны коллектив композициягә берләштерү (пәрәмәчләр подноста ята, чәй сервизы һ.б.). Уртак эшчәнлек нәтиҗәсеннән шатлык хисләре уяту.

*Аппликация*

Балаларны аппликация сәнгате белән таныштыру, әлеге эшчәнлек төренә карата кызыксыну формалаштыру. Кәгазь битенә татар бизәкләренең чәчәк-үсемлек мотивлары (лалә, кыңгырау, ромашка, гөлҗимеш, миләш һ.б.) буенча төшерелгән әзер детальләрне урнаштырырга, гап-гади бизәкләрне катлаулы ритмик тәртиптә тезәргә, аннан соң аларны шакмакның уртасына, читләренә, әйләнә буйлап урнаштырырга, әзер детальләрне беркетергә өйрәтү.

Татар гамәли сәнгате мотивлары буенча индивидуаль һәм коллектив композицияләр төзергә өйрәтү. Алган белем һәм күнекмәләрне кулланып, рәсем ясау, әвәләү, аппликацияләрне берләштерү ярдәмендә сәнгатьле образлар тудырырга булышу.

Балаларны үзләре ясаган сынлы сәнгать эшләренең нәтиҗәләрен бәяләргә өйрәтү.

**Музыка эшчәнлеге**

Татар халык музыкасына, татар композиторлары тудырган музыкага карата эмоциональ бәя бирергә, аны тыңларга, аһәңен тоярга өйрәтү. Балаларның теге яки бу көйгә ирекле хәрәкәтләнүен хуплау. Курай, тальян гармун кебек музыка уен кораллары белән таныштыру, аларның яңгыраш тембрын тыңлау мөмкинлеге бирү.

Татар биюенә хас гади хәрәкәтләр белән таныштыру: «гади адымнар», «бер аяк белән тыпырдау», «ике аяк белән тыпырдау», «борма» (гадиләштерелгән вариант), «вак атлап йөрү», «бөтерелү». Биергә теләк тудыру.

Музыканы балаларның эшчәнлек төрләренә кертү. ТРның матур әдәбият һәм сынлы сәнгать әсәрләрен кулланып, интеграцияләнгән музыкаль шөгыльләр үткәрү. Баланың музыкаль-сәнгати кызыксынуларына һәм иҗади эшчәнлегенең нәтиҗәләренә ихтирам белән карау.

## МУЗЫКАЛЬ ӘСӘРЛӘРНЕҢ ЯКЫНЧА ИСЕМЛЕГЕ

### Музыка тыңлау

«Курчаклар маршы», Р. Еникиев муз.; «Әпипә», татар халык көе, Ю. Виноградов эшкәрт.; «Йокла инде, курчагым», М. Имашев муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Бишек җыры», З. Хәбибуллин муз.; «Безнең әни», Л. Шиһабетдинова муз., Ф. Рәхимголова сүз.; «Көз», Р. Еникиева муз., К. Нәҗми сүз.; «Тын бакчада», М. Мозаффаров муз.; «Яңгыр», Л. Хисмәтуллина муз.; «Ялгыз

бию», татар халык көе, А. Ключарёв эшкәрт.; «Куян биюе», «Аю биюе», «Үҗәтлек», Р. Еникиев муз.; «Кыш», Ф. Җәләлетдинова муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Буранлы көн», «Шаян әтәчләр», Ф. Шәймәрданова муз.; «Кыш бабай җыры», Л. Шиһабетдинова муз., Г.Зәйнашева сүз.; «Марш», «Урманда», И. Шәмсетдинов муз.; «Шук малай», Ә. Шәрәфиев муз.; «Шаян кыз», Н. Җиһанов муз.; «Дәү әнигә кучтәнәч», Т. Вафина муз., Ш. Галиев сүз.; «Тамчылар бии», А. Батыршин муз., З. Нури сүз.; «Яз», Р. Ахиярова муз., Г. Рахманколый сүз.; «Песи», М. Мозаффаров муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Усал малай», Р. Зарипов муз.; «Үҗәтлек», Р. Еникиев муз.; «Нәни көдрәш», Р. Ахиярова муз.; «Наза йөри бакчада», Р. Еникиев муз., Җ. Дәрзаман сүз.; «Ат булып уйнау», Х. Әхмәтов муз.; «Кәккүк җыры», Н. Зарипова муз., Г. Таһирова сүз.

**Җырлау**

*Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре:* «Чәбәк-чәбәк», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз.; «Су», Ф. Җәләлетдинова муз., Б. Рәхмәт сүз.; «Әлли-бәлли бәү», Ф. Җәләлетдинова муз., халык сүз.; «Барабан», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз. һәм сүз.; «Яңгыр, яу!», балалар фольклорыннан, Н. Бакиева эшкәрт.; «Кояш, чык!», балалар фольклорыннан, Р. Зарипов эшкәрт.; «Кәккүк», Н. Бакиева, З.Шәйхетдинова муз һәм сүз.; «Чебиләрем», Л. Шиһабетдинова муз., Җ. Дәрзаман сүз.

*Җырлар:* «Тату бармаклар», Ф. Җәләлетдинова муз., халык сүз.; «Бәйрәмгә барабыз», Г. Гыйләҗетдинова муз., Н. Бакиева сүз.; «Сәгать», Т. Вафина муз., Г. Вафина сүз.; «Көз килде», Л. Шиһабетдинова муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Әнием», Ф. Җәләлетдинова муз., Р. Гыйләҗева сүз.; «Бакчабыз», «Кышкы җыр», «Тамчылар», Г. Гәрәева муз. һәм сүз.; «Чыршы», Ф. Фәизова муз., Н. Гайсин сүз.; «Тукран», З. Гыйбадуллин муз., Р. Хафизова сүз.; «Гармун уйный», Г. Гыйләҗетдинова муз., Р. Вәлиева сүз.; «Яз килә», Ф. Шәймәрданова муз., Ш. Галиев сүз.; «Чебиләр», Л. Шиһабетдинова муз., М. Хөсәен сүз.; «Әтәчкәй», Г. Гыйләҗетдинова муз., Р. Гыйләҗева сүз.; «Ми-яу!», Л. Хисмәтуллина муз., Р. Гыйләҗева сүз.; «Мәче, кил юышырга», Р. Еникиева муз., Н. Гайсин сүз.; «Аткаем», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз., Р. Зарипов эшкәрт.; «Йомшак су, йөгерек су», Ф. Җәләлетдинова муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.

*Җыр иҗаты:* «Исемең ничек?», Ф. Җәләлетдинова муз.; «Әлли-бәлли», «Куян», Ф. Җәләлетдинова муз. һәм сүз.; «Тукран», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз., халык сүз.; «Әтәч», Ф. Җәләлетдинова муз., Г. Лотфи сүз.; «Без уйныйбыз», Ф. Җәләлетдинова муз., халык сүз.; «Урманда бәйрәм», Н. Мөхетдинова муз., Р. Вәлиева сүз.

**Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр**

*Уен күнегүләре:* «Чәбәкәй», Р. Ахиярова муз., Х. Халиков сүз.; «Йөрибез», «Ат», Ф. Шәймәрданова муз.; «Күңелле», А. Монасыйпов муз.; «Йөгердек», А. Монасыйпов муз. («Этюд»); «Марш», «Чәчәкләр белән күнегү», Л. Шиһабетдинова муз.; «Атлыйбыз һәм йөгерәбез», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз. һәм сүз.; «Куллар өчен күнегү», Л. Хисмәтуллина муз.; «Баскычтан баскычка», Р. Еникиева муз.; «Кошлар оча», И. Сафин муз.; «Марш», Ә. Шәрәфиев муз.; «Паровоз», Р. Ахиярова муз.

*Этюдларны сәхнәләштерүләр:* «Мәче балалары», Р. Зарипов муз.; «Без яулыклар юабыз», С. Сабирова муз. һәм сүз.; «Чыпчыклар», «Куяннар һәм төлке», Ф. Шәймәрданова муз.; «Аю баласы», Ә. Шәрәфиев муз.; «Самолёт», Р. Зарипов муз.; «Күрсәт әле, үскәнем», татар халык уены, Р. Еникиева эшкәрт.

*Уеннар:* «Кояш һәм яңгыр», Т. Вафина муз., Г. Вафина сүз.; «Аткаем», «Кар бөртекләре», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз.; «Шылтыравыклар белән уен», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Песи һәм чыпчыклар», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Курчак белән уен», Ф. Шәймәрданова муз.; «Аю баласы», Ф. Әбүбәкеров муз., Н. Исәнбәт сүз.; «Качышлы уены», татар халык көе, Ф. Җәләлетдинова эшкәрт.; «Кыңгырау», Т. Вафина муз., Ф. Миңнебаева сүз.; «Күңелле поезд», З. Ибраһимова муз., Г. Юнысова сүз.

*Түгәрәк уеннары һәм биюләр:* «Нәниләр», «Кыш бабай белән күмәк җыр», Ф. Шәймәрданова муз., М. Әндерҗанова сүз.; «Көз белән балалар җыры», Г. Гәрәева муз. һәм сүз.; «Яфраклар белән бию», Т. Вафина муз.; «Шылтыравыклар белән бию», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Курчаклар белән бию», Ф. Шәймәрданова муз.; «Бөтерчек», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Кыю бас», Н. Бакиева муз. һәм сүз.; «Бию», татар халык көе, Ф. Җәләлетдинова эшкәрт.; «Парлы бию», татар халык көе, Ф. Җәләлетдинова эшкәрт.; «Төсле яулыклар», татар халык көе, Р. Гатина, Ф. Батыршина сүз., Р. Еникиева эшкәрт.; «Татарча бию», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Дусларым бар», Л. Хисмәтуллина муз. һәм сүз.; «Болында», татар халык җыры, Ф. Җәләлетдинова эшкәрт.; «Кара-каршы бию», Ф. Фәизова муз.; «Без җиләккә барабыз», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.

*Характерлы биюләр:* «Гөмбәләр биюе», Г. Гыйләҗетдинова муз. һәм сүз.; «Кар бөртекләре оча», Р. Гыйләҗева муз. һәм сүз.; «Куяннар биюе», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Фонарьлар», Ф. Шәймәрданова муз. һәм сүз.; «Чәчәкләр биюе», Ф. Фәизова муз.

*Биюле уен иҗаты:* «Әпипә», татар халык көе, Р. Еникиева эшкәрт.; «Куяннар биюе», Л. Хисмәтуллина муз.; «Кырдан килә Кыш бабай», Ф. Шәймәрданова муз., И. Сәлахова сүз.; «Курчак», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Парлы бию», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.

**Музыкаль-дидактик уеннар**

*Музыкада аваз югарылыгын ишетү сәләтен үстерү:* «Кош һәм кошчыклар»; «Аю белән курчак бии», татар халык көе, Р. Тимершина эшкәрт.

*Ритмны тою сәләтен үстерү:* «Курчак нишли?»; «Урман буйлап кем килә?»; «Тычкан һәм аю».

*Тембрны аера белү һәм динамик төсмерләрне ишетү сәләтен үстерү:* «Нәрсәдә уйныйм?» (барабан, шөлдерле барабан, шылтыравык); «Зур һәм кечкенә кыңгырау»; «Бу өйдә кем яши?»; «Атта», Ф. Әхмәтов муз.

*Жанрны аера белү һәм музыкаль хәтерләрен үстерү:* «Безгә кунаклар килде («Кошчык», «Аю», Ф. Җәләлетдинова муз.); «Тылсымлы капчык».

**Бәрмә музыка уен коралларында уйнау**

«Әпипә», татар халык көе, Р. Еникиева эшкәрт.; «Бәллү», Р. Ахиярова муз.; «Әнисә», татар халык көе, Р. Еникиева эшкәрт.; «Шома бас», татар халык көе, Р. Еникиева эшкәрт.; «Кура җиләк», Л. Шиһабетдинова муз., Н. Арсланова сүз.

**Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәре**

*Сәхнәләштерү һәм музыкаль спектакльләр:* «Песи һәм чыпчыклар», «Без җиләккә барабыз», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Аткаем», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз.; «Куян кызы», А. Алиш; «Күңелле поезд», З. Ибраһимова муз., Г. Юнысова сүз.

*Курчак театры:* «Зилә бакчага бара», З. Хөснияр; «Кем нәрсә ярата?», «Төлке белән каз» (татар халык әкиятләре); «Җиләккә барганда», Җ. Тәрҗеманов.

*Әдәби-музыкаль композицияләр:* «Уенчыклар кибете»; «Яшелчә бакчасында»; «Әбинең ишек алды»; «Яз килә, кояш көлә»; «Дәү әнидә кунакта»; «Аюның туган көне»; «Светофор».

*Бәйрәмнәр:* «Чыршы бәйрәме», «8 Март – әниләр бәйрәме».

## • ФИЗИК ҮСЕШ

**Балаларда сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен булдыру, аларда үзләренең гәүдә төзелеше һәм физик мөмкинлекләре турында күзаллауларны үстерү, хәрәкәтләр тәҗрибәсе булдыру һәм хәрәкәт активлыгын камилләштерү, спортның кайбер төрләре турында күзаллаулар формалаштыру, кагыйдәле хәрәкәтле уеннарга өйрәтү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең физик үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балаларда сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен булдыру өлкәсендә***

Культура-гигиена процедураларын башкару алгоритмы белән таныштыру. Балаларны аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә гигиена процедураларын башкарырга өйрәтү: сабынны дөрес итеп кулланырга, пөхтә итеп кулларны сабынларга, битне, колакларны юарга, юынгач сөртенергә, сөлгене урынына эләргә, тарак, кулъяулык кулланырга. Гигиена күнекмәләрен үтәү ихтыяҗын формалаштыру.

Табында үз-үзеңне дөрес тоту күнекмәләрен булдыру: сыек ризык ашаганда, кашыкны дөрес тотарга, аш һәм чәй кашыкларын, чәнечкене дөрес кулланырга, ипи-күмәч ише ризыкларның валчыкларын коймыйча ашарга, ризыкны авызны ябып чәйнәргә, өстәл яныннан киткәндә рәхмәт әйтергә.

Милли ризыклар һәм эчемлекләр белән таныштыру: токмачлы аш, шулпада пешкән пилмән, чумар, сөтле чәй (куе сөт белән) һ.б. Милли ризыкларны ашау үзенчәлекләре белән таныштыру, аларның бала организмы өчен файдасын аңлату.

Сөт ризыкларының (каймак, катык, эремчек), яшелчә, җиләк-җимеш, яшел тәмләткеч үләннәрнең кеше организмы өчен файдасы турында сөйләү. Файдалы һәм зыянлы ризыклар турында күзаллау булдыру, сәламәт туклану турында элементар кагыйдәләр үтәргә ярдәм итү.

Балага үзен ничек хис итүенә, өс киеменә, аяк киеменә (юеш аяк киеменнән, юеш өс киеменнән йөрмәскә һ.б.) игътибар итәргә кирәклеген аңлату. Баланы үзенең һәм якын кешеләренең сәламәтлегенә карата җаваплы һәм сак карарга өйрәтү.

Сәламәт яшәү рәвешенең файдасын аңларга ярдәм итү.

***Балаларның хәрәкәт активлыгын камилләштерү, аларда үзләренең гәүдә төзелеше һәм физик мөмкинлекләре турында күзаллауларны үстерү, спортның кайбер төрләре турында күзаллаулар формалаштыру, кагыйдәле хәрәкәтле уеннарга өйрәтү өлкәсендә***

Белем бирү оешмасының тибын һәм төрен, булган шартларын, төркемнең тулылыгын, балаларның физик үсеше һәм сәламәтлекләре үзенчәлекләрен, шулай ук төбәкнең климат һәм сезон үзенчәлекләрен искә алып, бала организмын системалы рәвештә чыныктыру өчен шартлар тудыру. Балаларның физик һәм психик сәламәтлеген саклау һәм ныгыту.

Хәрәкәт активлыгы, шул исәптән мөстәкыйль хәрәкәтләнү өчен шартлар тудыру.

Балаларның хәрәкәткә булган табигый ихтыяҗларын канәгатьләндерү. Балаларга өч тәгәрмәчле велосипедта турыга, түгәрәк буенча һәм борылышлар ясап йөрү мөмкинлеге булдыру.

Балаларда, хәрәкәтләрне һәм кагыйдәләрне үзгәртеп һәм катлауландыра барып, татар хәрәкәтле уеннарын уйнарга теләк уяту.

## ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР ИСЕМЛЕГЕ

***Йөрүле һәм йөгерүле уеннар.*** «Минем яныма йөгерегез!», «Песи һәм тычканнар», «Маэмай», «Флагка таба йөгерегез», «Төлке һәм тавыклар», «Күңелле сыерчыклар», «Атлар», «Такси», «Түгәрәктә».

***Сикерүле уеннар.*** «Инеш аша үтәбез», «Күбәләкне тот!», «Песи һәм чыпчыклар», «Түмгәктән түмгәккә».

***Шуышулы һәм үрмәләүле уеннар.*** «Тавык һәм чебиләр», «Йорт куяннары».

***Тупны тәгәрәтү һәм тотып алу уеннары.*** «Туплар», «Кызыл, зәңгәр...», «Капкага керт!», «Тот, ыргыт, төшермә!».

***Тирәлектә ориентлашу уеннары.*** «Чыпчыклар һәм автомобиль», «Трамвай», «Үз төсеңне тап!», «Үз өеңне тап!».

***Аз хәрәкәтле уеннар.*** «Уенчыкны сакла!», «Куык», «Кошчыклар», «Флагны тап!».
***Татар халык уеннары.*** «Коймак», «Күз бәйләш».
***Рус халык уены.*** «Аю урманында».

## УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ

(4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

### • ИҖТИМАГЫЙ-КОММУНИКАТИВ ҮСЕШ

**Балада үзенә һәм башкаларга карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү, коммуникатив һәм иҗтимагый, шул исәптән мәгълүмати-иҗтимагый компетентлыкны, уен эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең иҗтимагый-коммуникатив үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балада үзенә һәм башкаларга карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү өлкәсендә***

Балада үзе, ата-анасы турында күзаллау формалаштыру. Гаилә фотосурәтләрен караганда, аның әти-әнисе белән охшаш якларына игътибар итү. Фотодагы кешеләрнең эмоциональ халәтен билгеләргә, аларның кәефен гаилә тормышындагы аерым бер вакыйгалар белән бәйләргә өйрәтү.

Балада гаилә, аның милли составы, үзенең әлеге гаилә әгъзасы булуы, гаилә әгъзаларының һәм баланың гаиләдәге бурычы, мәнфәгатьләре, кызыксынулары, ял итү турындагы күзаллаулар формалаштыру. Гаилә кыйммәтләренә сакчыл караш тәрбияләү.

Балада ата-анасының бала чагындагы вакыйгалары, аларның яраткан уен һәм уенчыклары, баланың мавыгуларына һәм хисләренә туры килә торган иң кызыклы балачак мизгелләре белән кызыксынуны хуплау. «Балачак» төшенчәсен аңларга булышу.

***Коммуникатив һәм иҗтимагый, шул исәптән мәгълүмати-иҗтимагый компетентлыкны үстерү өлкәсендә***

Баланың, табигать һәм социаль дөнья, туган шәһәрендәге (авылындагы), республикадагы вакыйгалар турындагы күптөрле мәгълүмат чыганагы буларак, өлкән кеше белән аралашуга ихтыяҗын хуплау.

Туган телдә аралашу инициативасын хуплау, башка кешеләрнең аралашу теләгенә әдәпле җавап бирү, төрле эшчәнлек вакытында өлкәннәр һәм балалар белән вербаль һәм вербаль булмаган элемтәләр урнаштыру. Әңгәмәдәшен кызыксындырган темага әңгәмә кора, сөйләшү темасын дәвам итә белүне үстерү.

Башка телдә сөйләшүче кешеләрнең мәдәниятенә һәм гадәтләренә карата кызыксыну уяту, тыңларга өйрәтү. Рус телендә башлангыч дәрәҗәдә аралашырга, сөйләм теленең беренчел күнекмәләрен үзләштерергә булышу. Телне тоемлау сәләтен үстерү.

Милләтара аралашу культурасын (әңгәмәдәшенең нинди милләттән булуына бәйле рәвештә, матур итеп исәнләшү һәм саубуллашу, күрсәтелгән ярдәм, сый өчен рәхмәт әйтү, гафу үтенү, тәкъдим, үтенеч белән әдәпле итеп мөрәҗәгать итү) формалаштыру.

Баланы гадәти булмаган тормыш хәлләрендә зур саклык белән эш итәргә, таныш түгел кешеләр белән очрашканда сак булырга өйрәтү. Таныш түгел кешеләр белән элемтәләрне чикли торган кагыйдәләр белән таныштыру.

Балаларны балалар бакчасының туган көнен, шәһәрнең (авыл, бистә) истәлекле даталарын бәйрәм итүгә җәлеп итү. Балалар бакчасы, шәһәр (авыл, бистә) тормышында катнашудан шатлык, канәгатьлек хисләре кичерүенә ирешү.

Балалар бакчасының көндәлек режимы, үз-үзеңне әдәпле тоту кагыйдәләре һәм бинада хәрәкәт иткәндәге элементар куркынычсызлык таләпләре белән таныштыруны дәвам итү.

Балаларга артык ашауның, сыйфатсыз ризыклар белән туклануның, витаминнарны, даруларны күпләп куллануның зарары турында сөйләү. Сәламәт туклану культурасын үстерү.

***Уен эшчәнлеген үстерү өлкәсендә***

Бу төбәктә яшәүче халыкларның тормыш-көнкүрешеннән, татар язучылары, шагыйрьләре әсәрләре мотивлары, мультфильм күренешләреннән алынган темалар буенча уен өчен катлаулы булмаган сюжетлар тәкъдим итү.

Баланың яшьтәшләре белән рольләр һәм партнёрлык мөнәсәбәтләре дәрәҗәсендә аралашуын оештырырга булышу, аның уен өчен йорт кирәк-яраклары (көянтә-чиләкләр, казан, уклау һ.б.), кием-салым (милли костюм, зәркән бизәнү әйберләре, читек һ.б.), халык уенчыклары, музыка уен коралларын сайлап ала һәм рольгә ярашлы рәвештә аларны куллана белүен хуплау.

LEGO DUPLO, LEGO Classic конструкторларын кулланып, корылмалар, шәһәр (авыл) урамнары, юллары макетларын төзергә тәкъдим итү. Объектларның урынга бәйле характеристикаларының, аларның озынлыкларының төрле булуына, детальләрнең урынын (өстән, астан, өстә, аста) билгеләүгә балаларның игътибарын җәлеп итү. Тимер юл, ике яклы хәрәкәт булган юлларны, күпер, гараж һ.б.ны ясау омтылышын хуплау. Ясалган конструкциянең уен сюжеты һәм телдән тасвирлау белән бәйләнешен булдыру.

Балаларның уенда мөстәкыйльлеген, рольләргә бүлешеп, туган (татар) телендә диалог төзүләрен, тормышчан вакыйгаларга туры китерергә тырышып уйнауларын актив хуплау.

Театральләштерелгән уеннарда һәм режиссёр уеннарында милли киемдәге курчакларны, образлы уенчыклар, бибабо, кулдан ясалган уенчыкларны һәм ишарә, мимика, интонация кебек кайбер сәнгать ысулларын кулланып, катлаулы булмаган сюжетлар (татар халык әкиятләре мотивлары буенча ясалган мультфильмнардан) буенча ситуацияләрне уйнап күрсәтү.

Халык уенчыклары, курчак театры персонажлары, музыка уен коралларына (курай, гармун һ.б.) өстенлек биреп, ял итү уеннары, төрле киемнәр киенеп уйнау, күңел ачу уеннары оештыру.

Бәйрәм-карнавал уеннары, Сабан туе, Карга боткасы кебек теге яки бу ел фасылына бәйле бәйрәмнәргә караган уеннар уздыру, өлкәннәр һәм балалар арасында бердәмлек тойгысын үстерү.

## • ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ

**Баланың кызыксынучанлыгын, танып белү активлыгын, танып белү сәләтләрен үстерү өчен шартлар тудыру, әйләнә-тирә чынбарлык турында белемнәрнең төрле юнәлешләре буенча күзаллауларны баету белем бирү эшчәнлегенең танып белү үсеше өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Кызыксынучанлыкны, танып белү активлыгын, танып белү сәләтләрен үстерү өлкәсендә***

Кешенең яшәү урыны (шәһәрдә, авылда), йорт кирәк-яраклары турында күзаллауларын үстерү. Яңа нәрсә турында белү, кеше кулы белән ясалган төрле җайланмаларның билгеләнеше һәм ничек эшләнгәнлеге турындагы сораулар бирү омтылышын уяту.

Үз-үзен, йорт-җирен, йорт хайваннарын һәм үсемлекләрен, транспортын кайгыртып торучы, ишегалдын, урамны тәртиптә тотучы кешенең хуҗалык эшчәнлеге турында беренчел күзаллауларны формалаштыру. Үз гамәлләренең нәтиҗәсенә һәм мәгънәсенә дөрес бәя биреп, торган йорты, туган шәһәре (авылы) урамнарын тәртиптә тоту теләге уятуга, белемнәрне арттыруга этәргеч бирү.

Әйләнә-тирә табигать объектларын: агачлар (нарат, өрәңге), гөмбәләр (майлы, ак гөмбә), чәчәкләр (ромашка, күкчәчәк), бүлмә гөлләрен (бальзамин, фуксия) өйрәнү тәҗрибәсен арттыру, танып белү мотивациясен формалаштыру.

Җиләк-җимеш (груша, слива), яшелчә (кыяр, помидор, суган), җиләкләр (кура җиләге, миләш, карлыган), аларның сыйфатлары (эре, вак, шома, сусыл, әче, баллы һ.б.) белән танышуны дәвам итү. Җимешләрне сортларга аерырга, аларны чагыштырырга өйрәтү, уңыш җыйган вакытта өлкәннәргә булышу теләге уяту.

Бөҗәкләр (кырмыска, бал корты, төклетура, коңгыз) турындагы күзаллауларны киңәйтү, балаларның мөстәкыйль күзәтүләрен, беренче ачышларын хуплау: бал кортлары, күбәләк, төклетуралар чәчәкләр күп үскән урыннарда ешрак оча.

Йорт һәм кыргый хайваннар, төркемдәге табигать (тере почмакта) почмагында яшәүчеләр белән танышуны дәвам итү. Табигатьтә очрый торган иң гади элемтәләр (кайбер хайваннар урманда яши, икенчеләре – елга-күлләрдә, өченчеләре – кыр һәм болыннарда) турындагы күзаллауларны формалаштыру.

Участокка очып килгән кошларны, аларның үз-үзен тотышларындагы үзенчәлекләрен (чыпчыклар чыркылдый, ризык эзләп оча, сикерә, күгәрченнәр гөрли, горур кыяфәттә йөри) күзәтү, кошларны куркытмаска өйрәтү, ел әйләнәсендә кошларны ашатасы килү теләге тәрбияләү.

Табигатьтә сезонлы үзгәрешләр турында күзаллауларны үстерү, балалардан җәен (кышын, көзен, язын) кырда, болында, елгада, урманда нәрсәләр күрүләре турында сөйләтү. Үзләренә ошаган үсемлек, хайван рәсемен ясау, фотога төшерү теләге уяту.

Балаларны хайваннар белән очрашканда сак булырга өйрәтү, агулы үсемлекләрнең сыйфатлары (үзлекләре) турында кисәтү.

***Әйләнә-тирә чынбарлык турында белемнәрнең төрле юнәлешләре буенча күзаллауларны үстерү өлкәсендә***

Милли мәдәниятнең кайбер атрибутлары (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли ризыклар, кием, савыт-саба, музыка уен кораллары) турында күзаллауларны формалаштыру, бу атрибутларны сакларга өйрәтү.

Балаларны республика, аның башкаласы, туган шәһәре (авылы, бистәсе), үзе яши торган урамның исемен әйтергә өйрәтү. Аларга шәһәрнең (авылның) истәлекле урыннары турында сөйләү.

Балага туган шәһәрендә барган вакыйгалар турындагы әңгәмәләрдә катнашу тәҗрибәсе тупларга булышу. Открыткалар, значоклар, истәлекле урыннарда гаилә белән төшкән фотолар җыюны, туган як образы белән бәйле рәсемле альбомнар, китаплар, журналлар туплауны хуплау.

Татар халык әкиятләре («Дүрт дус», «Песәй» һ.б.) ярдәмендә өлкәннәрнең хезмәт эшчәнлеге турындагы күзаллауларын үстерү. Баланың эш-гамәлләрен татар шагыйрьләренең шигъри юллары (Ж. Тәрҗеманов. «Таякка атланып»; Ш. Маннур. «Күгәрченнәр гөрли» һ.б.) белән бәйләп алып бару.

Кешенең ел әйләнәсе табигать белән бәйле булуы, аның сезонлы эшләр башкаруы (кырда арыш, бодай чәчә, бәрәңге утырта, болында печән чаба, ишегалдында кар көри һ.б.) турында күзаллауларны арттыру. Туган җиргә тугрылык хисе формалаштыру.

Өлкәннәрнең һөнәри эшчәнлеге турындагы белемнәрне арттыру: трамвай йөртүче пассажирларны билгеләнгән маршрут буенча йөртә, кар җыю машинасын йөртүче юлның транспорт йөри торган өлешен кардан чистарта, ЮХИДИ инспекторы шәһәр урамында автомобильләр хәрәкәтен көйли һ.б.; өлкәннәрнең эшчәнлеге шәһәр халкын кайгыртуны күздә тотканлыгына балаларның игътибарын юнәлтү.

Балаларның шәһәр җәмәгать транспорты (троллейбус, автобус, трамвай) турындагы күзаллауларын баету. «Автобус (троллейбус, трамвай) тукталышы урыны» юл билгесе буенча маршрут транспорты тукталышы урынын билгеләргә, якын-тирәдәге тукталышларның исемнәрен атарга өйрәтү. Шәһәр җәмәгать транспортына утыру һәм аннан чыгу кагыйдәләре белән таныштыру.

Балалар белән бергә тимер юл макетын карау, машинист хезмәте турында сөйләү. Казан шәһәрендәге метрополитен, аның үзәгендә урнашкан «Тукай мәйданы» станциясе белән таныштыру, аның фотоларын карау, бизәлешендәге милли колоритка (Г. Тукай әсәрләрендәге геройлар һәм темалар сурәтләнгән 22 мозаика панносы, шагыйрьнең портреты) игътибар итү. Мәдәни кыйммәтләрне куллану өчен киң мөмкинлекләр булуы турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Хәрәкәт итүнең чагыштырма тизлеген (тиз, әкрен) билгеләү күнекмәсен үстерү; транспорт чараларының (трамвай, автобус, янгын сүндерү машинасы, ашыгыч ярдәм машинасы һ.б.) тавыш сигналларын аеру; тавыш чыганагының урынын билгеләү, кирәк булганда туктап калырга өйрәтү. Светофор сигналларына туры килгән гамәлләрне баланың үзе тарафыннан ачыклатып кабатлау.

## • СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ

**Сөйләм һәм тел культурасы нигезләрен формалаштыру, баланың сөйләм телен төрле яктан камилләштерү, матур әдәбият әсәрләрен уку культурасына җәлеп итү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең сөйләм үсеше өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Баланың сөйләм телен төрле яктан камилләштерү өлкәсендә***

Милли мәдәният һәм аралашу чарасы буларак туган (татар) телен үстерү өчен шартлар тудыру.

Балаларны тел мохитенә кертү, татар телен белү чикле булганда, баланың коммуникатив сәләтен үстерергә булышу, телне тоемлавын арттыру, тел күренешләрен үзара чагыштыруга карата кызыксынуны хуплау, татар телен үзләштерергә мотивлаштыру.

Балаларга «Татармультфильм» берләшмәсе мультфильмнарын, балалар һәм яшьләр өчен оештырылган «Яшь ТНВ» телеканалында барган «Күчтәнәч» тапшыруларын карау, җырлар тыңлау һәм туган (татар) телен чикле белгән шартларда да канәгатьлек алу мөмкинлеге тудыру. Сөйләм культурасы нигезләрен салу.

Максатчан өйрәтү һәм үстерү процессында проектлаштыру технологиясен, уен һәм мәгълүмат-коммуникация технологияләрен, уен ситуацияләрен, дидактик инструментарийларны, аудио- һәм видеоматериалларны, анимация сюжетларын куллану. Баланың сөйләм үсеше дәрәҗәсен исәпкә алып, аның коммуникатив сәләтен үстерү.

Диалог алып бара, үзенә мөрәҗәгать иткәнне аңлый белү һәм, аралашу вазгыятенә туры килә торган сүзләр кулланып, мөрәҗәгатькә дөрес җавап бирү күнекмәләрен үстерү. Балаларның диалогта катнашуын, әңгәмәдәше белән диалог алып баруларын хуплау.

Баланың яшьтәшләре белән туган (татар) телендә дустанә аралашуына булышу, диалогны ничек дәвам итәргә, сорауларны ничек дөрес итеп бирергә һәм аларга ничек җавап кайтарырга, әңгәмәдәшен игътибар белән тыңларга кирәклеген җай белән әйтеп җибәрү.

Уен ситуацияләре булдыру, балалар эшчәнлегенең төрле төрләрендә (уен, аралашу, эшчәнлекнең продуктив төрләре) аралашу ситуацияләрен тудыру юлы белән баланың инициативасын, мөстәкыйльлеген хуплау, аның дөрес итеп сөйләп бирә, конкрет ситуациягә ярашлы рәвештә үз фикерен әйтә белүен үстерү.

Бала өчен гадәти әйләнә-тирә мохиткә хас булмаган предметлар, күренешләр, вакыйгалар турында өлкәннәр белән аралаша белүен формалаштыру.

Туган (татар) телдә актив сүзлек запасын, сүзләрне дөрес аңлауны һәм куллануны үстерү. Ачык күрсәтмә мәгълүматка таянып һәм/яки таянмыйча, сүзлек запасын иркенле куллануга этәрү.

Сузык һәм тартык авазларның дөрес әйтелешен төгәлләштерү һәм ныгыту, туган (татар) телендәге барлык авазларны дөрес әйтүгә ирешү. Балалар тарафыннан сүзгә аваз анализы ясауның башлангыч күнекмәләрен үзләштерелүенә ярдәм итү: беренче авазны интонация белән ассызыклап, сүзләрне мөстәкыйль рәвештә әйтә белергә өйрәтү.

Татар халык әкиятләре буенча рәссам-иллюстратор Ф. Хәсьянова рәсемнәрен караганда, кызыксындырган күренешләргә бәйле сораулар бирүне хуплау, кыска хикәя (2–4 җөмлә) формасында сөйләүне һәм фикер белдерүне активлаштыру.

Баланың бәйрәмдә шигырь сөйләргә омтылуын хуплау, интонацион сәнгатьле сөйләү нигезләрен салу. Булачак вакыйганы көтү шатлыгы хисен татырга мөмкинлек бирү.

Рус телендә беренчел коммуникацияне үзләштерү өчен шартлар тудыру, «Изучаем русский язык» укыту-методик комплексын куллану. 200 сүздән дә ким булмаган сүзлек запасы туплау, сөйләм телен мәгънәле эчтәлек белән баету.

Сораулар аша уенчыкларны, рәсемнәрне, предметларны эзләп табарга кызыксыну уяту. Предметның атамасы, эш-хәрәкәте һәм сыйфатларын рәсемнәре белән чагыштыруларны кабатлау. Баланың биремне мөстәкыйль үтәвен, яңа сүзләрне кулланырга омтылуын хуплау.

Рус телендә җөмләләр төзергә, сүзләрне төрләндерергә (сан, род, килеш, заманын үзгәртү), төрле структурадагы җөмләләрдә аларны яраштырырга булышу.

Балалар белән сүзләрне татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү күнегүләре ясау, хәтерне активлаштыру.

Киләчәктә педагогик гамәлләрне оптимальләштерү максатыннан, аларның нәтиҗәлелеген бәяләүгә бәйле рәвештә балаларның сөйләм үсешен күзәтү системасын булдыру.

***Балаларны әдәби әсәрләрне уку культурасына җәлеп итү өлкәсендә***

Төрле жанр һәм тематикага (әкият, татар язучылары һәм шагыйрьләренең хикәя һәм шигырьләре) караган әдәби телне тыңлау һәм кабул итә белү, эчтәлеккә карата хис-тойгыларын белдерү сәләтен үстерү. Балаларның өлкәннәргә китап укуларын сорап мөрәҗәгать итүләрен хуплау.

Баланың эчке дөньясын әкият геройлары һәм аларның характерлары, чынбарлыктагы вакыйгалар, өлкәннәр һәм балаларның гамәлләре турындагы күзаллаулар белән баету, укыганны аңлауларын тикшерү максатыннан сораулар бирү. «Бала» тавышлы интерактив мультимедиа китапханәсе материалларын куллану.

Балаларда әдәби әсәрләрдәге геройларга карата борчылу, кайгыртучанлык кебек тойгылар тәрбияләү, үзләренең һәм яшьтәшләренең тәртипләренә бәя биргәндә ориентлашыр өчен, поэтик фольклорның кече формаларын, халык әкиятләрен куллану.

Татар әкиятләреннән кечкенә генә өзекләрне сәхнәләштерү. Укылган әсәрләрнең иң кызыклы, тәэсирле өзекләрен истә калдырырга ярдәм итү, моның өчен балаларга сүзләрне һәм кабатлау өчен авыр булмаган җөмләләрне әйтеп бетерергә мөмкинлек тудыру.

Хәзерге заман татар шагыйрьләренең шигырьләрен, татар фольклорының кече формаларын яттан сөйләүне хуплау. Шигырьне истә калдыру, ятлау сәләтен үстерү.

Балаларга китапның рәсемнәрен кабат мөстәкыйль карап чыгу мөмкинлеге бирү. Уен, сурәтләү, конструкцияләү һ.б. эшчәнлекне әдәби образлар белән баету.

Ата-анага өйдә бала өчен китап уку системасын оештыруда, Г. Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачылар театрының балалар өчен куелган спектакльләре («Бәхетле көнем», «Сәлам, Актәпи» һ.б.) белән беренчел танышуда булышу.

## ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ӘСӘРЛӘР

**Балаларга уку өчен**

***Җырлар, юаткычлар, эндәшләр, бармак уеннары:*** «Тыпыр-тыпыр биидер...»; «Карга әйтә: кар-кар»; «Кояшкаем, чык, чык...»; «Кәк-күк, кәк-күк...»; «Бас, кызым, эзенә...»; «Карга килә – казан аса...»; «Чума үрдәк, чума каз…»; «Әй чулпысы, чулпысы…»; «Болыт, болыт, килмә син…»; «Олыга – утын ярырга»; «Ябалак, ябалак…»; «Камка түти, кач, кач...»; «Утыр, балам, ашарга…».

***Әкиятләр:*** «Ата каз», «Ике ялкау», «Хәйләгә каршы хәйлә», «Аю белән Бабай», «Ябалак», «Балыкчы аю», «Карт белән Төлке», татар халык әкиятләре; «Йомры күмәч», рус халык әкияте; «Аю балалары һәм Төлке», «Комсызлык бәласе», венгр халык әкиятләре; «Ялкау аю», «Бөдрә чәчле кыз», чукча халык әкиятләре; «Тавык белән Сарык», болгар халык әкияте.

***Шигырьләр:*** Г. Тукай. «Көз», «Бу кайсы вакыт?»; Л. Лерон. «Яфрак бәйрәме»; Р. Мәннан. «Нәрсә ул җил?»; Ә. Кари. «Кыш», «Кошлар туйдырам»; Г. Толымбай. «Буран»; Н. Мадьяров. «Шуабыз»; Р. Корбан. «Оекбаш»; К. Булатова. «Солдатлар»; Р. Миңнуллин. «Туган илнең улы мин»; С. Сөләйманова. «Әниләр бәйрәме»; Ф. Кәрим. «Яз җитә»; С. Маршак. «Апрель», «Май», М. Мазунов тәрҗ.; Ф. Тютчев. «Май аенда», Ә. Ерикәй тәрҗ.; А. Барто. «Кишер суы», Ә. Юныс тәрҗ.; Р. Бәшәр. «Светофор»; Р. Арсланова. «Светофор тора сакта», «Җәй»; Я. Игәнәй. «Чебиләр сөенделәр»; Б. Рәхмәт. «Бакчага килгәч», «Уенчыклар»; Р. Вәлиева. «Уяталар»; Н. Гайсин. «Гөлсия»; З. Туфайлова. «Нәни ташчылар»; Х. Халиков. «Хәерле иртә».

***Әдәби әкиятләр һәм хикәяләр:*** Хәйдәр. «Керпе туны»; Батулла. «Аю Әппәс», «Шапшакларны бака ялый»; А. Алиш. «Бикбатыр белән Биккуркак», «Эшче абый»; С. Сәүбанова. «Шифалы сөт»; Р. Вәлиева. «Кыңгырау чәчәк»; Ә. Гаффар. «Койрык»; Г. Тукай. «Җил белән Кояш»; К. Насыйри. «Комсыз эт» (мәсәл); Л. Толстой. «Кырмыска белән Күгәрчен» (мәсәл), «Зирәк чәүкә»; Ә. Бикчәнтәева. «Тәмле сүз»; З. Хөснияр. «Куян күчтәнәче, яки Тешсез малай»; М. Гафури. «Әби белән онык»; Ф. Садриев. «Ботка»; Ә. Хәсәнов. «Балалар бакчасында»; И. Нәбиуллина. «Курчак»; А. Толстой. «Төлке белән Кысла», Ә. Еники тәрҗ.; В. Бирюков. «Мактанчык песи баласы»; К. Ушинский. «Хайваннар бәхәсе», «Тавык һәм үрдәк бәбкәләре», И. Ширияздановтәрҗ.; В. Осеева. «Бер әби», А. Лотфуллина тәрҗ.

**Яттан өйрәнү өчен**

*Татар халык авыз иҗаты:* «Тук, тук, тукран», «Бас, кызым Әпипә», «Ак калач», «Яңгыркаем, яу, яу!».

*Шигырьләр:* К. Нәҗми. «Көз»; Г. Тукай. «Бу кайчак була?», «Бу кайчак, туган?»; Җ. Тәрҗеманов. «Йомшак су, йөгерек су», «Кыш»; М. Фәйзуллина. «Кыш бабай»; Ә. Рәшит. «Кояшлы ил».

**Өстәмә әдәбият**

*Җырлар, юаткычлар, эндәшләр, бармак уеннары:* «Әтисенә ай кебек...»; «Әби коймак пешерә»; «Ай диләр, вай диләр…»; «Карга килә – казан аса…»; «Биесен лә, биесен»; «Кәккүк, чыпчык»; «Алтын, алтын, алтыным».

*Әкиятләр:* «Тавык, тычкан һәм көртлек», татар халык әкияте; «Кәҗә бәтие, Бәрән һәм Бозау», абхаз халык әкияте; «Төлке белән Аю», мари халык әкияте.

*Шигырьләр:* Р. Вәлиева. «Яз», «Бәхетле көн»; Ш. Галиев. «Дәү әнигә күчтәнәч», «Тыныч йокы», «Светофорның өч сүзе»; Р. Арсланова. «Бәйрәмдә», «Әниемне яратам»; М. Садри. «Һаҗирә апа»; М. Хөсәен. «Пескәем»; Ә. Бикчәнтәева. «Минем әнием»; М. Сөндекле. «Гүзәл».

*Әдәби әкиятләр һәм хикәяләр:* Г. Гомәр. «Чуар тавык»; Батулла. «Әйлән-бәйлән уены»; З. Гомәрова. «Уйныйсы килә»; С. Сәүбанова. «Кар бабай кая киткән?».

## • СӘНГАТИ-ЭСТЕТИК ҮСЕШ

**Балада чынбарлыкның эстетик ягына кызыксынуны үстерү, сәнгатьнең төрле төрләре һәм жанрлары (сәнгатьле сүз, музыка, рәсем сәнгате), шул исәптән халык иҗаты белән таныштыру, сәнгати-эстетик чынбарлыкның төрле төрләренә җәлеп итү, үзен иҗади яктан таныту, сәнгать идеяләрен чынга ашыруда инициатива һәм мөстәкыйльлек күрсәтү ихтыяҗын үстерү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең сәнгати-эстетик үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балада чынбарлыкның эстетик ягына кызыксынуны үстерү, сәнгатьнең төрле төрләре һәм жанрлары, шул исәптән халык иҗаты белән таныштыру өлкәсендә***

Халык һөнәрчелеге, татар декоратив-гамәли сәнгате предметларын караганда, эстетик хис-кичерешләрне чагылдыра белүне хуплау.

Сынлы сәнгать музеена баруны (ата-аналар белән берлектә) оештыру. Иҗат әсәрләрен сәнгати кабул итә, образларны эзлекле рәвештә карый, сурәткә карата хис-тойгыларны әйтеп бирә, рәсемне үз тәҗрибәләре белән чагыштыра белүләрен үстерү.

Балаларны традицион татар костюмы (бертөсле иркен күлмәк, бәрхет камзул, бизәкле күкрәкчә, киң ыштан, чигүле алъяпкыч, калфак, бизәкле күн читек яисә чүәк, түбәтәй һ.б.) белән таныштыру. Балаларның игътибарын милли киемдә тегү, туку, чигешнең төрле төрләре, бизәнү әйберләре һәм күн мозаикасы чагылыш табуына юнәлтү. Заманча киемдә дә кайбер шундый элементларны табарга булышу.

«Сәнгати нәфис керамика», «рәссам», «рәссам-керамика остасы», «чүлмәкчелек һөнәре» төшенчәләре белән таныштыру. Балаларга аңлаешлы формада чүлмәкче иҗатының үзенчәлеге («зоодиңгез» керамикасы – төрле кош һәм җәнлекләр сурәтләнгән савытлар, сыбызгы формасындагы балалар уенчыклары, Питрәч керамика һөнәрчелеге) турында сөйләү.

«Архитектура» (балалар бакчасы, мәктәп, китапханә, цирк, курчак театры – барысы да архитектура корылмалары) төшенчәсе белән таныштыру. Төрле биналарның охшашлыгына һәм аерымлыгына игътибарны юнәлтү, баланың корылма өлешләрен мөстәкыйль таба һәм күрсәтә белүен, аның үзенчәлекләрен атавын хуплау.

Китап, китаптагы иллюстрацияләр турындагы белемнәрне тирәнәйтү. Китапларны, шул исәптән татар язучылары һәм шагыйрьләре тарафыннан язылган әсәрләрне саклау үзәге буларак, милли китапханә белән таныштыру.

Чынбарлыкның эстетик ягына кызыксыну уяту, аның төрле төрләре һәм жанрлары, шул исәптән халык иҗаты белән таныштыруны дәвам итү.

***Сәнгати-эстетик чынбарлыкның төрле төрләренә җәлеп итү, баланың үзен иҗади яктан таныту, сәнгати уй-ниятне чынга ашыруда инициатива һәм мөстәкыйльлек күрсәтү ихтыяҗын үстерү өлкәсендә***

**Сынлы сәнгать эшчәнлеге**

*Рәсем ясау*

Балаларның игътибарын табигатьнең матурлыгына юнәлтү һәм алар белән бергә үсемлек һәм хайваннар дөньясы объектларының формаларына, төсләренә, төзелешләренә соклану.

Татар гамәли сәнгать әсәрләре белән танышуны дәвам итү. Балаларның халык сәнгате һәм гамәли сәнгать белән кызыксынуын хуплау.

Балаларны «бизәк», «орнамент» төшенчәләре белән таныштыру. Осталарча татар бизәгенә күчерелгән табигый чәчәк-үсемлек мотивларын балалар белән бергәләп карау. Бизәкнең элементларын аера белүне үстерү.

Балаларны гамәли сәнгать эшчәнлегенә тарту: тукранбаш – өчле яфрак (бер ноктадан өч якка буяу), күкчәчәк, ромашка, гөлҗимеш, миләш һ.б.ны ясау ысулын күрсәтү. Бер, ике яисә

берничә төсне кулланып, гади элементлардан торган кайма (бордюр) бизәге ясарга өйрәтү. Чәчәкле үсемлекләргә туры килә торган төсне сайлый белүгә игътибарны җәлеп итү.

Берничә өлештән торган предметларның (кош, күбәләк, бал корты) формасын һәм төзелешен рәсемдә бирә белергә өйрәтү.

Төсмерләр (зәңгәрсу, соры, алсу, аксыл шәмәхә) белән таныштыру, төсне тоемлау хисен үстерү.

Балаларны татар гамәли сәнгате мотивлары буенча күмәк эшләр башкаруга җәлеп итү, үз гамәлләрен башкалар белән килешеп эшләргә өйрәтү.

Рәсемдә туган шәһәр (авыл) тормышына кагылышлы истә калырлык вакыйгаларны тасвирлый белүгә кызыксыну уяту. Балалар белән бергә эшләрне карау һәм рәсемдә сурәтләнгәннәр турында сөйләргә җәлеп итү, иҗади активлыкны уяту.

*Әвәләп ясау*

Балчык, тозлы камыр, пластилин һәм башка сыгылмалы материаллардан әвәли белүне камилләштерү. Әвәләп ясауга кызыксыну үстерү.

Төп кисәктән зур булмаган кисәкләрне чеметеп яисә өзеп алу, аларны бармаклар белән түгәрәкләү, өлешләрне берләштерү (чәкчәк, анар, миләш җимешләре); җәлпәкләндерелгән шарның өстен шомарту, аның ян-якларын аз гына күтәртеп бизәкләү (гөбәдия, вак бәлеш һ.б.) күнекмәләрен формалаштыру. Стека (махсус кискеч) ярдәмендә ике яисә дүрт өлешкә (бәлеш кисәкләренә) бүлеп, барлыкка килгән формаларны үзгәртеп ясарга омтылышларын хуплау.

Эче куыш форма (касә, чүлмәк, чынаяк) ясау өчен, шарның уртасын басып батыру ысулын кат-кат кабатлау. Стеканы куллану ысуллары белән таныштыру. Әвәләп ясалган предметны стека ярдәмендә яки өстәп ябыштырып бизәүләрен хуплау.

Әвәләп ясалган предметларны берләштереп, күмәк композиция (тәлинкәгә салынган сый, чәй сервизы һ.б.) төзү. Уртак эшчәнлек нәтиҗәсенә соклану, шатлану хисе уяту.

Декоратив әвәләүдә халык уенчыклары (Шәмәрдән балчык уенчыгы, Актүбә уенчыклары һ.б.) мотивлары буенча иң гади образлар тудырырга омтылыш уяту.

Әвәләп ясауда татар халык әкиятләре мотивлары буенча берәр сюжетны чагылдыруга кызыксыну һәм теләк уяту, алга таба әвәләп ясалган фигураларны өстәл театрында, мультипликацион фильмнар төшерүдә куллану. Өлкәннәр белән балаларның уртак эшчәнлеге нәтиҗәсенә карата шатлык хисләре тудырырга ярдәм итү.

*Аппликация*

Аппликация сәнгатенең эчтәлеген катлауландырып һәм төрле сурәтләрне ясау мөмкинлекләрен арттырып, әлеге сәнгать белән кызыксынуны үстерү.

Башта кыска, аннан соң озынрак тасмаларны туры буенча кисәргә өйрәтү. Төсле кәгазьдән киселгән тасмалардан предмет сурәтләре (флаг) ясау күнекмәләрен үстерү.

Сирень, артыш чәчәкләреннән композиция ясау өчен, ертулы аппликация техникасы белән таныштыру.

Чәчәк, җиләк, җимеш һ.б. предметларны сурәтләү өчен, почмакларны кисү ысулы белән квадраттан – түгәрәк, дүртпочмаклыктан озынча түгәрәк формаларны кисәргә өйрәтү. Тасма, квадрат, түгәрәк эчендә бизәк сыйфатында декоратив элементлар төзү омтылышларын хуплау. Ритмны тою хисен үстерү.

Балаларны татар гамәли сәнгате мотивлары буенча әзер формалардан (чәчәк, күбәләк, кош) күмәк композицияләр ясауга җәлеп итү.

Бер кәгазь битендә берничә предметны (урам, шәһәр) төзү һәм ябыштыру юлы белән балаларга сюжетлы аппликацияләр ясарга булышу. Балаларның игътибарын аерым оригиналь ысулларны куллануга юнәлтү.

**Музыкаль эшчәнлек**

Милли татар музыкасы белән кызыксынуны үстерү, аны тыңлыйсы килүне хуплау. Аның эмоциональ-образлы эчтәлегенә карата хисләрне күрсәтә, үз тәэсирләре белән бүлешә белергә өйрәтү.

Татар композиторларының музыка әсәрләрен кулланып, өч төп музыкаль жанр: «җыр», «бию», «марш» төшенчәләрен кертү. Балаларны музыканың характерын, аның кәефен билгели белергә өйрәтү.

Музыка уен кораллары (курай, кубыз, тальян гармун һ.б.) һәм аларның яңгырашы белән танышуны дәвам итү.

Чиста интонация, сүзләрне төгәл әйтү, татар җырларын сәнгатьле, аңлап башкару күнекмәләрен үстерү.

Татар биюе өчен характерлы булган иң гади хәрәкәтләр белән танышуны дәвам итү: «аяк очына басып йөреш», «берле бишек», «чүгәләп бию», «бармак очы – үкчә», «тыпырдау», «аяк очына күтәрелү», «борма» (гади варианты), «парлап әйләнү» һ.б. Музыка характерына карап, хәрәкәтләр ритмын формалаштыру.

Хәрәкәт итү импровизацияләрендә музыкаль уен образын күрсәтү омтылышын хуплау, балалар белән бергә образга керүнең төрле вариантларын («тәкәббер» әтәч, «кайгыртучан» тавыклар, «тиктормас» чебиләр һ.б.) карау, музыкаль әкиятнең эчтәлегенә һәм характерына иң югары дәрәҗәдә туры килгән образны сайларга булышу, һәр иҗади табышны хуплау.

Музыканы балаларның һәр эшчәнлек төре структурасына кертү, балалар матур әдәбият, ТР театр һәм сынлы сәнгате белән танышканда, музыкаль эшчәнлекне кушу. Сәнгати идеяләрне мөстәкыйль рәвештә тормышка ашырганда, балалар инициативасын, аларның импровизациягә омтылышын хуплау.

**МУЗЫКАЛЬ ӘСӘРЛӘРНЕҢ ЯКЫНЧА ИСЕМЛЕГЕ**

**Музыка тыңлау**

«Туган илебез», З. Хәбибуллин муз., Х. Вахит сүз.; «Күңелле бию», А. Леман муз.; «Марш», Н. Җиһанов муз.; «Шома бас», татар халык җыры, Р. Еникиева эшкәрт.; «Хәерле йокы», А. Монасыйпов муз.; «Безнең гаилә», З. Хәбибуллин муз., Г. Тукай сүз.; «Яратам», Ф. Хатыйпов муз., Ш. Маннур сүз.; «Әни кирәк», М. Шәмсетдинова муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Ямьле көн», «Моңлы көй», А. Монасыйпов муз. («Дүрт пьеса» циклы); «Көз көне», М. Мозаффаров муз., Н. Гайсин сүз.; «Сүзсез җыр», татар халык көе, А. Вәлиуллин эшкәрт.; «Курчаклар маршы», «Вальс», Н. Җиһанов муз. («Балалар өчен пьесалар» альбомы); «Гөлнара полькасы», Р. Халитов муз.; «Балалар ярдәм итә», З. Хәбибуллин муз., Г. Лотфи сүз.; «Кышкы әкият», Ф. Шәймәрданова муз.; «Авыру куян», Р. Ахиярова муз.; «Куян биюе», Р. Еникиев муз.; «Яз килде», С. Сәйдәшев муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Күбәләк», «Колын», Р. Ахиярова муз. («Балаларга фортепиано өчен пьесалар» циклы); «Сабан туе», татар халык көе, М. Садри сүз., Р. Еникиева эшкәрт.

**Җырлау**

*Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре:* «Йомшак су, йөгерек су», М. Зәйнуллина муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Бишек җыры», татар халык көе, Р. Миңнуллин сүз., Г. Гыйләҗетдинова эшкәрт.; «Әтәч», Г. Гыйләҗетдинова муз., Дәрдемәнд сүз.; «Карга», балалар фольклорыннан, Н. Бакиева муз.; «Яз», «Аткаем», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Акбай», М. Зәйнуллина муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Туп, туп, тубыбыз», М. Зәйнуллина муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Курчакка күлмәк», Н. Бакиева муз., Р. Вәлиева сүз.; «Җиләкләр», Р. Еникиева муз., Л. Лерон сүз.; «Колын», «Каен җиләге», Ә. Бакиров муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.

*Җырлар:* «Яфрак бәйрәме», Р. Еникиева муз., Л. Лерон сүз.; «Көз килде», Л. Хисмәтуллина муз. һәм сүз.; «Атларны без яратабыз», татар халык җыры, Л. Хисмәтуллина эшкәрт.; «Бакчабызда бәйрәм», Г. Гәрәева муз. һәм сүз.; «Кыш», Ф. Җәләлетдинова муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Кыш бабай», Ф. Әбүбәкеров муз., Т. Миңнуллин сүз.; «Яңа ел», Р. Ахиярова муз., Л. Әмирханова сүз.; «Солдат буласым килә», Ә. Гайсамова муз. һәм сүз.; «Әниләр бәйрәме», Ф. Шәймәрданова муз., И. Сәлахова сүз.; «Яз килә», Т. Вафина муз., халык сүз.; «Чыпчык», Ф. Кәримуллина муз., Р. Вәлиева сүз.; «Үзен бик чиста йөртә», Н. Зарипова муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Әтәч», Л. Хисмәтуллина муз, Г. Лотфи сүз.; «Кояш, чык инде», З. Гыйбадуллин муз., Р. Хафизова сүз.; «Яратам», Э. Зиннәтуллина муз., З. Вәлиева сүз.; «Дәү әнигә бүләккә», Н. Яхина муз. һәм сүз.; «Күңелле безнең бакча», Л. Хисмәтуллина муз., Р. Вәлиева сүз.

*Җыр иҗаты:* «Исемең ничек?», «Хәерле иртә», М. Зәйнуллина муз., Х. Халиков сүз.; «Курчагымны тирбәтәм», Ф. Җәләлетдинова муз. һәм сүз.; «Әтәч», Җ. Фәйзи муз., М. Җәлил сүз.; «Бака, бака, бакырган», Ф. Шәймәрданова муз., халык сүз.; «Яз килә», Ф. Шәймәрданова муз., Ш. Галиев сүз.; «Сыерчыклар», Ф. Җәләлетдинова муз., Д. Гарифуллин сүз.; «Җавап бир», Ф. Шәймәрданова муз., Э. Мөэминова сүз.

**Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр**

*Уен күнегүләре:* «Без йөрибез», татар халык көе («Сәрия»), Р. Еникиева эшкәрт.; «Яшь солдатлар без», М. Мозаффаров муз.; «Әйлән-бәйлән», татар халык көе, М. Зәйнуллина эшкәрт.; «Сикерү», Р. Кәлимуллин муз.; «Биергә өйрәнәбез», татар халык көе («Уфа – Чиләбе»), Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Чакыру биюе», «Өммегөлсем», татар халык көе, Ф. Фәизова эшкәрт.; «Марш», М. Салихов муз.; «Барабан», А. Хәсәншин муз.; «Куллар өчен күнегү», Р. Гыйләҗева муз.; «Әтәчкәем», И. Шәмсетдинов муз.; «Тасмалар тотып», Х. Вәлиуллин муз. («Вальс»); «Төлке һәм куяннар», А. Батыршин муз. («Татар полькасы»); «Полька», И. Якубов муз.; «Җайдаклар», Ф. Шәймәрданова муз.; «Түгәрәктә бию», татар халык көе, М. Зәйнуллина эшкәрт.; «Кечкенә бию», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Тыпырдау», татар халык көе («Төймә»), Ә. Фәттах эшкәрт.; «Чәчәкләр белән күнегү», Р. Еникиев муз. («Вальс»).

*Сәхнәләштерелгән этюдлар:* «Барабанчы», З. Хәбибуллин муз.; «Көзге яфраклар биюе», Ф. Шәймәрданова муз. («Вальс); «Кем саный», Р. Ахиярова муз.; «Күңелле уен», Л. Хәйретдинова, М. Әндерҗанова муз.; «Шаян мәче», Ә. Шәрәфиев муз.; «Көз», Ф. Шәймәрданова муз., С. Сабирова сүз.; «Очкычлар», А. Монасыйпов муз. («Этюд»); «Аланда», Ф. Шәймәрданова муз.; «Миңлебай», Р. Еникиева муз., халык сүз.; «Әтәч һәм тавыклар», С. Сәйдәшев муз. («Бию»); «Чебиләр зарядкасы», Л. Хәйретдинова муз., М. Фәйзуллина сүз.; «Без урманга барабыз», татар халык җыры, М. Зәйнуллина эшкәрт.; «Җиләк җыям», Җ. Фәйзи муз. («Якты таң»); «Күбәләк», Ф. Шәймәрданова муз., М. Әндерҗанова сүз.

*Түгәрәк уеннары һәм биюләр:* «Әйлән-бәйлән», Ә. Һадиева муз., А. Минһаҗев сүз.; «Түбәтәй», татар халык көе («Шома бас»), Ә. Гайсамова сүз., Р. Еникиева эшкәрт.; «Бөтерчекләр», татар халык көе («Аллы-гөлле гөлчәчәк»), М. Мозаффаров эшкәрт.; «Парлы бию», Л. Шиһабетдинова муз.; «Тыпырдап бию», татар халык көе; «Төймә», М. Зәйнуллина эшкәрт.; «Күңелле биибез», башкорт халык көе, А. Кобагошев эшкәрт.; «Чыршы», Л. Хисмәтуллина муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Яулыклар тотып бию», Л. Хисмәтуллина муз.; «Күңелле бию», Ф. Фәизова муз.; «Матур уен», татар халык көе һәм сүз., Г. Беляева эшкәрт.; «Зәңгәр чәчәк», татар халык җыры, Р. Еникиева эшкәрт.; «Бергәләшеп биик», Р. Гыйләҗева муз. һәм сүз.; «Чума үрдәк, чума каз», татар халык җыры, Р. Еникиева эшкәрт.; «Яшел бакча», татар халык җыры, Р. Тимершина эшкәрт.

*Характерлы биюләр:* «Аю балалары биюе», Р. Гыйләҗева муз. һәм сүз.; «Әнкә куян һәм куянкайлар», А. Батыршин муз. («Гөлнара полькасы»); «Кар бөртекләре биюе», «Петрушкалар

биюе», Л. Хисмәтуллина муз.; «Мәрҗән бөртекләре биюе», Ф. Шәймәрданова муз.; «Бәбкәләр», Ф. Шәймәрданова муз., Р. Вәлиева сүз.; «Чәчәкләр биюе», Р. Еникиев муз. («Вальс»).

*Музыкаль уеннар:* «Үз кәрзинеңне тап», Х. Вәлиуллин муз. («Вальс»); «Кайсыбыз юк?», Р. Еникиев муз. («Пьеса»); «Яңгыр», М. Мозаффаров, Л. Хисмәтуллина муз.; «Кем беренче?», татар халык көе, Р. Сабитов эшкәрт.; «Кыңгыраулар белән уен», Ф. Шәймәрданова муз.; «Тычканнар», Р. Зарипов муз.; «Сыерчык оялары», М. Салихов муз. («Полька»); «Үзеңә пар тап», Р. Зарипов муз.; «Бәр шөлдерле барабанга», татар халык көе, В. Вәлиева эшкәрт.; «Ат тоту», Л. Шиһабетдинова муз.; «Әбәкләшү», Р. Еникиев муз.

*Җырлы уеннар:* «Автобуска утырдык», Л. Хисмәтуллина муз. һәм сүз.; «Безнең бакча», Ә. Һадиева муз. һәм сүз.; «Песи һәм тычканнар», «Тилгән», Г. Гыйләҗетдинова муз., халык сүз.; «Алтын капка», Ф. Шәймәрданова муз., халык сүз.; «Куяннар һәм бүре», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Тавышымнан таны», В. Вәлиева муз. һәм сүз.; «Паровоз», Л. Шиһабетдинова муз., С. Әхмәтов сүз.; «Аю белән уен», Л. Хисмәтуллина муз., халык сүз.; «Каен җиләге», Ә. Бакиров муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Күңелле туп», татар халык уены.

*Биюле уен иҗаты:* «Кыю бас», Н. Бакиева муз. һәм сүз.; «Курчак», татар халык көе, А. Монасыйпов эшкәрт.; «Песи баласы», М. Мозаффаров муз.; «Бию», «Чыпчыклар», Ф. Шәймәрданова муз.; «Безнең чебиләр», Г. Беляева муз., Г. Зәйнашева сүз.; «Җырлап бию», татар халык көе, Р. Зарипов эшкәрт.

**Музыкаль-дидактик уеннар**

*Музыкада аваз югарылыгын ишетү сәләтен үстерү:* «Бу өйдә кемнәр яши?», «Баскыч», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова эшкәрт.

*Ритмны тою сәләтен үстерү:* «Әйдәгез урамга!», «Карусель», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз.

*Тембрны аера белү һәм динамик төсмерләрне ишетү сәләтен үстерү:* «Ак калач кемне очрата?», «Нәрсәдә уйныйм?», «Музыкаль табышмак».

*Жанрны аера белү һәм музыкаль хәтерләрен үстерү:* «Бала нишли?»; «Рәсемне сайлап ал»; «Урман аланында».

**Балалар музыка уен коралларында уйнау**

«Тукран», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз., халык сүз.; «Бишек җыры», М. Яруллин муз.; «Карга», балалар фольклорыннан, Н. Бакиева муз.; «Су», М. Зәйнуллина муз., Б. Рәхмәт сүз.; «Тышта яз», Л. Шиһабетдинова муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Тилгән», «Там, там, тамчы», М. Зәйнуллина муз., халык сүз.; «Бию», Җ. Фәйзи муз.; «Кура җиләк», Л. Шиһабетдинова муз., Н. Арсланова сүз.; «Оркестр», татар халык көе, Г. Гыйләҗетдинова эшкәрт.

**Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәре**

*Сәхнәләштерү һәм музыкаль спектакльләр:* «Автобуска утырдык», Л. Хисмәтуллина муз. һәм сүз.; «Дәү әнигә бүләккә», Н. Яхина муз. һәм сүз.; «Атларны без яратабыз», татар халык җыры, Л. Хисмәтуллина эшкәрт.; «Куяннар һәм бүре», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Кыш», Ф. Җәләлетдинова муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Урмандагы куяннар», Г. Гыйләҗетдинова муз. һәм сүз.; «Паровоз», Л. Шиһабетдинова муз., С. Әхмәтов сүз.; «Кояш кебек», С. Ихсанова муз., Р. Вәлиева сүз.; «Чуар тавык», Г. Гомәр; «Тавык, Тычкан һәм Көртлек», татар халык әкияте; «Бала белән Күбәләк», Г. Тукай.

*Әдәби-музыкаль композицияләр:* «Алтын көз», «Әниләр көне», «Кышкы әкият», «Яз килә», «Музыкаль уенчыклар» (Р. Вәлиеваның «Урманда бәйрәм булган» шигыре буенча), «Юлда йөри беләсеңме?».

*Бәйрәмнәр:* «Хуш киләсең, Яңа ел», «23 февраль – Ватанны саклаучылар көне», «8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне», «9 Май – Җиңү бәйрәме»; «Милли бәйрәм – Сабан туе».

## • ФИЗИК ҮСЕШ

**Балаларда сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен булдыру, аларда үзләренең гәүдә төзелеше һәм физик мөмкинлекләре турында күзаллауларны үстерү, хәрәкәтләр тәҗрибәсе алу һәм хәрәкәт активлыгын камилләштерү, спортның кайбер төрләре турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру, кагыйдәле хәрәкәтле уеннарны өйрәнү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең физик үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балаларда сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен тәрбияләү өлкәсендә***

Балаларның, шул исәптән сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле булганнарның физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту, Оешмада тудырылган шартларны, төркемнең тулылыгын, тәрбияләнүчеләрнең физик үсеш дәрәҗәсен, сәламәтлек үзенчәлекләрен, төбәкнең климатка һәм сезонга хас үзенчәлекләрен исәпкә алып, балалар организмын чыныктыру эшен дәвам итү.

Балаларда шәхси гигиена процессы алгоритмы турында күзаллауларны баету. Балаларның гигиена кагыйдәләрен аңлы рәвештә үтәвенә ирешү: ашау алдыннан һәм ашаганнан соң, пычранганда, бәдрәфтә булганнан соң мөстәкыйль рәвештә кулны юарга, тешләрне чистартырга, ашаганнан соң авызны чайкарга, йоклар алдыннан аякларны юарга өйрәтү.

Гади һәм чиста киенеп йөрүне, киемнәрне пөхтәләп төрүне, бүлмәдә чиста аяк киемен кия белүне хуплау.

Ашаганда пөхтәлекне саклау күнекмәләрен камилләштерү: ризыкны аз-азлап алырга, тыныч кына ашарга, артык кайнар ризыкны ашамаска, чүпләмәскә, аш приборларыннан дөрес файдалана белергә.

Милли ризыклар, эчемлекләр белән таныштыру: умач, татарча азу, Казан пылавы, күрәгә һәм кара җимешле чәй, хуш исле чәй һ.б.

Бала организмына кирәкле витаминнар турында сөйләү. Ашау һәм эчү режимын саклау, яшелчә, җиләк-җимеш, яшел үләннәр, җиләкләр, балык һәм сөт ризыклары (кайнаган сөт, кефир, корт), ит һәм башка файдалы продуктлар куллануга ихтыяҗ формалаштырырга булышу. Балаларга сәламәт туклану кагыйдәләрен аңларга ярдәм итү.

«Сәламәтлек» һәм «авыру» төшенчәләре, кайбер халык медицинасы чаралары белән таныштыру. Бәрелгәндә, киселгәндә үзенә һәм башка балаларга иң гади ярдәм күрсәтә, үз сәламәтлеге турында кайгырта белүне формалаштыру.

Сәламәтләндерү чараларында балаларның актив катнашуы өчен мөмкинлекләр тудыру.

***Хәрәкәт итү активлыгын камилләштерү, балаларда үзләренең гәүдә төзелеше һәм физик мөмкинлекләре турында күзаллауларны үстерү, спорт турында башлангыч күзаллауларны формалаштыру өлкәсендә***

Балаларда хәрәкәт итү активлыгына ихтыяҗ формалаштыру. Берничә яшьтәше катнашында мөстәкыйль рәвештә татар халык уеннарын оештыра белүне үстерү. Уен кагыйдәләрен үтәгәндә үзконтрольгә өйрәтү.

Балаларга өч көпчәкле самокатта йөрү мөмкинлеге тудыру. Үз хәрәкәтләре белән идарә итә, бер аяк белән этелеп китә һәм туктап кала белүләрен үстерү.

Өч көпчәкле велосипедта йөрүне камилләштерү: сулга һәм уңга борылырга, әйләнә буенча йөрергә, предметларны урап уза белергә, уен мәйданчыгында иркен ориентлашырга күнектерү.

Татар һәм рус халык уеннарының вариантларын уйлап табуны, хәрәкәтләрне бергә кушуны хуплау.

**ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАРНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ**

***Йөгерүле уеннар.*** «Ябалак», «Төсле автомобильләр», «Очкычлар», «Кыңгырау», «Сиздермичә йөгереп үт!», «Беренче булып бас!», «Шалтыравык», «Песи белән тычкан», «Песи һәм кошчыклар», «Соры бүре».

***Сикерүле уеннар.*** «Тавык кетәклегендә төлке», «Куяннар», «Хәйләкәр төлке», «Инеш аша сикереп чык!», «Курыкмыйм».

***Шуышулы һәм үрмәләүле уеннар.*** «Көтүче», «Песи балалары», «Көчекләр», «Кошлар оча».

***Тупны ыргыту һәм тотып алу уеннары.*** «Ыргыт һәм тотып ал!», «Ераккарак ыргыт!», «Бәҗра», «Төз ыргыт!», «Кем ераграк ыргыта?».

***Тирәлектә ориентлашу уеннары.*** «Үз төсеңне тап!», «Сыерчык оялары», «Көн – төн», «Үзеңә пар тап», «Көтүче һәм атлар», «Бүләкләр», «Үз чиләгеңне тап!», «Кайда шалтыраттылар?», «Кем тавышы?».

***Татар халык уеннары.*** «Куышу уены», «Ак калач», «Аю – бүре», «Песием», «Яшелчәләр».

***Рус халык уеннары.*** «Казлар – аккошлар», «Ябалак һәм кошлар», «Минем күңелле тубым», «Инеш».

## ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ

(5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

### • ИҖТИМАГЫЙ-КОММУНИКАТИВ ҮСЕШ

**Балада үзенә һәм башка кешеләргә карата уңай мөнәсәбәт үстерү, коммуникатив һәм иҗтимагый, шул исәптән мәгълүмати-иҗтимагый компетентлыкны арттыру, уен эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең иҗтимагый-коммуникатив үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балада үзенә һәм башка кешеләргә карата уңай мөнәсәбәт үстерү өлкәсендә***

Гаилә, аның тарихы турында күзаллауларны тирәнәйтү. Гаилә составы, туганнар (әти-әни, әби-бабай, әне-сеңелләр, абый-апалар, икенче, өченче буын абый һәм апалар), үзенең шул гаиләгә каравы, туганлык җепләре һәм гаилә эчендәге бәйләнешләр, әти-әниләрнең һөнәрләре һәм мавыгулары турында күзаллауларны киңәйтү, туганнарның фотосурәтләрен карарга җәлеп итү, игътибарны баланың әти-әнисе, башка туганнары белән охшашлыгына юнәлтү. Гаилә һәм нәсел кыйммәтләрен формалаштырырга булышу.

Хәленнән килгәнчә баланың гаилә бәйрәмнәрен әзерләүдә катнашуын, өйдә даими вазифасын үтәргә теләвен хуплау. Гаилә эшләренә карата кызыксыну уяту, проблемаларны бергәләшеп чишәргә омтылуын хуплау.

Гомумкешелек кыйммәте буларак ватанпәрвәрлекнең беренче чагылышының (үз гаиләсенә, балалар бакчасына, туган якка, анда яшәүче кешеләргә мәхәббәт) әхлакый нигезләрен формалаштыру өчен шартлар тудыру.

Үз казанышлары, фестивальләрдә, ярышларда яшьтәшләренең уңышлы чыгышлары, спортчыларның Олимпия уеннарында җиңүләре, артистларның халыкара конкурсларда чыгышлары өчен горурлык хисен үстерү.

Баланың әйләнә-тирәдәге өлкәннәрнең балачак вакыйгалары, тугры дуслар, ишегалды уеннары, кулдан ясалган уенчыклар турында, баланың үз кызыксынуларына һәм хисләренә аваздаш булырлык һәм яхшы истә калган кызыклы хәлләр, эпизодлар турында мәгълүмат белән кызыксынуын хуплау.

Балаларның участокны коелган яфраклардан чистарту, шәһәрдә калган кошларны ашату кебек күмәк эшләрдә, экологик акцияләрдә катнашу юнәлешендә шәхси тырышлыкларын хуплау.

***Коммуникатив һәм социаль, шул исәптән мәгълүмати-социаль компетентлыкны арттыру өлкәсендә***

Табигый һәм социаль дөнья, туган шәһәрендәге (авылындагы), республикадагы, илнең башка төбәкләрендәге вакыйгалар турында төрле мәгълүмат чыганагы буларак, өлкәннәр белән аралашу ихтыяҗын хуплау.

Өлкәннәрнең бала белән һәм бала активлыгының төрле төрләре вакытында балаларның үзара туган телдә эмоциональ яктан бай эчтәлекле аралашуы өчен шартлар тудыру.

Төрле балалар (кечкенәләр, үзеннән олыраклар, яшьтәшләре, малайлар, кызлар), балалар бакчасындагы төркемгә яңа гына килгән бала һ.б. белән туган телдә аралаша белүен үстерү, аларга карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.

Татар һәм рус телләрендә сөйләшүче кешеләрнең гореф-гадәтләренә, традиция һәм культурасына карата кызыксыну һәм хөрмәт тәрбияләү, башка тел һәм мәдәният вәкилләре белән үзара бәйләнешкә кергәндә, үз-үзеңне аңлы һәм нигезле тоту күнекмәләре, иҗтимагый мәдәниятара аралашу күнекмәләре формалаштыру.

Балаларны Халыкара туган тел көнен, республиканың истәлекле даталарын бәйрәм итүгә тарту. Туган телнең кыйммәтен танырга булышу, республика тормышында катнашудан шатлык һәм канәгатьлек хисе тоюны формалаштыру.

Элементар этикет кагыйдәләрен үзләштерергә булышу, этик яктан кыйммәтле аралашу үрнәкләрен хуплау, сөйләмдә халык авыз иҗаты әсәрләрен (әйтемнәр, мәкальләр, сынамышлар һ.б.) куллану.

Таныш булмаган кеше белән очрашканда һәм очраклы рәвештә аралашырга туры килгәндә баланың үз-үзен тотышын күз алдына китерә алуы. Мондый очрашулар вакытында ихтималлылыгы зур булган ситуацияләрне тикшерү һәм фикер алышу, игътибарны таныш булмаган кеше белән икәүдән-икәү калырга ярамаганлыгына һәм моның куркыныч булуына юнәлтү.

Балаларны шәһәр, республика, илнең төп истәлекле даталарына әзерләнү эшенә җәлеп итү. Шәһәр (республика, ил) тормышында катнашудан горурлык һәм шатлык хисләрен формалаштыру.

Шәһәр юллары һәм урамнарында, җәмәгать транспортында, метрода куркынычсызлык кагыйдәләре нигезләрен формалаштыру.

Балаларны сукбай хайваннар белән очрашканда куркыныч туу ихтималы турында кисәтү.

Табигатьтә үз-үзеңне тоту культурасын формалаштыру. Балаларга туган як табигате өчен куркыныч булган кайбер гамәлләр һәм вакыйгалар (агачларны кисү, урман янгыннары, каты салкыннар, сулыкларның пычрануы һ.б.) турында сөйләү. Табигать ресурсларының торышы өчен җаваплылык тоярга, экологиягә зыян китерә торган гамәлләргә битараф булмаска өйрәтү.

Табигать белән кешенең үзара бәйләнеше, әйләнә-тирә мохитнең кеше сәламәтлегенә йогынтысы турында күзаллаулар формалаштыру.

***Уен эшчәнлеген үстерү өлкәсендә***

Сюжетлы-рольле уеннар өчен сайланган темаларны киңәйтүне хуплау, социаль дөньяны кабул итү, татар язучылары һәм шагыйрьләренең әдәби әсәрләре, телевизион тапшырулар, шәһәр (авыл) буенча экскурсия, күргәзмә, походлар аша алынган белемнәргә таянып, сюжетларны үстерергә ярдәм итү.

Балаларның мөстәкыйль уйнавын, рольләргә бүленгән уен диалогы төзи белүләрен, рольгә, чынбарлыктагы яисә уйлап табылган вакыйгага туры китереп уйнарга тырышуларын хуплау.

Балаларның шартлы формада милли уенчыклар, кулдан ясалган уенчыклар, тормыштан алынган, Идел буе халыклары әкиятләре, мультфильм сюжетлары һ.б. кулланылган индивидуаль яисә уртак режиссёрлык уеннарына булышу.

Балаларның артистлык сәләтләрен үстерү, аларны сәхнә сәнгатенә тарту: концерт куеп уйнау, татар җырларын тыңлау, Идел буе халыкларының биюләрен башкару, спектакльдән өзекләр кую. Яшьтәшләре, әти-әниләре һәм кунаклар каршында чыгыш ясау өчен мөмкинлек тудыру.

Физик, социаль (этномәдәни) үсешкә ярдәм итә торган кагыйдәле уеннарда, татар халык уеннарында индивидуальлекнең чагылышын, кагыйдәләрнең үтәлүен, уенда рольгә керә белү инициативасын хуплау.

Балаларның күңел ачу уеннарын (күп очракта халык уенчыклары, курчак театры персонажлары, балалар музыка уен кораллары (курай, гармун, кубыз һ.б. кулланылган интеллектуаль, күңел ачу, өстәл уеннары, мавыктыргыч уеннар) мөстәкыйль оештыруга кучүләрен хуплау, мөстәкыйльлек, инициатива күрсәтүне, тулы хокуклы партнёр позициясен алуларын хуплау.

LEGO Education WeDo, LEGO Sprike Prime, LEGO «Простые механизмы», LEGO Education «Планета STEAM», LEGO DUPLO конструкторлары ярдәмендә балаларны конструкция һәм модельләрне схема буенча ясарга өйрәтү. Балалар ясаган конструкцияләргә механик элементлар кертергә, туклану элементына тоташтырырга булышу, төзелгән конструкцияләрне кулланып, балалар уеннарын оештыру.

Балаларның Сабан туе, Сөмбелә, Нәүрүз, Карга боткасы һ.б. шундый сезонлы бәйрәмнәргә багышланган уеннарда актив катнашуларына ирешү, кешеләр арасында бәйрәм кәефен тоюны үстерү.

## • ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ

**Балаларның кызыксынучанлыгын, танып белү активлыгын, танып белү сәләтләрен үстерү өчен шартлар тудыру, әйләнә-тирә чынбарлык турында белемнәрнең төрле юнәлешләренә караган күзаллауларны баету белем бирү эшчәнлегенең танып белү үсеше өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Кызыксынучанлыкны, танып белү активлыгын, танып белү сәләтләрен үстерү өлкәсендә***

Балаларның туган як табигате, анда ел фасылларына хас үзгәрешләр турында белемнәрен тирәнәйтү. Табигатьнең бербөтенлеге һәм аның компонентларының үзара бәйләнештә булуы турында элементар күзаллауларны формалаштыру.

Республика территориясендә яшәүче хайваннарның яшәү рәвешен, аларның тышкы кыяфәтенә хас үзенчәлекләрне (гәүдә өлешләре, тәне нәрсә белән капланган), хәрәкәт итү ысулларын (шуыша, оча, йөзә), туклану үзенчәлекләрен, яшәү мохитенә яраклашуларын күзәтергә теләүне, шуның белән кызыксынуларын хуплау. Балаларның сезонлы үзгәрешләргә карап тере организмнарның яшәү мохитенә җайлашулары да үзгәрүе (көзен бөҗәкләр җир асты, агач кайрысы астына кача һәм йоклый; кышлаучы кошлар кеше яшәгән урынгарак күчә, куян үзенең «тунын» алыштыра һ.б.) турындагы белемнәрен баету. Хайваннарны алар чыгарган авазларга карап таный, тыңлый белүләрен үстерү. Табигать дөньясы турында фәнни белемнең алшартларын формалаштыру.

Туган якта иң еш очрый торган үсемлекләр белән кызыксынуларны хуплау. Табигать объектларын үзенчәлекләре буенча классларга һәм төркемнәргә бүләргә (ылыслы һәм яфраклы

агачлар, куаклар, үлән үсемлекләр, урман, болын, бакча, сулык үсемлекләре, бүлмә гөлләре һ.б.) өйрәтү. Туган як табигатенең матурлыгын, аның форма, төс һәм исләр байлыгын күрә белүләрен үстерү.

Кешенең табигатьне саклау эшчәнлеге белән таныштыру. Идел-Кама дәүләт тыюлыгы, «Түбән Кама» милли паркы турында сөйләү, аларның республика табигатен саклаудагы роле турында аңлату.

Тере һәм терек булмаган табигатькә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, кешенең табигатькә катнашуы аркасында килеп чыккан уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, туган як табигате үз ихтыяҗыңны канәгатьләндерү өчен кирәк дигән карашның тискәре күренеш булуын аңлату, табигатьтән дөрес файдалануның беренчел күнекмәләрен («Бөтенебез дә дару үсемлекләрен тамырлары белән җыйсак, ...») булдыру. Табигать ресурслары өчен җаваплылык хисен формалаштыру.

Балаларга, табигатькә чыккач, үз-үзеңне дөрес тоту буенча иң мөһим кагыйдәләр аерып күрсәтелгән хикәяләр тупланган җыентык ясарга булышу, җыентыкны балалар ясаган рәсемнәр белән бизәү. Җәмгыятьтә кабул ителгән норма һәм кагыйдәләрне үзләштерергә булышу. Иҗади сәләтләрне үстерү.

***Әйләнә-тирә чынбарлык турында белемнең төрле юнәлешләренә караган күзаллауларны үстерү өлкәсендә***

Татарстан Республикасы символикасы (флаг, герб, гимн) белән таныштыру. Балаларга үз халкыңның бер өлеше булуларын аңлату.

Казан – республикабыз һәм бөтендөнья татарларының башкаласы дигән күзаллауны формалаштыру. Казан – эре сәнәгать үзәге, Россиянең иң борынгы шәһәрләренең берсе. Казанда Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Хөкүмәте, шәһәр мэры эшли. Башкала символикасы белән таныштыру.

Балаларга туган як тарихы, легендалары, мифлары турында сөйләү, алар турында фикер алышу. Узган вакыйгалар, истәлекле урыннар, тарихи һәйкәлләр, музейлар, туган шәһәр (авыл) урамнары исемнәренең килеп чыгышы белән таныштыру. Балаларда Татарстан Республикасының узганына һәм бүгенгесенә, туган як тарихына кызыксыну уяту. «Безнең йортыбызга 100 ел» китабын куллану.

Балаларны Татарстан Республикасының географик урыны белән таныштыру: картада һәм глобуста республика территориясен, Идел һәм Чулман (Кама) елгаларын, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычын, Кабан күлен, тирә-яктагы күлләрне һәм елгаларны билгеләү. Балаларга шартлы билгеләрне аңлату.

Балаларда милли мәдәният чаралары турында (торак, көнкүреш кирәк-яраклары, милли ризыклар, кием, савыт-саба, милли бәйрәмнәр, музыка уен кораллары, фольклорның кече формалары) күзаллауларны киңәйтү. Балаларда сорау бирү, үз фикерен белдерү теләген уяту.

Татарстан – күпмилләтле республика дигән фикерне формалаштыру. Әдәби текстларны кабул итү, китап рәсемнәрен, видеоальбомнарны карау аша Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның традицияләре, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру. Кешеләрнең үз-үзләрен тотышында һәм культурасында гомум һәм үзгә сыйфатларны күрә белергә өйрәтү, башка милләт кешеләренә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

Милли һәм дөнья мәдәниятенең узганы һәм бүгенгесе турында сөйләү. Күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең тормышы һәм иҗаты белән таныштыру: шагыйрьләр (Г. Тукай, М. Җәлил, Р. Миңнуллин һ.б.), язучылар (А. Алиш, Р. Батулла һ.б.), рәссамнар (Р. Заһидуллин, А. Гайфуллин һ.б.), сынчылар (Б. Урманче, Р. Нигъмәтуллина, И. Башмаков һ.б.). Аларның тормыш һәм иҗат эшчәнлегенә кызыксыну уяту.

Балаларда зур сәнәгать комплекслары, фермер хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукцияләре, терлекчелек һәм үсемлекчелек белән бәйле кайбер һөнәрләр (фермер, сыер савучы, ветеринар, комбайнчы, яшелчәче һ.б.) турында күзаллаулар формалаштыру. Туган җиргә мәхәббәт, шул җирдә хезмәт итәргә теләк тәрбияләү.

Балаларда татар халык әкиятләре («Өч кыз», «Үги кыз» һ.б.) аша өлкәннәрнең хезмәт эшчәнлеге, аларның хезмәткә мөнәсәбәте турында күзаллауларны үстерү. Балаларның игътибарын хезмәт сөйгән әкият геройларына юнәлтү. Балаларның эш-гамәлләрен Г. Тукайның шигъри юллары («Кызыклы шәкерт», «Шаян песи» һ.б.) белән бәйләп алып бару.

Казан шәһәре метрополитены, аның станцияләре белән танышуны дәвам итү: «Кремль», «Кәҗә бистәсе», «Сукно бистәсе» һ.б., аларның фотоларын карау һәм атамаларының килеп чыгу тарихы белән таныштыру. Туган якны өйрәнү эшчәнлеген үстерү, әйләнә-тирә чынбарлык турында белемнәрне тирәнәйтү.

Метрода үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләре белән таныштыру: вагонда ишекләргә сөялмәскә, чыгарга иртәрәк әзерләнергә, станциядә бар кеше белән бер юнәлештә атларга, чикләү сызыгыннан чыкмаска, эскалаторда уңга басарга, эскалаторга басканда яисә төшкәндә үзеңнең хәрәкәтеңне эскалаторныкы белән җайларга, турникет аша узганда түләргә. «Сакла» интернет-порталы материалларын кулланырга.

«Велосипедта хәрәкәт итү тыела», «Велосипед юлы» билгеләре, велосукмаклар билгеләнгән урамнар белән таныштыру. Шәһәр урамнарында ирекле ориентлаша белүне камилләштерү. Велосипедта йөрү кагыйдәләре белән таныштыру.

Балаларны үз җирлекләрендәге транспорт чаралары белән таныштыру: өйдән балалар бакчасына, үзәк мәйданга, курчак театрына һ.б.га кадәр кайсы маршрут автобусына утырырга кирәклеген, әти-әниләрнең нинди транспорттан файдалануын ачыкларга.

Балаларны машинада йөртү кагыйдәләре белән таныштыру: балалар утыргычында каеш белән эләктереп утырырга, йөртүчегә комачауламаска, тәрәзәдән сузылмаска, үзең белән очлы предметлар алмаска, үз гамәлләреңә контрольлек итә белү күнекмәләрен ныгытырга.

Балаларда махсус транспорт чараларының (ашыгыч ярдәм машинасы, полиция машинасы, янгын сүндерү машинасы һ.б.) кулланылышы турындагы белемнәрне төгәлләштерү, аларның сигнал тавышларын аерырга, ишеткәч нишләргә кирәклеген өйрәтү. Махсус транспорт чараларының аерым очракларда юл хәрәкәте кагыйдәләрен боза алуына игътибарларын юнәлтү.

Урамда һәм шәһәр (авыл) юлларында үз-үзеңне куркынычсыз тоту өчен кирәкле төп кагыйдәләргә басым ясалган җыентыклар булдыруда балаларга булышу, җыентыкны балалар рәсемнәре белән бизәү. Иҗатның төрле формаларын үстерү.

## • СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ

**Сөйләм һәм тел культурасы нигезләрен формалаштыру, баланы матур әдәбият уку культурасына тарту өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең сөйләм үсеше өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Бала сөйләменең төрле якларын камилләштерү өлкәсендә***

Туган (татар) телен аралашу һәм милли мәдәният чарасы, хисләрне һәм мөнәсәбәтләрне белдерү, фикерләрне формалаштыру, өлкәннәр белән балалар арасын көйләү чарасы буларак үстерү өчен шартлар тудыруны дәвам итү. Уңышка ирешү ситуациясен булдыру.

Баланың көндәлек тормышында сөйләм һәм тел культурасын формалаштыру өчен балаларны тел мохитенә кертү, телне тоемлауны үстерү, тел күренешләрен үзара чагыштыруга карата кызыксыну уяту. Туган (татар) телдә сөйләшү теләген уяту.

Максатчан өйрәтү һәм үстерү процессында модельләштерү, проектлаштыру технологияләрен, уен һәм мәгълүмат-коммуникация технологияләрен, белем бирү, аралашу ситуацияләрен, дидактик инструментарийларны, уен чараларын, аудио- һәм видеоматериалларны, анимацияле сюжетларны куллану. Баланың сөйләменең үсеш дәрәҗәсен исәпкә алып, коммуникатив сәләтләрен үстерү.

Балаларга «Татармультфильм» берләшмәсе мультфильмнарын, «Шаян ТВ» телеканалы тапшыруларын һ.б.ны карарга, тавыш модульле китапларны, татар җырларын тыңларга һәм туган (татар) телен начар белгән очракта да канәгатьлек алырга өйрәтү. Сөйләм культурасы нигезләрен салу.

Рус теленнән татарчага сүзләр, сүзтезмәләрне тәрҗемә итү күнекмәләрен үстерү, хәтерне активлаштыру.

Диалог барышында туган аралашуның яңа формасы – үз фикерләре, тәэсирләре, белемнәре белән уртаклашу теләгеннән килеп чыккан монологны хуплау.

Балаларда үз теләге белән яисә өлкәннәр тәкъдиме белән сөйләүгә кызыксынуны хуплау, татар әкиятләре, хикәя, картина, зур булмаган текстлар, шәхси тәҗрибәдә алынган тәэсирләрнең эчтәлеген сәнгатьле итеп сөйләргә, яттан шигырьләр укырга, әдәби әсәрләрне сәхнәләштерергә өйрәтү.

Сыйфатка исем сайлау, охшаш һәм капма-каршы мәгънәле сүзләр табу күнекмәләрен үстерү. Образлы сүзләр, чагыштырулар, төгәл фигыльләрне активлаштыру, табышмак, мәкаль һәм әйтемнәрдәге образлы гыйбарәләрне аңларга өйрәтү. Туган телнең сүзлеген сыйфат һәм сан ягыннан баетуны тәэмин итү.

Грамматик яктан дөрес сөйләргә омтылуны хуплау.

Туган телдәге авазларның дөрес әйтелешенә ирешү, сүзләрне һәм фразаларны төгәл һәм аңлаешлы итеп әйтергә өйрәтү.

Балаларны җөмләнең сүз составы һәм сүзнең аваз составы белән таныштыру. Авазның сүздәге урынын (сүз башында, уртасында, азагында) билгеләргә өйрәтү, сүз басымын аеру һәм аның сүздәге урынын билгеләү. Сүздәге сузык, калын һәм нечкә тартык авазларны аерырга өйрәтү.

Балаларга Халыкара туган тел көнендә, бәйрәмнәрдә, бәйгеләрдә, сәхнәләштерүләрдә шигырь сөйләү мөмкинлеген тудыру. Сәнгатьле сөйләү нигезләрен салу. Булачак вакыйгалардан шатлык хисен кичерү мөмкинлеге бирү.

Балаларның сөйләм үсеше динамикасын, туган (татар) телендә бала өчен гадәти коммуникатив ситуациядә аралашу күнекмәләренең тотрыклылыгын мониторинглау системасын алып бару.

«Изучаем русский язык» укыту-методик комплексында каралган лексика күләменең (кимендә 380 сүз) бала тарафыннан тулысынча үзләштерелүен тәэмин итү, сүзләрне дөрес аңлау һәм куллануга булышу, сөйләм телен мәгънәле эчтәлек белән баету.

Диалог алып бару күнекмәсен үстерү, үзенә юнәлгән сөйләмне аңларга һәм, белем бирү ситуациясенә туры килә торган репликалар кулланып, мөрәҗәгатькә дөрес җавап бирергә өйрәтү. Балаларның диалогта катнашуын, әңгәмәдәшенә кушылырга омтылуын хуплау.

Сүзләрне үзгәртү һәм кушу юлы белән җөмлә төзү, родларда, санда, килештә төрләндерүнең төп закончалыкларын үзләштерергә булышу. Сөйләмдә тел культурасын формалаштыру.

Рус телен табигый сөйләм ситуациясендә куллануны хуплау, сөйләм телен үстерүгә карата кызыксыну барлыкка килүгә булышу.

***Балаларны әдәби әсәрләр уку культурасына җәлеп итү өлкәсендә***

Әдәби әсәрләрне кабул итүгә, аларның эчтәлеге, бизәлеше хакында фикер алышуга кызыксыну һәм ихтыяҗ уяту. Танып белү әдәбиятына кызыксыну уяту. «Сүзлек» (русча-татарча, татарча-русча), «энциклопедия», «хрестоматия», «белешмәләр китабы» төшенчәләре белән таныштыру. Китапка белем чыганагы буларак караш формалаштыру.

Балаларга әдәби телне, татар язучылары уйлап чыгарган геройларны аңларга, вакыйгаларны искә төшерергә һәм фаразларга ярдәм итә торган дәвамлы уку тәҗрибәсен куллану. Баланың өлкәннәргә китапны укып бетерүне сорап мөрәҗәгать итүенә, уңай тәэсирләр көтеп алуына ирешү. «Бала» интерактив мультимедиа китапханәсе материалларын куллану.

Халык авыз иҗаты әсәрләреннән (мәкаль, әйтем, табышмак һ.б.) алынган тәэсирләр запасын баету, фольклор текстын аңларга, аларның милли-сәнгати үзенчәлегенә төшенергә ярдәм итү. Балаларның иҗат итү, элементар уйлап табу, сүзләрне рифмага салу омтылышларын хуплау.

Балаларга бүгенге рәссам-иллюстраторлар (С. Киатров, Н. Кочергина, Д. Кузьмина, Э. Шевцова) иҗаты турында сөйләү, китапның бизәлешен мөстәкыйль карарга теләүләрен, рәсемнәрне чагыштыруларын хуплау. Китапка эстетик культура предметы буларак карау, китап битләрен пөхтә итеп ачу, кыстыргыч куллану, укыганнан соң китапны киштәгә алып кую кебек кагыйдәләрне өйрәтү.

Зур булмаган проза текстларының эчтәлеген, татар шагыйрьләренең шигырьләрен сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтү, текстны рольләргә бүлеп сөйләүдә, өзекләрне сәхнәләштерүдә катнаштыру. Балаларны әдәби тел мохитенә тарту.

Балаларның игътибарын тылсымлы әкиятләрнең милли үзенчәлегенә юнәлтү. Балаларда әхлакый гамәлләрнең нигезен тәшкил иткән кайгыртучанлык, авырлыкларны уртаклашу, кызгану кебек әхлакый сыйфатлар булдыру өчен, татар халык әкиятләрен куллану. Балаларга әкият героеның кылган эшләрен аңлаулары турында сөйләргә мөмкинлек бирү, геройның үз-үзен тотышындагы яшерен сәбәпләрне аңларга булышу.

Әти-әниләргә гаиләдә бала өчен уку почмагы оештырырга ярдәм итү, Республика балалар китапханәсенә язылырга, К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында сәхнәләштерелгән балалар өчен спектакльләрне карарга тәкъдим итү.

## ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ӘСӘРЛӘР

**Балаларга уку өчен**

***Җырлар, такмаклар, тел көрмәкләндергечләр, эндәшләр, әйтешләр, бармак уеннары:*** «Исәнмесез, саумысыз...»; «Бака, бака, бакырган...»; «Без уйныйбыз, уйныйбыз...»; «Ямьле бәйрәм көн иде...»; «Барыр идем урманга...»; «Саескан сары май китерә...»; «Тамчы, там...»; «Без йөрибез әйләнеп...»; «Абага...»; «Кара карга кардан бара»; «Яңгыр, яу, иләкләп...»; «Әйт әле, Чикерткә...»; «Карга әйтә...»; «Торыгыз, тор, хуҗалар...»; «Яңгыр ява, томан төшә...».

***Әкиятләр һәм легендалар:*** «Шүрәле», «Янган бүрек», «Кем көчле?», «Ике кыз», «Батыр әтәч»; «Куркак юлдаш», «Өч кыз», татар халык әкиятләре; «Ни өчен Эт белән Песи бер-берсенә дошман булганнар?», «Күгәрченнәр ни өчен гөрләшеп яшиләр, һәм гөрләмеш уены каян килеп чыккан?», легендалар.

***Дөнья халыклары әкиятләре:*** «Башак», украин халык әкияте; «Итагатьле Мәче», литва халык әкияте; «Күгәрчен белән Кырмыска», Индонезия халыклары әкияте; «Хәйләкәр әтәч», болгар халык әкияте; «Шат күңелле Чыпчык белән карт Карга», калмык халык әкияте; «Батыр Куян», вьетнам халык әкияте; «Конфет ашап тамак туямы?», корея халык әкияте; «Күкшә», якут халык әкияте.

***Шигырьләр:*** Р. Сәлах. «Көз»; С. Маршак. «Сентябрь», «Октябрь», М. Мазунов тәрҗ.; Р. Вәлиева. «Без игенчеләр булдык»; Ф. Яруллин. «Көзге табын»; С. Рәхмәтулла. «Витаминлы кыярлар», «Солдат»; Ә. Рәшит. «Банан тәмле буламы?»; З. Туфайлова. «Миннән дә зур үсәрсез»; Ш. Галиев. «Кунаклар»; Э. Шәрифуллина. «Шофёр буласым килә», «Яшел чыршы, яшь чыршы»; Г. Латыйп. «Кар яуды»; Г. Лотфи. «Балалар ярдәм итә»; Йолдыз. «Бүләк»; Ә. Кари.

«Кыш бабай бүләкләре», «Минем кунагым»; В. Хәйруллина. «Кем ул солдат?»; Г. Гыйльманов. «Ярый әле...»; Н. Исәнбәт. «Иң матур сүз»; Х. Шабанов. «Кадерлә син китапны»; Б. Рәхмәт. «Яз килә»; Л. Шәех. «Карга боткасында»; Г. Тукай. «Бала белән Күбәләк»; Ш. Маннур. «Яхшы бел»; Л. Әмирханова. «Бабам истәлеге»; Р. Бәшәр. «Кызыл ут»; Л. Нурлы. «Туган илем»; Р. Корбан. «Җиңү бәйрәме», «Кояш»; Г. Садә. «Әссәламегаләйкем!».

***Төрле ил шагыйрьләре әсәрләре:*** М. Әлимбаев. «Бәләкәй көчек», казахчадан Р. Миңнуллин тәрҗ.; Н. Думбадзе. «Энә», грузинчадан Р. Миңнуллин тәрҗ.; Г. Виеру. «Аю», молдаванчадан, русчадан Р. Миңнуллин тәрҗ.; А. Тимиркаев. «Якшәмбе көн балыкта», маричадан Р. Миңнуллин тәрҗ.

***Рольләргә бүлеп сөйләү өчен:*** Р. Вәлиева. «Керпе белән бала»; Х. Халиков. «Оныткан»; Р. Ураксина. «Фотомодель булам»; Р. Миңнуллин. «Авыл малае белән шәһәр малае...»; Н. Мадьяров. «Үрдәк белән сөйләшү»; Э. Мөэминова. «Җавап бир»; М. Хөсәен. «Безнең дусларыбыз»; Р. Арсланова. «Кошкаем».

**Яттан өйрәнү өчен**

*Татар халык авыз иҗаты:* «Карга килә – казан аса...», «Мич башында биш мәче», «Түбәтәеңне кигәнсең».

*Шигырьләр:* Г. Тукай. «Безнең гаилә»; М. Фәйзуллина. «Өлкән группага күчкәч»; Г. Зәйнашева. «Кыш килде»; Җ. Тәрҗеманов. «Якын дус»; Ш. Галиев. «Туган тел»; Н. Баян. «Яз»; Ш. Маннур. «Кояш, чык, чык!»; Р. Корбан. «Бәйрәм бүген»; Р. Миңнуллин. «Нәүрүз»; З. Туфайлова. «Тукай абый».

***Әдәби әкиятләр һәм хикәяләр:*** Г. Таһирова. «Кечкенә миләш»; С. Сәүбанова. «Мактанчык алма», «Керпе»; Ә. Гаффар. «Суалчан кунакка бара»; А. Алиш. «Каз белән Аккош», «Әбиләрдә кунакта»; Батулла. «Әбү булган аягы»; И. Дәүләтша. «Алпамыш шәһәргә килде»; Р. Вәлиева. «Ялкау Карга баласы»; Л. Толстой. «Бүре белән Тиен», Ф. Әмирова тәрҗ.; К. Ушинский. «Каз белән Торна», «Сыер», А. Әхмәт тәрҗ.; Н. Фәттах. «Ирек, Алмас һәм Җәмил»; Г. Мөхәммәтшин. «Ак песи», «Велосипедлы Мөнир»; Г. Бакир. «Йорт салалар»; М. Хәсәнов. «Көн җылынды»; Р. Мингалим. «Канатларың булса...»; З. Әхмәров. «Агачлар да авырый»; Ф. Зариф. «Татлы җәй»; Ә. Хәсәнов. «Бал дәвалый»; Я. Тайц. «Сөт елгасы», К. Котдусова тәрҗ.

**Өстәмә әдәбият**

*Татар халык авыз иҗаты:* «Чырык-чырык тургай...»; «Бие, бие, Хәйбулла...»; «Борын-борын заманда...»; «Бер әби белән бабай...»; «Таулар биек таллардан...»; «Чыпчык, чыпчык...».

*Шигырьләр:* Ф. Гыйззәтуллина. «Әдәпле кыз»; Р. Сәлах. «Бүләк кирәк кызларга»; Р. Арсланова. «Якын дустым»; М. Җәлил. «Карак песи»; Йолдыз. «Гайшә белән дәү әни»; Р. Корбан. «Ныграк авыртыр иде»; Р. Миңнуллин. «Почмакта торам»; Г. Морат. «Туган тел»; М. Фәйзуллина. «Бал корты»; А. Барто. «Елга», З. Мансур тәрҗ.

*Әдәби әкиятләр һәм хикәяләр:* Г. Лотфи. «Тамчы»; Батулла. «Аюлар»; Ә. Бикчәнтәева. «Өстәл янында»; Н. Кәримова. «Кое чыпчыгы»; А. Хәсәнов. «Бал кортлары һәм яңгыр»; В. Монасыйпов. «Шифалы табиблар»; Г. Гыйльманов. «Бүләк»; Т. Әйди. «Дачада»; М. Хәсәнов. «Фәридә кошы»; Н. Каштан. «Кем тизрәк үскән?»; Җ. Дәрзаман. «Актырнак белән Назбикә».

## • СӘНГАТИ-ЭСТЕТИК ҮСЕШ

**Балаларда чынбарлыкның эстетик ягына кызыксынуны арттыру, сәнгатьнең төрле төрләре һәм жанрлары (сүз, музыка, сынлы сәнгать), шул исәптән халык иҗаты белән таныштыру, сәнгати-эстетик чынбарлыкның төрле төрләренә тарту, иҗади сәләтләрне ачу, сәнгати идеяләрне тормышка ашыруда инициатива һәм мөстәкыйльлек күрсәтү ихтыяҗын**

**үстерү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең сәнгати-эстетик үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балаларда чынбарлыкның эстетик ягына кызыксынуны арттыру, сәнгатьнең төрле төрләре һәм жанрлары, шул исәптән халык иҗаты белән таныштыру өлкәсендә***

Балаларны сынлы сәнгатькә тарту, аңа карата кызыксынуны үстерү. Татарстан Республикасы сынлы сәнгать осталарының күренекле әсәрләре («Кечкенә Тукай», Х.И. Казаков; «Хөкем алдыннан», «Юмарт август», Х.А. Якупов; «Тәрәзә буенда», Р.Ф. Хуҗин; «Авыр елларда», А.Г. Ширяева һ.б.) белән таныштыру.

Балаларга «пейзаж» төшенчәсен аңлату, Алабугада туып үскән атаклы рус пейзажисты И.И. Шишкинның иҗаты («Нарат урманында иртә», «Арыш басуы», «Корабельная роща» һ.б.) турында сөйләү. Сурәт тудырган тойгыларны чагылдыра, аны аңлый, картинаны үз тәҗрибәләре белән чагыштыра белү күнекмәләрен үстерү.

Сәнгатьнең иң борынгы төрләренең берсе булган керамика, әлеге юнәлештә эшләгән хәзерге көн осталарының (Б. Шубин, А. Абзгильдин, Р. Миргалимов, А. Миңнуллина) иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Балаларның игътибарын керамика әйберләренең формасында да, аларның бизәлешендә дә чагылыш тапкан милли үзенчәлеккә җәлеп итү. Милли орнамент элементларын аерып ала белергә өйрәтү.

Балаларның игътибарын рус милли киеме үзенчәлекләренә юнәлтү, аны традицион татар костюмы (баш киеменең, өс һәм аяк киемнәренең, бизәнү әйберләренең үзенчәлекләре) белән чагыштыру. Милли киемнәрдәге охшашлыкны һәм аерымлыкларны табарга булышу.

Балаларны күн мозаикасы сәнгате белән таныштыру. Күн чүәк, башмак, читекләрне, читекнең алгы өлешендә, кунычында урнашкан бизәкләрне карау. Балаларның игътибарын берберсенә тоташтырылган ачык, җете элементларны бердәм композициягә туплаучы төс фонына, кәкре сызыклы формадагы бизәкләрнең фонга контраст төстәге ефәк җеп белән беркетелүенә юнәлтү.

Балаларны туган шәһәрләренең архитектурасы белән таныштыруны дәвам итү. Бина конструкциясенең аның билгеләнешенә (торак, йорт, мәчет, кинотеатр һ.б.) бәйле булуын аңларга булышу. Бер үк билгеләнештәге архитектура корылмаларының охшашлыгына һәм аерымлыгына игътибар итү.

Кремль архитектура ансамбле (Спас манарасы, Сөембикә манарасы, Кол Шәриф мәчете, Благовещение соборы һ.б.) белән таныштыру. Тарих һәм мәдәният объектларын аңлый белү тәҗрибәсен формалаштыру. Кремль тарихы белән кызыксыну уяту.

Шәһәрнең агачны уеп ясалган бизәкләр белән бизәлгән борынгы агач йортлар, утар корылмалары (капка, коймалар) сакланып калган борынгы өлешенә (Казанның Иске Татар бистәсе) экскурсия оештыру. Уеп ясалган бизәкләрнең характерына, аларның пропорцияләренә һәм төсләренә (татар чигүенә, күн мозаикасына хас) игътибар итү.

Балаларның китап иллюстрацияләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү. Р. Миңнуллин, Ш. Галиев, Й. Шәрәпова һ.б.ның шигырьләрендәге герой образларын сурәтләгән рәссамиллюстраторлар иҗаты белән таныштыру. Бер үк әдәби әсәр буенча төрле рәссамнар тарафыннан ясалган иллюстрацияләрне чагыштыра белергә, аларны ничек кабул итүләре турында сөйләргә өйрәтү.

***Сәнгати-эстетик чынбарлыкның төрле төрләренә тарту, иҗади сәләтләрне ачу, сәнгати идеяләрне тормышка ашыруда инициатива һәм мөстәкыйльлек күрсәтү ихтыяҗын үстерү өлкәсендә***

**Сынлы сәнгать эшчәнлеге**

*Рәсем ясау*

Балаларны милли бизәкләр белән таныштыруны дәвам итү. Чәчәк-үсемлек (кыр, болын, бакча) мотивларын, җилпәзә пальма яфрагы һәм ярты яфрак мотивларын, лотос, үсемлек яфрагы мотивларын һ.б.ны карау. Композициянең характерына (симметрияле, асимметрияле), бер үк вакытта төрле төстәге мотивлар кулланыла торган чәчәк букетына игътибар итү.

Балаларның сәнгати тәҗрибәләрен баету: вертикаль сабакка карата ике якта да бертөсле итеп ясалган симметрияле букет ясау ысулын күрсәтү.

Кием, баш киеме, аяк киеме (түбәтәй, алъяпкыч, читек һ.б.), көнкүреш кирәк-яраклары (сөлге, орчык һ.б.) силуэтларында декоратив рәсем ясау техникасын камилләштерү, төрледән-төрле милли орнамент элементларын куллануларын хуплау.

Яңа төсләр (шәмәхә) һәм аларның төсмерләре (куе шәмәхә, аксыл шәмәхә) белән таныштыру. Яңа төсмерләр алу өчен буяуларны кушарга өйрәтү. Мөстәкыйль рәвештә төсләр кушылмасын сайлый алуны хуплау.

Балаларны татар гамәли сәнгате мотивлары буенча башкарыла торган күмәк эшләргә җәлеп итү. Үзләштерелгән ысулларны катнаштыру, төрле декоратив рәсем ясау ысулларын сәнгати конструкцияләү, аппликация, балалар дизайнының төрле техникалары белән берләштерү мөмкинлеген бирү.

Көнкүреш кирәк-яракларын, татар халык әкиятләре персонажларын сурәтләү тәҗрибәсен баету. Г. Тукай, А. Алиш («Сертотмас үрдәк кемне очраткан», «Кем иң көчле», «Шүрәле белән Былтырның очрашуы», «Кәҗә белән Сарык» һ.б.) әкиятләре буенча сюжетлы композицияләр ясауны хуплау.

Балаларның туган шәһәрләре (авыллары) иҗтимагый тормышында булган кызыклы вакыйгаларны рәсемдә чагылдыру омтылышын хуплау, ясалган рәсем буенча сөйләргә өйрәтү. Сәнгати иҗатны иректе чагылдырырга ярдәм итү.

*Әвәләп ясау*

Актүбә һәм Шәмәрдән уенчыкларын сәнгати кабул итүләрен, аларны карап, әвәләп ясау күнекмәләрен баету, уенчыкларның характерлы үзенчәлекләрен чагылдырырга өйрәтү.

Балаларны рельефлы сурәтләү техникасы белән таныштыру. Карап ясала торган предметка хас үзенчәлекләрне исәпкә алып, пропорцияләрне дөрес сайлап, өчле яфракның ничек әвәләп ясалуын күрсәтү. Балаларга әвәләп ясауны плинтус – нигездән башларга кирәклекне аңлату, нигезгә стека очы ярдәмендә рельефның контурлы рәсемен төшерү.

Тасма ысулы белән әвәләү, тоташ бер кисәк балчыктан әвәләү техникаларын алга таба үзләштерергә булышу, предметларны (чүлмәк, ваза, чүмеч, комган һ.б.) вак детальләр белән тулыландыру, стека, штамп, ябыштыру ысулы ярдәмендә бизәү.

Мөстәкыйль рәвештә төп фикерне билгеләү, гадирәк сюжет һәм тәэсирле образлар («Сабан туенда», «Көянтә күтәргән кыз», «Өч кыз» һ.б.) тудыру теләкләрен хуплау.

Әдәби әсәр геройларын (Су анасы, Шүрәле, Камыр батыр һ.б.) үзләре аңлаганча сурәтләү белән кызыксынуны хуплау. Ирекле иҗат чагылышын үстерергә ярдәм итү, инициативаларын хуплау.

*Аппликация*

Эчтәлеген катлауландыра һәм төрле сурәтләрне ясау мөмкинлеген киңәйтә барып, аппликация сәнгате белән кызыксынуны үстерү.

Гармун кебек бөкләп куелган кәгазьдән милли бизәкнең бертөрле элементларын (гөлҗимеш, күкчәчәк, ромашка таҗларын, яфрак һ.б.), кәгазьне урталай бөкләп, симметрияле сурәтләрне (өчле яфрак, пальметта, лалә, кыңгырау һ.б.) кисүнең яңа ысулларын үзләштерү өчен

шартлар тудыру. Композициядә төсләрне тагын да җетерәк күрсәтү өчен, аппликациядә ерту ысулын куллану. Төрле сәнгать ысулларын берләштерә белүләрен хуплау.

Дәлия (георгин), чалмабаш (пион), кашкарый (астра) кебек чәчәкләрдән композиция ясау өчен күләмле аппликациягә өйрәтү. Композициягә сурәтне баета торган детальләр (кошлар, бал кортлары, күбәләк һ.б.) өстәүне хуплау.

Төрле билгеләнештәге архитектура корылмалары силуэтларын (цирк, вокзал, супермаркет, торак йорт һ.б.) кәгазьгә ябыштырып төзү юлы аша сәнгати тәҗрибәне баету. Планлаштыруның күргәзмә ысулларын (эскиз, композиция схемасы) кулланып, эшне планлаштыру күнекмәсен үстерү.

**Музыкаль эшчәнлек**

Татар музыкасын интонацион-мелодик яктан кабул итүне, аның нигезендә яткан эчтәлеген аңлауны үстерү. Музыкаль тәэсирләр байлыгын арттырырга, аерым фрагментлар буенча көйне танырга өйрәтү. Көйнең характерын, андагы кәефне билгеле белергә өйрәтү, музыкаль хәтерне яхшырту.

«Музыка сәнгате жанры» (җыр, бию, марш) төшенчәсе белән таныштыру. Татар композиторларының кайбер музыка әсәрләренең жанрларын билгеләргә, таныш музыка уен коралларының (думбра, курай, кубыз, тальян гармун һ.б.) яңгырашын танырга өйрәтү. Музыка әсәре турында әңгәмәдә катнашуларын хуплау.

Татарстан Республикасының Дәүләт гимны көе белән таныштыру, ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү.

Матур яңгырашлы ялгыз җырчы һәм хор башкаруында вокаль әсәрләрне тыңлау аша музыканы ишетә белү тәҗрибәсен баету. Бу әсәрләрне яңадан тыңлыйсы килү теләге уяту.

Милли репертуар нигезендә җырлау күнекмәләрен камилләштерү. Җыр характерын хисләр аша күрсәтеп һәм баланың табигый тавыш тибын исәпкә алып, җырлау эшчәнлеген оештыру.

Катлаулы вариантларын эшкәртү барышында бию хәрәкәтләрен башкару техникасын камилләштерү: «тыпырдау», «борма», «бишек», «чүгәләү», «төп йөреш», «үкчәдә йөреш», «кырын йөреш», «парлап әйләнү» һ.б. Бию хәрәкәтләрен кабатлаганда хәрәкәтләр импровизациясен хуплау. Татар (рус) әйлән-бәйлән уеннарында йөрү хәрәкәтләре белән таныштыру, табигый хәрәкәтләрне җиңел итеп башкаруны формалаштыру.

Идел буе халыкларының бию элементлары белән таныштыру. Хәрәкәт аша музыканың характерын, аның эмоциональ образлы эчтәлеген бирү күнекмәләре тәрбияләү.

**МУЗЫКА ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ЯКЫНЧА ИСЕМЛЕГЕ**

**Музыка тыңлау**

«Мин яратам сине, Татарстан!», Р. Андреев муз., Р. Рәкыйпов сүз.; «Көзге җыр», «Бүген бәйрәм», М. Мозаффаров муз.; «Күңелле бию», А. Леман муз.; «Уракчы кыз», татар халык көе, Р. Еникиева эшкәрт., Н. Исәнбәт сүз.; «Марш», «Таң», Р. Еникиев муз.; «Бишек җыры», «Иртә» Н. Җиһанов муз.; «Җирдә миңа ни кирәк?», Ф. Әхмәтшин муз., Ш. Галиев сүз.; «Марш», Л. Хәйретдинова муз. («Мәкерле песи» операсы); «Ямансу», Н. Җиһанов муз. («Балалар өчен пьесалар» альбомы); «Кыш бабай белән аю русча бииләр», Р. Яхин муз.; «Полька», З. Хәбибуллин муз.; «Кояш гомере», Ф. Әхмәдиев муз., Г. Зәйнашева сүз.; «Вальс», С. Сәйдәшев муз.; «Егет биюе», «Татар кызы бии», «Клоун биюе», Ю. Виноградов муз.; «Карауҗа авылы көе», татар халык җыры, Р. Еникиева эшкәрт.; «Туган тел», татар халык көе, Г. Тукай сүз., Р. Еникиева эшкәрт.; «Язгы тамчылар», Р. Еникиев муз. («Табигать күренешләре» циклы); «Шүрәле», А. Ключарёв муз.; «Урман күбәләге», «Көтүче малай уйный», Л. Батыр-Болгари муз. («Авыл

күренешләре» циклы); «Уйлану», И. Якубов муз.; «Куркыныч төш», А. Монасыйпов муз. («Дүрт пьеса» циклы); «Кунакларны каршылау», С. Сәйдәшев муз., Х. Рахман сүз.

**Җырлау**

*Музыкаль ишетү сәләтен һәм тавышны үстерү күнегүләре:* «Баскыч», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз. һәм сүз.; «Сәгать», Ф. Әхмәтов муз., М. Җәлил сүз.; «Бишек җыры», С. Бәдертдинова муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Саный беләм», Р. Еникиев муз., Җ. Дәрзаман сүз.; «Бу кайчак, туган?», М. Зәйнуллина муз., Г. Тукай сүз.; «Буран», Р. Еникиева муз., Г. Толымбай сүз.; «Песнәк», Р. Тимершина муз., Х. Гарданов сүз.; «Беренче яңгыр», Ә. Бакиров муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Гөрләвек», С. Бәдертдинова муз. һәм сүз.; «Яз», Ф. Җәләлетдинова муз., Н. Гайсин сүз.; «Күбәләк», Р. Еникиева муз., Л. Лерон сүз.; «Кошчык», С. Ихсанова муз., Ф. Абдуллина сүз.; «Паровоз», С. Бәдертдинова муз., С. Әхмәтов сүз.

*Җырлар:* «Балалар бакчасында», Н. Зарипова муз., Н. Гайсин сүз.; «Тыныч йокы», Ф. Шәймәрданова муз., Ш. Галиев сүз.; «Үтте – китте», Л. Хисмәтуллина муз., К. Нәҗми сүз.; «Минем әби», А. Ключарёв муз., Г. Латыйп сүз.; «Иң якын кешем», Л. Хисмәтуллина муз., Л. Юнысова сүз.; «Кар йомшак», С. Вәлиди муз., Н. Гайсин сүз.; «Тауда», Р. Еникиева муз., Л. Лерон сүз.; «Кыш бабай», Л. Шиһабетдинова муз., М. Фәйзуллина сүз.; «Без – кечкенә солдатлар», Р. Гәрәева муз. һәм сүз.; «Бәйрәм бүген», Ш. Тимербулатов муз., Р. Корбан сүз.; «Минем әни», Ф. Кәримуллина муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Әниләр бәйрәме», М. Бикбова муз., Г. Гомәр сүз.; «Яз җитә», Җ. Фәйзи муз., Ф. Кәрим сүз.; «Яз», Р. Ахиярова муз., Г. Рахманколый сүз.; «Сыерчык», И. Шәмсетдинов муз., Г. Лотфи сүз.; «Тукай абый», М. Шәмсетдинова муз., З. Туфайлова сүз.; «Яңгыр, яу!», И. Якубов муз., Р. Вәлиева сүз.; «Наза йөри бакчада», Р. Еникиев муз., Җ. Дәрзаман сүз.

*Җыр иҗаты:* «Кикрикүк», М. Зәйнуллина муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Аюым», М. Зәйнуллина муз., Җ. Дәрзаман сүз.; «Ап-ак иткән», Р. Тимершина муз., Ф. Яруллин сүз.; «Гөлләр», Р. Тимершина муз., З. Туфайлова сүз.; «Яз», Ф. Шәймәрданова муз., Ш. Галиев сүз.; «Кәккүк», Р. Тимершина муз., халык сүз.; балалар фольклорыннан: юаткычлар, үртәвечләр, санамышлар һәм башка кыска татар халык җырлары.

**Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр**

*Уен күнегүләре:* «Гади адым», татар халык көе («Сандугач-күгәрчен»), М. Мозаффаров эшкәрт.; «Яшь физкультурачылар», Ә. Бакиров муз.; «Марш», Н. Җиһанов муз.; «Йөрибез-йөгерәбез», татар халык көе («Талы, талы»), Р. Еникиева эшкәрт.; «Бию», Ф. Җәләлетдинова муз.; «Гөлнара полькасы», Р. Халитов муз.; «Куллар өчен күнегү», Х. Вәлиуллин муз. («Вальс»); «Сыгылу», татар халык көе («Тал арасы»), Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Тыпырдау», татар халык көе («Эрбет»), Г. Беляева эшкәрт.; «Кул сугып уйнау», татар халык көе («Тамчы, там»), М. Мозаффаров эшкәрт.

*Предметлар белән күнегүләр:* «Уңыш бәйрәмендә», Л. Хәмиди муз.; «Флаглар тотып тезелү», М. Мозаффаров муз.; «Яулык бирәм», татар халык көе («Матур булсын»), Г. Беляева эшкәрт.; «Шылтыравыклар белән күнегү», Ф. Шәймәрданова муз.; «Туплар белән күнегү», Ә. Шәрәфиев муз.; «Вальс», Р. Яхин муз.

*Сәхнәләштерелгән этюдлар:* «Каз канаты», татар халык көе, А. Ключарёв эшкәрт.; «Сикергеч», Җ. Фәйзи муз.; «Кечкенә балыкчы», Р. Зарипов муз.; «Кар атышып уйныйбыз», Ф. Шәймәрданова муз., халык сүз.; «Песи белән тычкан», Л. Шиһабетдинова муз.; «Миңлебай», Р. Еникиева муз., халык сүз.; «Табигать кочагында», Р. Кәлимуллин муз.; «Яңгыр», И. Якубов муз.; «Бүре һәм кәҗә бәтиләре», татар халык көе, А. Монасыйпов эшкәрт.; «Урман кайтавазы», С. Бәдертдинова муз. һәм сүз.

*Биюләр:* «Дуслар», татар халык көе, М. Мозаффаров эшкәрт.; «Парлы бию», татар халык көе, З. Хәбибуллин эшкәрт.; «Күмәк бию», татар халык көе, А. Ключарёв эшкәрт.; «Парлы бию», татар халык көе, Ф. Фәизова эшкәрт.; «Иптәшеңне алыштыр», башкорт халык көе, А. Кобагошев эшкәрт.; «Чакыру», татар халык көе («Әпипә»), Р. Еникиева эшкәрт.; «Такыяләр белән бию», «Яулыклар тотып бию», Ф. Шәймәрданова муз.; «Күңелле бию», Л. Хисмәтуллина муз.; «Егетләр биюе», татар халык көе, Р. Сабитов эшкәрт.; «Суга», татар халык көе, Р. Еникиева эшкәрт.; «Биергә чакыру», рус халык көе, И. Арсеев эшкәрт.; «Әйләнеп бас», рус халык көе, С. Разорёнов эшкәрт.; «Тыпырдатып басабыз», чуваш халык көе, Г. Воротникова эшкәрт.; «Әйдәгез биибез», удмурт халык көе, В. Емельянов эшкәрт.

*Характерлы биюләр:* «Миләшләр биюе», «Пингвиннар биюе», Л. Хисмәтуллина муз.; «Гөмбәләр биюе», «Кышкы вальс», Ф. Шәймәрданова муз.; «Аю балалары биюе», В. Виноградов муз.; «Петрушкалар биюе», Л. Шиһабетдинова муз.; «Шаяннар», Ә. Абдуллин муз.; «Чылдыр-чылдыр», А. Ключарёв муз.; «Тамчылар биюе», М. Кәшипов муз. («Яңгыр вальсы»), Р. Еникиева эшкәрт.

*Түгәрәк уеннары:* «Яңгыр», татар халык җыры, М. Зәйнуллина эшкәрт.; «Куш кулым», татар халык уен җыры, Р. Тимершина эшкәрт.; «Әйдә, дустым, биергә», В. Вәлиева муз. һәм сүз.; «Кыш бабай», татар халык көе, Р. Еникиева эшкәрт., Ә. Кари сүз.; «Чыршы янында бию», Ф. Җәләлетдинова муз.; «Яңа ел җыры», Г. Гәрәева муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Чыршы, чыршыкай», Л. Хисмәтуллина муз. һәм сүз.; «Өммегөлсем», татар халык көе, Ф. Фәизова эшкәрт.; «Тамчы, там», татар халык җыры, Р. Сабитов эшкәрт.; «Яз җыры», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Әйлән-бәйлән уйныйбыз», Л. Батыр-Болгари муз., Батулла сүз.; «Түгәрәк алан», татар халык уен җыры, Р. Сабит эшкәрт.; «Җырлап бию», татар халык көе, Р. Зарипов эшкәрт.

*Музыкаль уеннар:* «Шаяру», татар халык көе, Ш. Монасыйпов эшкәрт.; «Шылтыравык бир», Р. Еникиев муз.; «Җитез бул!», Р. Ахиярова муз.; «Түбәтәйле», «Кыңгыраулар белән уен», Ф. Шәймәрданова муз.; «Үзеңә пар тап», татар халык көе, М. Зәйнуллина эшкәрт.; «Чәчәк бәйләме», Б. Мөлеков муз. («Шаян фикер»); «Атта», Р. Ахиярова муз. («Галоп»); «Соңга калма», М. Бикбова муз.; «Ябалак», Р. Кәлимуллин муз. («Уен»); «Кәккүк», С. Сәйдәшев муз. («Ямьле җәй»); «Уенчык эзлә», рус халык көе, В. Агафонников эшкәрт.; «Тозак», рус халык көе, Л. Сидельников эшкәрт.; «Давыл», башкорт халык уены; «Таралыгыз», чуваш халык уены; «Парлап уйнау», удмурт халык уены; «Үз урыныңны бир», мари халык уены.

*Җырлы уеннар:* «Диңгез сурәтләре», Ф. Шәймәрданова муз., халык сүз.; «Куян белән уен», татар халык көе, Э. Шәрифуллина сүз., Р. Тимершина эшкәрт.; «Керпе белән уен», татар халык көе, Р. Вәлиева сүз., Г. Гыйләҗетдинова эшкәрт.; «Кем беренче?», татар халык көе, Г. Гыйләҗетдинова сүз., Г. Гыйләҗетдинова эшкәрт.; «Яулык салыш», татар халык көе, Р. Еникиева эшкәрт.; «Без бардык урманга», Ш. Мәҗитов муз. һәм сүз., «Яңгыр», И. Байтирәк муз. (өзек); «Мәликә», Ф. Шәймәрданова муз., халык сүз.; «Үрмәкүч», татар халык уены, Р. Тимершина эшкәрт.; «Бакалар һәм торна», Ф. Шәймәрданова муз., Р. Насыйбуллина сүз.; «Башмакчы», татар халык уены, М. Зәйнуллина эшкәрт.; «Тирмә», башкорт халык көе, Г. Гәрәева сүз., Ю. Тугаринов эшкәрт.; «Исемен әйт!», башкорт халык уены, Р. Тимершина эшкәрт.; «Карга», рус халык уены, Е. Тиличеева эшкәрт.; «Карлыгач», чуваш халык уены; «Каз йөзә», удмурт халык уены, Г. Матвеев эшкәрт.; «Саескан», мари халык уены, В. Алексеев муз., С. Чевайн сүз.

*Биюле уен иҗаты:* «Әпипә», татар халык көе, Р. Еникиева эшкәрт.; «Мәче», татар халык көе, Р. Зарипов эшкәрт.; «Курчак», М. Бикбова муз.; «Нәни төлке», татар халык көе, А. Монасыйпов эшкәрт.; «Шаян каз бәбкәсе», татар халык көе, Р. Еникиев эшкәрт.; «Бию», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Җырлап бию», татар халык көе, Р. Зарипов эшкәрт.; аудиоязмадагы бию көйләренә ирекле биюләр.

**Музыкаль дидактик уеннар**

*Музыкада аваз югарылыгын ишетү сәләтен үстерү:* «Баскыч»; «Зур һәм кечкенә кыңгырау»; «Музыкаль лото»; «Әниләр һәм бәбиләр».

*Ритмны тою сәләтен үстерү:* «Ритмик таякчыклар»; «Мин уйныйм – син кабатла!»; «Поезд», Р. Ахиярова муз.

*Тембрны аера белү сәләтен үстерү:* «Нәрсәдә уйныйм?», «Кем йорты?».

*Динамик төсмерләрне ишетү сәләтен үстерү:* «Быргы», «Урман кайтавазы», С. Бәдертдинова муз. һәм сүз.; «Эзлә».

*Музыканы кабул итү һәм музыкаль хәтерне үстерү:* «Игътибарлы бул!», «Музыкаль кибет», «Безнең җырлар».

**Балалар музыка уен коралларында уйнау**

«Әпипә», татар халык көе, Р. Еникиева эшкәрт.; «Хайваннарны чакыру», «Кәккүк, чыпчык», «Паровоз», М. Зәйнуллина муз., халык сүз.; «Яшел урманда», Н. Бакиева муз. һәм сүз.; «Әйһәйлүк», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Болында», Л. Шиһабетдинова муз., Ә. Ерикәй сүз.

**Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәре**

*Сәхнәләштерү һәм музыкаль спектакльләр:* «Уңыш җыйдык», Н. Лотфуллина муз., Р. Асретдинова сүз.; «Әтәч һәм балалар», З. Хәбибуллин муз., Б. Рәхмәт сүз.; «Песи», М. Мозаффаров муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Кем уяткан Ләйләне?», С. Сабирова муз., С. Сөләйманова сүз.; «Кирәк сабын кисәге», М. Мозаффаров муз., М. Мазунов сүз.; «Наза йөри бакчада», Р. Еникиев муз., Җ. Дәрзаман сүз.; «Бәбкәләр һәм карга», Ф. Шәймәрданова муз., Р. Вәлиева сүз.; «Һәркем эштә», Г. Тукай; «Яшелчәләр бәхәсе», В. Хәйруллина; «Чукмар белән Тукмар», А. Алиш; «Батыр әтәч», татар халык әкияте.

*Әдәби-музыкаль композицияләр:* «Алтын көз», «Өлкәннәргә – хөрмәт», «Әниләр көне», «Татар теле – туган телем!», «Капка төбе», «Җырлап-биеп уйныйбыз», «Без – Тукай шәкертләре», «Мин яратам сине, Татарстан!», «Хуш киләсез, кунаклар», «Юлда йөри беләсеңме?».

*Тематик кичәләр:* Н. Җиһановның «Балалар өчен пьесалар» альбомы, «Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары», «Халык уеннары», «Халык бәйрәмнәре», «Идел буенда яшәүче халыкларның мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре» (танышу).

*Бәйрәмнәр:* «Хуш киләсең, Яңа ел», «23 февраль – Ватанны саклаучылар көне», «8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне», «9 Май – Җиңү бәйрәме», «Милли бәйрәм – Сабан туе».

## • ФИЗИК ҮСЕШ

**Балаларда сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен тәрбияләү, аларда үзләренең гәүдә төзелеше һәм физик мөмкинлекләре турында күзаллауларны баету, хәрәкәт итү тәҗрибәсен үзләштерү һәм хәрәкәт итү активлыгын камилләштерү, спортның кайбер төрләре турында беренчел күзаллауларны формалаштыру, кагыйдәле хәрәкәтле уеннарны өйрәтү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең физик үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балаларда сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен тәрбияләү өлкәсендә***

Балаларда сәламәт яшәү рәвешен тәшкил итүче (хәрәкәт активлыгы, йокы, ял, дөрес туклану һ.б.) һәм сәламәтлекне какшатучы факторлар турындагы күзаллауларны арттыру. Сәламәтләндерү чараларында балаларны актив катнаштыру өчен шартлар тудыру.

«Туклану режимы» төшенчәсе, милли камыр ризыклары: өчпочмак, бәлеш, бөккән, кыстыбый, кабартма һәм башкалар белән таныштыру.

«Эчү режимы» төшенчәсе, файдалы эчемлекләр: әйрән (катыктан ясалган эчемлек), сөзмә

(сөзелгән катык), кымыз һәм башкалар белән таныштыру. Сенсор тоемлауларга нигезләнеп, ашамлыкның сыйфатын билгеләргә өйрәтү.

Кайбер дәвалау-профилактика процедураларының йогынтысы, аерым авыруларның сәбәпләре һәм аеруча киң таралганнарын кисәтү чаралары турында элементар күзаллаулар формалаштыру. Экстремаль хәлләрдә (борыннан кан китү, эссе яисә кояш сугу һ.б.) беренче ярдәм күрсәтүнең иң гади ысуллары белән таныштыру.

Үз хәлен тасвирлый белергә өйрәтү.

Авыру кешенең хәленә керә белү хисе тәрбияләү. Баланың авыру кешегә хәленнән килгәнчә ярдәм итүен (дару, стакан белән су бирү, өстенә ябу, аралашу һ.б.) игътибарсыз калдырмау.

***Балаларның хәрәкәт итү активлыгын камилләштерү, аларда үзләренең гәүдә төзелеше һәм физик мөмкинлекләре турында күзаллауларны үстерү; спорт турында башлангыч күзаллауларны формалаштыру өлкәсендә***

Балаларда спорт командалары (хоккей буенча – «Ак Барс», футбол буенча – «Рубин», баскетбол буенча – «УНИКС», волейбол буенча – «Зенит», «Динамо» һ.б.) турындагы күзаллауларны тирәнәйтү. 2013 елда узган XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына һәм Казанда узган башка ярышларга (2015 елгы су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты, 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионаты матчлары, 2019 елда нәфис гимнастика буенча дөнья кубогы этабы, 2022 елда спорт гимнастикасы буенча Россия чемпионаты һ.б.) төзелгән спорт комплексларының төрләре белән таныштыру. Балалар олимпия хәрәкәтен хуплау.

Елның салкын вакытында балаларга чанада, чаңгыда, җылы вакытта самокатта йөрергә, футбол, бадминтон, балалар теннисы һ.б. уеннар уйнарга мөмкинлек тудыру. Балаларда спортның җәйге төрләре һәм аларда катнашу өчен кирәкле физик мөмкинлекләр турында күзаллауларны үстерү.

Ике тәгәрмәчле самокатта, ике яисә өч көпчәкле велосипедта уңга һәм сулга борылып, әйләнә буенча йөрү, бормалы хәрәкәтләр ясап йөрү өчен шартлар тудыру. Үз хәрәкәтләре белән идарә итү күнекмәләрен үстерү, табигый хәрәкәт активлыгын канәгатьләндерү.

Милли уеннар, ярыш элементлары белән таныштыру: «Капчык киеп йөгерү», «Көянтә күтәреп йөгерү», «Йомырка кабып йөгерү», «Катык», «Чүлмәк вату» һ.б. Милли уен-ярышларда катнашудан балаларның уңай хисләр алуына ирешү.

Идел буе халыкларының уеннары һәм аларның кагыйдәләре белән таныштыру. Ярыш элементлары булган уеннарда катнашуларын, мөстәкыйль оештыруларын хуплау. Гадел көндәшлек культурасын, уен кагыйдәләрен саклый белүне үстерү.

## ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАРНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ

***Йөгерүле уеннар.*** «Куышу», «Карусель», «Почмак алыш», «Урыныңны тап!», «Балалар һәм әтәч», «Песи һәм тычкан», «Төлке һәм тавыклар», «Балыклар», «Куяннар һәм төлке», «Чыпчык, чык!», «Чәчәк бәйләме», «Мин качам, син тот!», «Яулык».

***Сикерүле уеннар.*** «Кармак», «Бау аша сикер!», «Бүре һәм куяннар», «Кучтек», «Кем тизрәк?», «Идәндә калма!», «Сазлык».

***Шуышулы һәм үрмәләүле уеннар.*** «Аю һәм бал кортлары», «Янгын сүндерүчеләр», «Соңга калма!».

***Тупны ыргыту һәм тотып алу уеннары.*** «Аучы һәм куяннар», «Кыршау эченә ыргыт!», «Тупны ыргыт!», «Тупны сетка аша ыргыт!», «Серсо».

***Эстафета, ярыш уеннары.*** «Кем тизрәк җыелыр?», «Кыршау тәгәрәтү», «Флаг янына!», «Тупны тизрәк тапшыр!», «Каршылыклар юлы», «Кайсы төркем җитезрәк?».

***Татар халык уеннары.*** «Кемдә йөзек?», «Мияу, мияу, нинди төс?», «Ак димә, кара димә...», «Буяу сатучы һәм буяулар», «Очты, очты...».

***Рус халык уеннары.*** «Шат балалар», «Ике суык», «Диңгез дулкынлана», «Тилгән».

***Башкорт халык уеннары.*** «Буяу сатыш», «Давыл», «Без уникe кыз идек...».

***Мари халык уеннары.*** «Биляша», «Туп тәгәрәтү», «Бөҗра кемдә?».

***Мордва халык уеннары.*** «Козгын», «Куяннар», «Яулыклар».

***Удмурт халык уеннары.*** «Туп һәм чокыр», «Тоттым!», «Кәҗә бәтиләре һәм этләр».

***Чуваш халык уеннары.*** «Чәчәкләр», «Диңгездә –ерткыч!», «Таралыгыз!», «Балыклар».

## МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ

(6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

### • ИҖТИМАГЫЙ-КОММУНИКАТИВ ҮСЕШ

**Балада үзенә һәм башка кешеләргә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү, коммуникатив һәм иҗтимагый, шул исәптән мәгълүмати-иҗтимагый компетентлыкны, уен эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең иҗтимагый-коммуникатив үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балада үзенә һәм башка кешеләргә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү өлкәсендә***

Гаилә тарихына карата (әби, карт әби, бабай, карт бабай) кызыксыну формалаштыру. Авыр сугыш (сугыштан соңгы) елларына туры килгән балачаклары турында сөйләүгә балаларда кызыксыну уяту. Аларның уңышларын, бүләкләрен игътибарсыз калдырмау, гаиләгә карата горурлык хисе тәрбияләү.

Гаилә традицияләрен саклау, анда кабул ителгән кагыйдәләрне үтәү, гаилә тантаналарында, уртак эшләнәсе эшләр, чыгымнар турында уртак фикер алышуда катнашырга этәрү. Гаилә әгъзалары белән татарча аралашуны хуплау.

Якындагы социумда үз урыны, үзенең теге яисә бу төркем (балалар бакчасына йөрүче бала, халык биюләре ансамблендә катнашучы, спорт мәктәбе укучысы, булачак гимназист һ.б.) вәкиле булуы турында күзаллаулар формалаштыру.

Тирә-юньдәгеләргә карата уңай мөнәсәбәт, кешеләргә (аларның социаль чыгышына, нинди милләттән, диннән булуына, теленә, җенесенә һәм яшенә дә карамастан), аларның хисләренә, фикерләренә, карашларына карата ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү, үзеңнең килешмәвеңне дәлилли, ышандыра белү һәм башка күнекмәләрен үстерү. Төрле илләрдәге кешеләр һәм этнослар белән уңай мөнәсәбәтләр кору, милләтара аралашу культурасын үстерү, позитив аралашуның әһәмиятен аңлату.

Балалар белән республикада, илнең төрле төбәкләрендә бара торган вакыйгалар турында фикер алышу, төрле континентларда яшәүче халыклар тормышы, аларның үзара дус-тату яшәргә теләүләре турында сөйләү.

Балаларга инвалидлар, ялгыз калган өлкәннәр тормышында нинди авырлыклар килеп чыгуы, аларның нинди ярдәмгә мохтаҗ булулары турында сөйләү. Балаларда хәлгә керергә, кулдан килгәнчә булышырга, шатлыклары белән бүлешергә әзер булуларын чагылдырырга ярдәм итү.

Әйләнә-тирә табигатьне кайгыртуга юнәлдерелгән күмәк эшләрдә (ишегалдында яисә балалар бакчасы участогында – агач, түтәлләргә чәчәкләр утырту, аларга су сибү, кышын кошларга җимлекләр кую һ.б.) балаларның катнашуын мактау, хуплау. Үз гамәлләренең мәгънәсен һәм нәтиҗәләрен дөрес бәяли белү күнекмәләрен үстерү.

***Коммуникатив һәм социаль, шул исәптән мәгълүмати-социаль компетентлыкны үстерү өлкәсендә***

Баланың өлкәннәрне табигать һәм иҗтимагый тирәлек турында, дөнья күләмендәге, илдәге, республикадагы, туган шәһәрендәге (авылындагы) вакыйгалар турында төрледән-төрле мәгълүмат чыганагы буларак кабул итеп, алар белән аралашу ихтыяҗын хуплау.

Баланың туган (татар) телендә аралашу даирәсен киңәйтү, мәктәп укытучылары, сугыш ветераннары, кунаклар белән аралашу, аларны хөрмәт белән тыңлау һәм сөйләшү, әңгәмә темасына кушылу, үтенеч, тәкъдимгә җавап бирү, ярдәм сорау ысулларын формалаштыру.

Балаларны табигый тел мохитенә кертү, татар һәм рус телләрен белүне үз эченә алган аралашу сәләтләрен, эмоциональ яктан бай аралашуны үстерү, партнёрның социаль ролен исәпкә алу.

Сөйләм аша аралашу культурасын үзләштерү ситуацияләре булдыру, өлкәннәргә һәм яшьтәшләренә әдәпле мөрәҗәгать итәргә кирәклеге турында күзаллауларны формалаштыру, төрле сөйләм этикеты элементлары арасыннан билгеле бер ситуациягә туры килә торганнарын сайлап ала белү күнекмәләрен үстерү.

Ватанпәрвәрлек, үзен туган шәһәре (авылы), республика, иленең гражданы итеп тою хисләрен тәрбияләү, шәһәр, республика, ил символикасына (флаг, герб, гимн) хөрмәт белән карау.

Балаларны дөнья күләмендә билгеләп үтелә торган истәлекле даталарны бәйрәм итүгә җәлеп итү, уртак чарадан шатлык тою һәм канәгать калу хисләре формалаштыру.

Балалар бакчасында, өйдә, шәһәр урамында һәм юлларында, җәмәгать урыннарында, метрода үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен саклау күнекмәләрен ныгыту, әлеге кагыйдәләрнең башкалар тарафыннан үтәлүен таләп итү. Ашыгыч ярдәм чакыру номерын мөстәкыйль җыя белергә өйрәтү.

Туган якның тере һәм терек булмаган табигатенә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, кеше катнашуыннан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан ук күрә белергә өйрәтү, табигатьтән файдалануның беренчел күнекмәләрен формалаштыру. Табигать ресурсларына сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

***Уен эшчәнлеген үстерү өлкәсендә***

Янәшә яшәүче халыкларның тарихы һәм мәдәниятенә, шулай ук социумда кешеләрнең роле һәм үз-үзләрен тоту кагыйдәләренә бәйле сюжетларны киңәйтү вариантларын тәкъдим итү, балаларның мәнфәгатьләре һәм уен ихтыяҗларына карап эш итү.

Сюжетлы-рольле һәм режиссёрлык уеннарында үзешчәнлек характеры чагылышын һәм аларда чынбарлык, Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре, нәфис һәм мультипликацион фильмнары турындагы белемнәрне чагылдыру ихтыяҗын хуплау.

Сәхнәләштерү өчен Идел буе халыкларының әкиятләрен, шигырьләрен, җырларын, халык биюләрен мөстәкыйль сайлауны хуплау, балаларны булачак спектакль өчен кирәкле атрибутлар һәм декорацияләр әзерләүдә, рольләр һәм вазифалар бүлешүдә катнаштыру. Театрның төрле төрләрен (бибабо, бармак театры, курчак, рәсемнәр театры һ.б.) куллану. Сәхнә сәнгатенә кызыксыну уяту.

Ирекле вакытны культуралы уздыру формасы буларак, балаларның мөстәкыйль рәвештә күңел ачу уеннарын (интеллектуаль уеннар, уен-сәяхәтләр, күбрәк халык уенчыклары, курчак театры персонажлары, музыкаль уенчыклар кулланыла торган күңел ачу уеннары) оештырырга ярдәм итү, мөстәкыйльлек, инициатива күрсәтүләрен, тулы хокуклы партнёр позициясен ала белүләрен хуплау.

Бәйрәм-карнавал уеннарында, Нәүрүз, Карга боткасы, Сабан туе, Май чабу, Каравон кебек теге яки бу сезонга бәйле халык бәйрәмнәрендәге уеннарда балаларда иҗади сәләт чагылышын

хуплау. Бергә яшәүче халыкларның мәдәниятенә, традицияләренә һәм йолаларына хөрмәт тәрбияләү. Бәйрәм кәефен, уртак бәйрәмдә актив катнашудан шатлык хисләре тоюны үстерергә булышу.

Балаларны робот техникасы белән таныштыру. Балаларның LEGO Education WeDo, LEGO Sprike Prime, LEGO «Простые механизмы», LEGO Education «Планета STEAM», LEGO DUPLO конструкторлары ярдәмендә схема буенча предметлар җыю һәм аларны модельләштерү күнекмәләрен үстерү, шулай ук үзләре уйлап чыгарган әйберләрне җыюны хуплау. Балаларның конструкцияләренә механик элементлар кертергә, туклану элементларына тоташтырырга булышу, җыелган конструкцияләрне кулланып, уеннар оештыру.

Сүзле күмәк уеннар оештыруны хуплау.

Уен тәҗрибәсен Идел буе халыклары уеннары белән баету.

## • ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ

**Балаларның кызыксынучанлыгын, танып белү активлыгын, танып белү сәләтләрен үстерү, әйләнә-тирә чынбарлык турында белемнәрнең төрле өлкәләрендәге күзаллауларны үстерү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең танып белү өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Кызыксынучанлыкны, танып белү активлыгын, танып белү сәләтләрен үстерү өлкәсендә***

Балаларда Идел буе халыклары, аларның кәсепләре, милли киемнәре, ризыклары, йола-традицияләре, халык бәйрәмнәре турында кайбер күзаллауларны үстерү өчен шартлар тудыру. Бер төркемгә йөрүче балаларның төрле милләт һәм мәдәният вәкилләре була алуына, төрле телләрдә сөйләшә алуларына игътибарны юнәлтү. Әхлакый-этик, милли, хокукый культурада кабул ителгән үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтү. Балаларны сорау бирергә, үз мәдәнияте белән чагыштырырга өйрәтү, аларны гадәти булмаган мәгълүмат белән гаҗәпләндерү. Милләт-ара аралашу культурасын үстерү.

Дәүләт тыюлыклары, анда яшәүчеләр, ТР Кызыл китабына кертелгән флора һәм фауна вәкилләре белән таныштыру. Кызыксынучанлыкны үстерү, балаларның аңына хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының сирәк вәкилләренә карата сакчыл мөнәсәбәттә булырга кирәклекне сеңдерү.

Татарстан елга һәм күлләрендә яшәүчеләр белән таныштыру. Елга-чишмәләрнең кеше тормышындагы әһәмияте турында сөйләү. Республика су ресурсларын чисталыкта тотарга теләк уяту.

Балаларның табигатьне саклау эшчәнлеге турындагы белемнәрен арттыру. Туган якның тере һәм терек булмаган табигатенә сакчыл караш тәрбияләү, кешенең табигатькә йогынтысының уңай һәм тискәре нәтиҗәләрен алдан күрә белергә өйрәтү, табигый ресурсларны саклау, табигатьтән рациональ файдалану күнекмәләрен формалаштыру. Җиләк һәм үсемлекләр җыю кагыйдәләре турында сөйләү.

Туган як табигатенең матурлыгына, форма, төс һәм исләр байлыгына игътибарны юнәлтү. Ватанпәрвәрлек нигезе – кече ватан табигатенә мәхәббәт тәрбияләү.

***Әйләнә-тирә чынбарлык турында белемнәрнең төрле өлкәләрендәге күзаллауларны үстерү өлкәсендә***

Балаларга Россиянең, Мәскәү, Санкт-Петербург, Казанның кайда урнашканлыгын, безнең илнең кайсы илләр белән чиктәш булуын глобуста күрсәтү. Аңлаешлы формада Россия тарихындагы кайбер вакыйгалар, дәүләт төзелеше, армия, авиация, флот, күренекле кешеләр, сәясәтчеләр һәм җәмәгать эшлеклеләренең хезмәте турында сөйләү.

Россиянең дәүләт символикасы (флаг, герб, гимн) белән таныштыру. Балаларга гимнны өйрәнергә булышу, Россия символикасына ихтирамлы караш тәрбияләү.

Республиканың элекке һәм бүгенге торышы, аның географик урыны, табигате, климаты, халкының эшчәнлеге белән таныштыруны дәвам итү. Туган якны өйрәнү эшчәнлеген үстерү, әйләнә-тирә чынбарлыкның төрле өлкәләренә караган белемнәрне баету.

Казанның зур сәнәгать һәм сәүдә үзәге булуы, ә татар халкының борын-борыннан иген-челек, терлекчелек, күн җитештерү, сәүдә һ.б. белән шөгыльләнүе турында сөйләү. Балаларның дөрес мәгълүмат алуы өчен шартлар тудыру, Казан тарихына карата кызыксыну уяту.

STEAM-белем бирүнең яңа мөмкинлекләрен кулланып, туган шәһәребездә барган уңай үзгәрешләрне (Түбән Кабан күле яр буен төзекләндерү, сәүдә-күңел ачу үзәкләренең, яңа метро станцияләренең ачылуы һ.б.) күрергә, аның киләчәген проектлаштырырга өйрәтү.

Балаларны карта белән таныштыру, картада төбәкнең зур шәһәрләрен (Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Яр Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзән, Чистай һ.б.) табу, андагы истәлекле урыннар, җитештерелә торган продукция, сәнәгать предприятиеләре белән таныштыру. Төбәк шәһәр-ләренең символикасын өйрәнүне дәвам итү.

Борынгы шәһәрләр (Биләр, Болгар, Зөя) тормышы, аларның тарихы, мәдәнияте, көнкүреше белән таныштыру. Авыл һәм шәһәр көнкүрешен чагыштырырга булышу, кием, торак, йорт кирәк-яракларының үзенчәлекләренә игътибарларын юнәлтү.

Милли һәм дөнья мәдәниятенең узганы һәм бүгенгесе белән таныштыру. Музыка һәм театр сәнгатенең күренекле эшлеклеләренең тормышы һәм иҗаты белән таныштыру: композиторлар (С. Садыйкова, С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин һ.б.), җырчылар (Ф. Шаляпин, Р. Ибраһимов һ.б.), театр режиссёрлары (К. Тинчурин, М. Сәлимҗанов һ.б.), театр актёрлары (В. Качалов, Г. Камал һ.б.). Кызыксынучанлыкны канәгатьләндерү, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренең иҗаты турында мәгълүмат эзләргә булышу.

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры сәхнәсендә ел саен оештырыла торган Ф.И. Шаляпин исемендәге Халыкара опера фестивале һәм Р. Нуриев исемендәге Халыкара классик балет фестивале турында сөйләү. Балаларны югары дәрәҗәдәге дөнья мәдәниятенә җәлеп итү.

Балаларга күренекле фән эшлеклеләренең (Н.И. Лобачевский, К.Ф. Фукс, А.М. Бутлеров, А.Е. Арбузов һ.б.) эшчәнлеге һәм тормышы турында сөйләү. Фәнгә кызыксыну уяту.

Бөек Ватан сугышы милли геройларының (М. Җәлил, Г. Гафиятуллин, М.П. Девятаев, П.М. Гаврилов, Н.Г. Столяров һ.б.) батырлыклары турында сөйләү. Ата-аналарны балаларына әби-бабаларының сугыш елларында алган хәрби бүләкләре турында сөйләргә җәлеп итү. Ватанны саклаучыларга хөрмәт тәрбияләү (һәйкәл, обелискларга чәчәкләр кую һ.б.).

Үз микрорайонында куркынычсыз юлларның гади план-схемасын («Балалар бакчасыннан иң якын тукталышка юлны тап», «Өйдән мәктәпкәчә булган юлны күрсәт», «Вакыйга булган урынны тап» һ.б.) куллана белү күнекмәләрен үстерү. Балаларның карта, схема, маршрут, расписание, үзләре белмәгән юл тамгалары буенча сорау бирүләрен хуплау.

Татар халык әкиятләре аша («Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс», «Васыять», «Алтын бөртекләр» һ.б.) хезмәт эшчәнлеге турындагы күзаллауларны үстерү. Кайбер заманча һөнәр-ләр (космик туризм өлкәсендә гид, медицина робот техникасы буенча белгеч, биоинформатик, техник язучы һ.б.) турында күзаллаулар формалаштыру, яхшы белгеч булу теләге тәрбияләү.

Автобан, юл, тимер юл төзелеше, махсус билгеләнештәге техник машиналар, төзүчеләрнең һөнәри эшчәнлеге белән таныштыру. Балаларның игътибарын тормышта бара торган уңай үзгәрешләргә җәлеп итү, бу үзгәрешләрнең хәрәкәт итү куркынычсызлыгына йогынтысын (хәрәкәт иминлеге юллар сыйфатына бәйле) аңлату.

Юлларда хәрәкәтнең көчәюе шартларында балаларны шәхси иминлекне тәэмин итү (үз-үзеңне саклау) процессына тарту. «Сакла» интернет-порталы материалларын куллану.

## • СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ

**Сөйләм һәм тел культурасының нигезләрен формалаштыру, баланың сөйләм теленең төрле якларын камилләштерү, аны матур әдәбият уку культурасына тарту өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең сөйләм үсеше өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Баланың сөйләм теленең төрле якларын камилләштерү өлкәсендә***

Аралашу һәм милли мәдәният чарасы, үз фикерләрен, хис һәм теләкләрен чагылдыру чарасы буларак, туган (татар) телне үстерү өчен шартлар тудыруны дәвам итү. Уңышка ирешү ситуациясен булдыру.

Балаларны тел мохитенә кертү, чынбарлык шартларында әңгәмәдәшенең туган (татар) телендә сөйләмен тыңлау, диалогка кушылу, татар телен чикле белгән очракта да коммуникатив максатка ирешергә мөмкинлек бирү. Белемнәрне реаль тел мохитендә куллануны хуплау.

Балаларга җырлар тыңлау, җырлау, әйлән-бәйлән уйнау, «Татармультфильм» берләшмәсе мультфильмнары җыентыгын, «Шаян ТВ» телеканалы тапшыруларын карау, танып белүдән һәм иҗади активлыктан канәгатьлек алырга мөмкинлек бирү. Тел культурасы, аралашу һәм эшчәнлек культурасы нигезләрен салу.

Белем бирүнең заманча методларын (авазлар ассоциациясе методы, тулы физик реакция методы, Сингапур методы), STEAM-белем бирү, проектлаштыру технологияләрен, үстерешле укыту, уен һәм мәгълүмат-коммуникация технологияләрен, аудиоязма, анимацияле сюжетлар, мультипликацион һәм видеопродукция, режиссёрлык һәм дидактик уеннарны куллану аша, баланың индивидуаль сөйләм үсеше траекториясен исәпкә алып, актив сүз байлыгын арттыру. Грамматик яктан дөрес сөйләмгә омтылышны хуплау.

Балалар белән рус теленнән татар теленә тәрҗемә күнегүләре ясау, актив сөйләм практикасын тәэмин итү.

Исемгә карата сыйфат сайлау, охшаш һәм капма-каршы мәгънәле сүзләр табу кебек күнегүләр эшләү. Образлы сүзләр, чагыштырулар, гомумиләштерә торган төшенчәләрне активлаштыру. Туган телдәге сүз байлыгының сан һәм сыйфат ягыннан үсешен тәэмин итү.

ТРИЗ (уйлап табу мәсьәләләрен чишү теориясе) технологиясенә таянып, табышмаклар, әкиятләр иҗат итү, бер генә герое булган ситуацияле рәсемнәр сериясе, сюжетлы картинкалар, репродукцияләр, шәхси күзәтүләр буенча үзе турында кечкенә генә (3–8 җөмлә) хикәя төзи белү күнекмәләрен үстерү. Телдән сөйләү осталыгына ирешү.

Балаларның әдәби мирас белән кызыксынуларын хуплау, аларны татар язучыларының әдәби әсәрләрен озак итеп тыңларга (кабул итәргә), аерым өзекләрне сөйләргә яисә аларның гомуми мәгънәсен аңлатырга өйрәтү, сәнгатьле сөйләүдә, сәхнәләштерүдә катнаштыру.

Татар рәссамнары (Р.Ф. Хуҗин, Р.Ш. Якупов, Б.И. Урманче, А.И. Гайфуллин һ.б.) картиналарын караганда баланың үзен кызыксындырган күренешләргә карата сорау бирә алуын хуплау, зур булмаган монолог формасында җөмләләр төзү һәм фикер белдерүне активлаштыру.

«Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып» (1 нче һәм 2 нче кисәк, 2023) эш дәфтәрен кулланып, балаларны язу нигезләрен үзләштерүгә әзерләү. Балаларны сүзгә аваз анализы ясарга, сузык һәм тартык авазларны аерырга, сүзнең аваз структурасында ориентлашырга, тәкъдим ителгән модельләргә сүзләр сайларга, хәрефләр танырга өйрәтү. Балаларда уку теләге уяту, ачык иҗекләр, кыска сүзләр укырга өйрәтү, мавыгып уку күнекмәсе тәрбияләү.

Балаларга Халыкара туган тел көнендә, шигырь конкурсларында, әдәби кичәләрдә шигырьләр сөйләү мөмкинлеге бирү. Сәнгатьле сөйләм телен формалаштыру. Үз чыгышыңнан канәгатьлек алырга өйрәтү.

Бала өчен яңа коммуникатив ситуациядә татар телендә аралашу күнекмәләренең тотрыклылыгына мониторинг үткәрү.

Баланы башлангыч мәктәптә татар телен тагын да тирәнрәк өйрәнүгә әзерләү.

«Изучаем русский язык» укыту-методик комплексында каралган лексик күләмнең (600 сүздән дә ким түгел) тулысынча үзләштерелүен тәэмин итү, сөйләмне мәгънәле эчтәлек белән баету. Максатчан өйрәтү процессында төрле фраза конструкцияләрендә яңа сүзләрнең кулланышын активлаштыру. Рус телен өйрәнүгә тотрыклы кызыксыну уяту.

Балаларны аерым сөйләм гамәлләренә генә түгел, аралашу ситуациясендә ориентлашырга һәм, тиешле сүзләр һәм грамматик чаралар кулланып, яңа шартларда сөйләмнең дөрес формасын мөстәкыйль табарга өйрәтү.

Җөмләдә сүзләрне бәйләү өчен кушымчалар системасын дөрес кулланырга өйрәтү. Үзенчәлекле эшчәнлек төрләрендә, табигый аралашу ситуацияләрендә балаларның рус фольклорын, киң кулланыштагы сүзләрне һәм гыйбарәләрне кулланырга тырышуын хуплау. Сөйләмдә фикерне төгәл чагылдыра, сөйләмне контрольдә тота белергә өйрәтү.

Эчтәлекле һәм конструктив бәйләнешне исәпкә алып, фикер-репликалар белән аралашырга булышу. Диалог кысаларында үз сөйләмен планлаштыра һәм башкалар сөйләмен фаразлый белү сәләтен үстерү. Диалогтан киң монологик сөйләм формаларына күчәргә өйрәтү.

Мәктәпкәчә белем бирүне тәмамлау этабында балаларны башлангыч мәктәптә рус телен тагын да тирәнрәк өйрәнүгә әзерләү.

***Матур әдәбият уку культурасына тарту өчен шартлар тудыру өлкәсендә***

Сәнгати, танып белү, энциклопедик характердагы басмалар ярдәмендә балаларның уку даирәсен киңәйтү. Китапны язучы (шагыйрь), рәссам һәм типография хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак тәкъдим итеп, балаларның бу өлкәдә белемен тирәнәйтү.

Шигырь, хикәя, әкиятләрнең аерым үзенчәлекләре белән таныштыру. Әсәрнең эчтәлеген аңларга, әдәби геройларның эш-гамәлләрен дөрес бәяләргә, вакыйгаларның үз версиясен уйлап табарга омтылуларны хуплау. «Бала» интерактив тавышлы мультимедиа китапханәсе материалларын куллану.

Зур күләмдәге (дәвамлы уку) әсәрләрне уку тәкъдименә уңай караш тәрбияләү. Балалар матур әдәбиятына көн саен мөрәҗәгать итү ихтыяҗын формалаштыру.

Катнаш бәйләнешле сөйләм (тасвирлау һәм хикәяләү монологларының катнашуы, диалоглар кушу) төзү, үз фикерләренең планын төзергә һәм шуның буенча сөйләргә өйрәтү. Кайбер проза текстларының эчтәлеген эмоциональ итеп җиткерү, кыска шигырьләрне сәнгатьле сөйләү, татар әкиятләрен сәхнәләштерүдә катнашу тәҗрибәсе өчен шартлар тудыру.

Идел буе халыкларының әкиятләреннән файдаланып, нигезендә әдәби образларны интерпретацияләү яткан күзаллау формаларын үстерү.

Татар халык авыз иҗатына карата кызыксынуны үстерү. Стиль һәм жанрларның төп үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, әдәби иҗат тәҗрибәсен үстереп, балаларны сүз сәнгатенә җәлеп итү.

Татар халык мәзәкләре («Ике ялкау», «Энә җавабы» һ.б.) белән таныштыру. Юмор хисен үстерү.

Әти-әниләргә бала өчен уку почмагы оештырырга ярдәм итү, китап күргәзмәләренә, ярминкәләренә барырга, яшь тамашачылар өчен Г. Камал исемендәге ТДАТ сәхнәләштергән спектакльләрне карарга тәкъдим итү.

## ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ӘСӘРЛӘР

**Балаларга уку өчен**

***Җырлар, такмаклар, әйтешүләр, тел көрмәкләндергечләр, санамышлар, алдавыч әкиятләр:*** «Роза гөлләре матур»; «Наза»; «Кәҗә-кәҗә, Мәкәрҗә...»; «Сип-сип суганга...»; «Сания апа суга бара...»; «Их, төймә, төймә, төймә...»; «Бер аланда чәчәкләр күп...»; «Карга әйтә: карр, карр...»; «Күпер башында күп күркә...»; «Ваттым мичкә, яктым мичкә...»; «Әти китте базарга...»; «Әлчи-бәлчи...»; «Әүвәл заманда булган бер зур тау...»; «Борын-борын заманда...».

***Әкиятләр, легендалар:*** «Ай белән Кояш», «Кола ат», «Алтын бөртекләр», «Үрдәк беренчелекне алган», «Бүләк кемгә?», «Акыллы килен», «Ялкау малай», татар халык әкиятләре; «Ни өчен бакалар бакылдык булып калганнар?», «Зөһрә йолдыз», «Ни өчен Чәберчек килмичә боз китми икән?», легендалар; «Казлар-аккошлар», «Эт үзенә ничек дус тапкан», рус халык әкиятләре.

***Дөнья халыклары әкиятләре:*** «Аю койрыгы», Индонезия халыклары әкияте; «Икмәк», төрекмән халык әкияте; «Пингвин баласы», инглиз халык әкияте; «Тычкан белән Чыпчык», удмурт халык әкияте; «Төлке белән Аю», мари халык әкияте, русчадан Р. Вәлиев тәрҗемәләре; «Куянның ирене нигә ерык?», эстон халык әкияте; «Сандугач», украин халык әкияте; «Хәйләкәр әкәм-төкәм», бирма халык әкияте; «Тату туганнар», корея халык әкияте; «Гадел Куян», тува халык әкияте; «Әтәч белән Төлке», каракалпак халык әкияте.

***Шигырьләр:*** М. Җәлил. «Көз җитте»; Г. Тукай. «Чыршы», «Бәйрәм бүген»; Л. Шәех. «Сөмбелә»; Р. Сәлах. «Куян килгән»; Р. Вәлиева. «Ашлар солтаны», «Энҗе-мәрҗән калфагым»; Н. Думави. «Беренче кар»; Җ. Дәрзаман. «Җепшек көндә»; Л. Шагыйрьҗан. «Сөембикә манарасы»; Р. Миңнуллин. «Светофор», «Сабантуй бүген бездә»; Ш. Җиһангирова. «Кайгырту»; Р. Корбан. «Җәлил турында җыр»; Я. Игәнәй. «Әти кайтыр эштән»; М. Гафури. «Татар теле», «Китап һәм балалар»; Р. Бәшәр. «Бүген», «Сандугачлы ак инеш», «Мин бит татар егете»; Ф. Яруллин. «Әниләр бәйрәмендә», «Татарстан байрагы»; М. Әгъләмов. «Тукай көне»; Р. Хафизова. «Нәүрүз килә»; Йолдыз. «Рамазан аенда», «Карга боткасы»; Э. Мөэминова. «Моңсу бәйрәм»; Р. Фәйзуллин. «Кызыл китап»; Р. Арсланова. «Әби сандыгы»; Л. Лерон. «Бу кайвакыт? Әйт, балам»; С. Рәхмәтулла. «Укырга өйрәнәбез»; А. Барто. «Катя», М. Хөсәен тәрҗ.; «Кабырчык», Г. Латыйп тәрҗ.; Б. Рәхмәт. «Мәктәпкә!»; Ә. Бикчәнтәева. «Әлифбам».

***Төрле ил шагыйрьләре әсәрләре:*** Ю. Некрошюс. «Карга бичара», литвачадан, русчадан Р. Миңнуллин тәрҗ.; Р. Сәрби. «Мин җырларга яратам», чувашчадан, русчадан Р. Миңнуллин тәрҗ.; Г. Виеру. «Әйтче, Кояш!», молдаванчадан, русчадан Р. Миңнуллин тәрҗ.; В. Романов. «Дуслашасым килә», удмуртчадан, русчадан Р. Миңнуллин тәрҗ.

***Рольләргә бүлеп сөйләү өчен:*** К. Тәхау. «Казлар, казлар...», «Карак песи»; Р. Миңнуллин. «Малайлар сөйләшә»; Ф. Яруллин. «Әнкәсе белән улы»; М. Галиев. «Мәче нигә мыеклы?»; А. Нигъмәтуллин. «Песи һәм Чыпчык».

**Яттан өйрәнү өчен**

*Татар халык авыз иҗаты:* «Юл читендә зәңгәр чәчәк», «Каенда – карга...», «Нардуган, Нардуган...», «Арыш, бодай игәбез...».

*Шигырьләр:* Г. Тукай. «Туган тел»; Н. Гайсин. «Уңыш җыелды»; Г. Зәйнашева. «Бер атнада ничә көн?»; Г. Латыйп. «Кыш килде»; Э. Мөэминова. «Туган телем»; Х. Туфан. «Казан»; М. Мазунов. «Яз килә»; Җ. Тәрҗеманов. «Иң матур җыр»; Р. Рәкыйпов. «Мин яратам сине, Татарстан!»; Ә. Бикчәнтәева. «Хуш, сөекле бакчабыз»; Р. Вәлиева. «Туган җир».

**Әдәби әкиятләр һәм хикәяләр:** Г. Тукай. «Шүрәле» (өзек), «Су анасы», «Ташбака белән Куян» (мәсәл); А. Алиш. «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар»; С. Гыйльметдинова. «Тузганак», «Шаян кырмыска»; Ә. Гаффар. «Кыңгырау чәчәкләр»; А. Хәсән. «Кыш бабай бүләк өләшә»; Батулла. «Чыбык ашату»; Н. Исәнбәт. «Һәркемнең үз эше»; И. Нәбиуллина. «Тел белүнең хикмәте»; С. Гаффарова. «Гөлгүзәл»; С. Әдһәмова. «Дуслар»; Ф. Зариф. «Чишмә»; В. Даль. «Кар кызы», Т. Шакирова тәрҗ.; К. Ушинский. «Җил белән Кояш», Т. Шакирова тәрҗ., «Шаян кырмыска»; «Сабыр итә бел», Ш. Шириязданов тәрҗ.; В. Сутеев. «Гөмбә астында», Г. Хәйдәрова тәрҗ.; В. Осеева. «Кем хуҗа?», Ф. Гайнанова тәрҗ., «Тылсымлы сүз», А. Лотфуллина тәрҗ.; Р. Фәхретдин. «Тәрбияле бала» (өзекләр); Дәрдемәнд. «Гали»; Н. Каштан. «Хәрәмләшү», «Солтания белән күбәләк»; З. Хөснияр. «Әниемнең көләч йөзе»; Р. Хафизова. «Песнәк»; Р. Вәлиева. «Туган көндә», «Ак песи»; Х. Халиков. «Витаминлы аш»; Ф. Яруллин. «Кояштагы тап»; М. Пришвин. «Туган илем», Х. Фәйзрахманова тәрҗ.; Н. Носов. «Җанлы эшләпә», Т. Шакирова тәрҗ.

**Өстәмә әдәбият**

*Татар халык авыз иҗаты:* «Әйләнәбез Нардуган...»; «Казандагы суны...»; «Чәйнеккә акча салдым...»; «Җепсез орчык...»; «Үрмәкүч, күч...»; «Саескан, саескан...»; «Нәүрүз әйттек без сезгә...»; «Исәнлеккә-саулыкка...»; «Тфү-тфү дияем...».

*Шигырьләр:* Р. Арсланова. «Мең сорау»; Б. Рәхмәт. «Кыш килде»; Йолдыз. «Бабам кебек»; Г. Тукай. «Ак бабай», «Кызыклы шәкерт»; Р. Шәйдуллина. «Икмәк ява»; Р. Корбан. «Кояш – безнең дустыбыз»; Л. Шагыйрьҗан. «Курчак театрында»; Л. Лерон. «Татар баласы»; Э. Шәрифуллина. «Сабантуй»; Ә. Кари. «Тәүлек»; Р. Фәйзуллин. «Кәгазь»; Л. Әмирханова. «Чигүле читекләрем»; Л. Газизова. «Файдалы дару», Л. Лерон тәрҗ.

*Әдәби әкиятләр һәм хикәяләр:* Г. Сабитов. «Кадерле бүләк»; И. Иксанова. «Сәгать дигән серле ил»; А. Имамиева. «Умырзая»; Ф. Яруллин. «Хәтерсез күке»; Р. Төхфәтуллин. «Шомырт нигә елый?»; Бертуган Гриммнар. «Боткалы чүлмәк», С. Әдһәмова тәрҗ.; Н. Носов. «Тауда», Т. Шакирова тәрҗ.

## • СӘНГАТИ-ЭСТЕТИК ҮСЕШ

**Балаларда чынбарлыкның эстетик ягына кызыксынуны арттыру, сәнгатьнең төрле төрләре һәм жанрлары (сүз, музыка, сынлы сәнгать), шул исәптән халык иҗаты белән таныштыру, сәнгати-эстетик чынбарлыкның төрле төрләренә тарту, иҗади сәләтләрне ачу, сәнгати идеяләрне тормышка ашыруда инициатива һәм мөстәкыйльлекне арттыру ихтыяҗын үстерү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең сәнгати-эстетик үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Балаларда чынбарлыкның эстетик ягына кызыксынуны арттыру, сәнгатьнең төрле төрләре һәм жанрлары, шул исәптән халык иҗаты белән таныштыру өлкәсендә***

Балаларны Г. Тукай әсәрләре, аның иҗаты чагылыш тапкан сәнгать төрләре (Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты, Ә. Бакировның «Су анасы», Н. Җиһановның «Кырлай» симфониясе) белән таныштыруны дәвам итү. Сәнгатьне кыйммәти-мәгънәви яктан аңлауның алшартларын формалаштыру.

Г. Тукай образын һәм аның «Апуш», «Кырлай», «И туган тел», «Бишек җыры», «Истәлекләр. Ташаяк ярминкәсе» һәм башка бик күп әсәрләренең геройларын сында чагылдырган республиканың беренче хатын-кыз скульпторы Рада Нигъмәтуллина иҗаты белән таныштыру. Балаларга сәнгать әсәрләренең эчтәлеген аңларга булышу.

Сынлы сәнгать әсәрләрен балаларның тулысынча аңлап кабул итүе өчен шартлар тудыру. Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музеендагы сынлы сәнгать әсәрләре («Мөнирә

Булатова портреты», Б.И. Урманче; «Акбай», Р.Х. Газиев; «Ишегалды», Р.Ш. Якупов; «Самавырлы натюрморт», С.В. Неустроев һ.б.) белән таныштыру. Сәнгать әсәрләренә мөстәкыйль бәя бирүне хуплау.

Балаларны борынгы сәнгать төрләренең берсе – металлны нәфис эшкәртү белән таныштыру. Татарстан Республикасы Милли музеена сәфәр оештыру, анда саклана торган йорт кирәк-яраклары белән таныштыру: көмеш поднослар, савыт-саба, бакыр чүлмәкләр, комганнар, йорт хайваннары сыннары формасындагы бронза йозаклар, җәмәгать биналарының эчке һәм тышкы якларын бизәп торган декоратив композицияләр. Мәдәни кыйммәтләргә сак карарга өйрәтү һәм музейда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен аңлату.

Балалар белән бергә борынгы бизәнү әйберләрен карау: йөзекләр, алкалар, беләзекләр, чулпылар, яка чылбырлары, хәситәләр һ.б. Хәзерге заман рәссам-ювелирлары (И.Ф. Фазылҗанов, С.В. Ковалевская, В.О. Ковалевский һ.б.) иҗаты белән таныштыру. Бизәнү әйберләренең милли үзенчәлегенә игътибар итү.

Татар халкының мөстәкыйль сәнгать кәсебе – укалап чигү турында сөйләү. Балалар белән бергәләп чигүле түбәтәй, хатын-кызларның бәрхет аяк киемен, янчык, калфак һ.б.ны карау. Чәчәк бәйләме, кош, бодай башагы, йолдыз, ярымай мотивлары, «алтын каурый» һ.б. кебек иң популяр композицияләргә игътибар итү. Сәнгать предметларына карата кызыксынуны үстерү.

Баланың кызыксынуларыннан чыгып, кул хезмәтенең кайбер төрләренә өйрәтү. Чигүнең төрле төрләрен (тамбурлы җөй, сәйлән белән чигү) күрсәтү, балаларга якыннары өчен милли бизәкле бүләк әзерләргә булышу.

Балаларны туган шәһәрләренең (авылларының) архитектурасы белән таныштыруны дәвам итү: җәмигъ мәчетләре, храмнар архитектурасы (Кол Шәриф мәчете, Раифа Богородица ирләр монастыре). Аларга хас үзенчәлекләрне, конструкцияләренең, бизәлеш детальләренең төрлелеген күрә белү сәләтен үстерү.

Китап иллюстрацияләре турындагы белемнәрне тирәнәйтү. Балалар әдәбиятында Шүрәле образын тудырган рәссамнарның (Ф. Әминов, Б. Әлминов, В. Булатов, Ю. Вәлиәхмәтов, А. Тимергалина, Б. Урманче, Н. Хаҗиәхмәтов, Р. Шәмсетдинов һ.б.) иҗаты белән таныштыру. Рәссамнарның әлеге әкият персонажына карата үз мөнәсәбәтләрен чыгылдыруларына игътибар итү. Китап иллюстрацияләрен карарга кызыксыну, сораулар бирергә теләк уяту.

***Сәнгати-эстетик чынбарлыкның төрле төрләренә тарту, иҗади сәләтләрне ачу, сәнгати идеяләрне тормышка ашыруда инициатива һәм мөстәкыйльлекне арттыру ихтыяҗын үстерү өлкәсендә***

**Сынлы сәнгать эшчәнлеге**

*Рәсем ясау*

Милли орнамент элементлары белән танышуны дәвам итү. Балалар белән бергә «тормыш агачы» образын карау. Композициянең асимметрик характерда булуына, бер үк вакытта төрле төстәге мотивларны куллану мөмкин булган чәчәк бәйләменә игътибар итү.

Декоратив рәсем ясау техникасын камилләштерү: чәчәк бөреләре, чәчәкләр, җимешләр, яфраклар, бөтеркәләр белән мул бизәлгән сабаклы ботактан гыйбарәт булган асимметрияле букет ясау ысулларын күрсәтү. Бизәкне планлаштыру ысуллары (якынча эскиз, каралама, композицион схема) белән таныштыру. Сурәтләү ысулларын эзләүне хуплау (пумаласыз ясау ысулын да кертеп). Композицияне тоемлау хисен үстерү.

Предметларның формасына, аның билгеләнешенә, материалына бәйле рәвештә декоратив тукыма, баш киемнәре, аяк киеме, сөлгеләр өчен бизәкләр уйлап табуларны хуплау.

Таныш техникаларны берләштерү һәм яңасын үзләштерү өчен шартлар тудыру. Чынбарлыктагы һәм әкияти образларны (Идел буе халыкларының әкиятләре геройларын кертеп)

сурәтләүнең төрле ысулларын берләштерү һәм төрле материаллар куллану мөмкинлеге бирү, композицияләрнең оригинальлеген хуплау.

Милли колорит элементлары булган сюжетлы, декоратив композицияләрне күмәкләшеп ясауны оештыру. Балаларның иҗади ниятләрен, инициативасын, мөстәкыйльлеген, җаваплылыгын хуплау.

Республиканың иҗтимагый тормышындагы иң истәлекле вакыйгаларны рәсемдә сурәтли белүләрен хуплау. Балалар белән бергә эшләрне карау, ясалган рәсем турында сөйләргә теләк уяту. Балалар эшләренең тематикасын киңәйтү.

*Әвәләп ясау*

Алынган тәэсирләрне сәнгати әвәләү эшендә чагылдыру өчен шартлар тудыру. Стека ярдәмендә савыт-сабаның (комган, чүлмәк, ваза һ.б.) характерлы сыйфатларын чагылдыру өчен, өлешләрне тарту-сузу һәм модельләштерү ярдәмендә тасма ысулы белән әвәләү күнекмәләрен камилләштерү. Төрле сыгылмалы материаллар: балчык, тозлы камыр, пластилин һәм башкалардан предметлар әвәләү күнекмәсен ныгыту.

Рельефлы сурәтләү техникасын камилләштерү. Натурага хас үзенчәлекләрне исәпкә алып, пропорцияләрне дөрес туры китереп, тукранбаш яфрагын әвәләп ясау күнекмәсен үстерү. Әвәләп ясаганда балаларның игътибарын плинтус – нигездән башларга кирәклегенә җәлеп итү, нигез өслегенә стека очы белән рельефның контурлы рәсемен төшерү.

Актүбә һәм Шәмәрдән уенчыкларын натурадан карап әвәли, аларның характерлы үзенчәлекләрен бирә белергә өйрәтү. Халык иҗатын үстерергә булышу.

Катлаулы булмаган сюжетка берләштерелгән ике-өч фигуралы скульптура төркемен сурәтләү тәҗрибәсен баету: «Сабан туенда», «Чәй эчү», «Ат чабышлары» һ.б. Сюжетның идеясен мөстәкыйль рәвештә билгеләү, хәрәкәт һәм торышларны дөрес чагылдыру омтылышын хуплау.

Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре геройларын күзаллау юлы белән әвәләп ясый белү күнекмәләрен үстерү. Иҗади сәләт һәм инициативаларын үстерү.

*Аппликация*

Балаларның аппликация сәнгатенә карата кызыксынуларын үстерү, кисеп ябыштыру эшчәнлегенең эчтәлеген катлауландыра барып, сюжетлы сурәтләр барлыкка китерүне дәвам итү.

Симметрияле, силуэтлы, күпкатламлы, челтәрләп кисү техникаларын, детальләрне фонга беркетүнең төрле юлларын, кәгазьне ертып-ертып, өсте-өстенә ябыштыру техникаларын куллануны хуплау.

Орнаментлы аппликацияләрне (панно, фризлар, коллажлар) коллектив белән төзергә, сәнгатьле образ тудыру өчен күптөрле материаллар кулланырга өйрәтү.

Дәлия, чалмабаш, кашкарый чәчәкләреннән композицияләр төзү өчен, күләмле аппликация ясау ысулларын камилләштерү. Сурәтне баета торган детальләр (кошлар, бал кортлары, күбәләкләр, энә карагы һ.б.) белән композицияләрне тулыландыру омтылышын хуплау.

Туган шәһәрдәге (авылдагы) иҗтимагый тормышны чагылдыра торган сюжетларны мөстәкыйль сайлый белүләрен активлаштыру. Башка белем бирү өлкәләре эчтәлегенә яраклаштырып, балалар эшләренең тематикасын киңәйтергә булышу.

**Музыкаль эшчәнлек**

Балаларны татар халкының музыкаль мәдәниятенә җәлеп итү. Вокаль, инструменталь, оркестр өчен язылган музыканың иң яхшы үрнәкләре белән таныштыру. Музыканың характерын, кәефен билгели, аның турында әңгәмә алып бара белү күнекмәләрен камилләштерү.

С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин, Р. Яхин, Н. Җиһанов һ.б. язган музыка әсәрләрен тыңларга өйрәтү. Татар композиторларының кайбер музыкаль әсәрләренең жанрын билгеләү, таныш музыка уен коралларының яңгырашыннан тану күнекмәләрен ныгыту.

Балаларны Россия Федерациясе Дәүләт гимны көе белән таныштыру. Ватанпәрвәрлек хисен тәрбияләү.

Милли репертуар нигезендә балаларның җырлау күнекмәләрен формалаштыру буенча эшне дәвам итү, интонация чисталыгына, сүзләрнең дөрес әйтелешенә, сәнгатьле итеп җырлауга ирешү.

Төп бию хәрәкәтләре күләмнәрен арттыру: «сыгылмалы йөреш», «беренче йөреш», «Әпипә», «сикерүле чылбыр», «борма», «бишек», «аяк очы – үкчә», «үкчә – аяк очы», «тыпырдау», «вак тыпырдау», «төп йөреш», «үкчәдә йөреш», «гади адым», «бөтерчек», «өчле тыпырдау», «парлап әйләнү» һ.б. Татар биюен башкару техникасын камилләштерү.

Идел буе халыкларының биюләрен башкару тәҗрибәсе алу өчен шартлар тудыру, бию вакытында эмоциональ аралашуны үстерү.

Театрның төрләре, актёр, режиссёр, декоратор, гримёр эше турында сөйләү. Сюжетлы этюдларда музыкаль хәрәкәт импровизациясен үстерү, киңәйтелгән композицияләр уйлап табарга булышу, музыкаль-иҗади эшчәнлектә актив мөстәкыйль хәрәкәтләр ясарга этәрү.

## МУЗЫКА ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ЯКЫНЧА ИСЕМЛЕГЕ

**Музыка тыңлау**

«Туган ил», М. Мозаффаров муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Бәйрәмдә», Р. Яхин муз.; «Иртәнге нур», С. Садыйкова муз., З. Вәли сүз.; «Вальс», Н. Җиһанов муз. («Балалар өчен пьесалар» альбомы); «Көз», «Кыш», «Яз», «Җәй», Р. Яхин муз. («Табигать күренешләре» циклы); «Полька», И. Якубов муз.; «Каршылау маршы», «Совет Армиясе маршы», С. Сәйдәшев муз.; «Бишек җыры», А. Ключарёв муз.; «Кар атыш», Э. Низамов муз.; «Әниләргә сөю бүләк итик», Ә. Һадиева муз., Э. Әхмәтҗанова сүз.; «Моңсу», «Кайгы», Н. Җиһанов муз. («Балалар өчен пьесалар» альбомы); «Песи җыры», «Марш», Л. Хәйретдинова муз. («Мәкерле песи» операсы); «Күршеләр», Р. Зарипов муз.; «Сөйләшү», Ф. Шәймәрданова муз.; «Әдрән диңгез», С. Сәйдәшев муз., Т. Гыйззәт сүз.; «Авыл көе», татар халык җыры, А. Вәлиуллин эшкәрт.; «Вальс-экспромт», «Мәзәк бию», Р. Яхин муз.; «Балалар биюе», «Кызлар биюе», Ф. Яруллин муз. («Шүрәле» балеты); «Шүрәле темасы», «Былтыр темасы», Н. Җиһанов муз. («Кырлай» симфоник поэмасы); «Тукай маршы», З. Яруллин муз.; «Әллүки», татар халык көе, Г. Тукай сүз., Р. Еникиева эшкәрт.; «Күмәк бию», Х. Вәлиуллин муз. («Самат» операсы); «Көрәш», «Ардым», Р. Закиров муз.; «Җиңел вариацияләр», Р. Еникиев муз.; «Әнисә», татар халык җыры, С. Сәйдәшев эшкәрт. (җиңел вариацияләр); «Әйһәйлүк», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Башкорт көйләре», С. Ишбулатов муз.; «Сайра, сандугач», М. Мозаффаров муз., М. Садри сүз.; «Җиләк җыйганда», М. Мозаффаров муз.; «Такмаклар», татар халык көе, Р. Тимершина эшкәрт.; «Авылда таң ата», «Гармунчы егет», «Ат чабышы», Л. Батыр-Болгари муз. («Авыл күренешләре» циклы).

***Җырлау***

*Музыкаль ишетү сәләтен һәм тавыш үстерү күнегүләре:* «Үстек», Г. Гыйләҗетдинова муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Тукран», С. Бәдертдинова муз., халык сүз.; «Бишек җыры», С. Бәдертдинова муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Көз», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Кошлар килде», Ш. Мәҗитов муз., Г. Латыйп сүз.; «Чәүкә», Г. Гыйләҗетдинова муз., Х. Гарданов сүз.; «Пескәем», Р. Еникиева муз., М. Хөсәен сүз.; «Кояш, чык», Ф. Кәримуллина муз., Р. Вәлиева сүз.; «Атым», Р. Гатина муз. һәм сүз.; «Яз бүләге», Ә. Бакиров муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Яз», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз. һәм сүз.; «Көтүче», Р. Еникиева муз., Н. Исәнбәт сүз.; «Кәҗә, кәҗә, Мәкәрҗә», М. Зәйнуллина муз., халык сүз.; «Урман кайтавазы», С. Бәдертдинова муз. һәм сүз.; «Гөмбәгә», Ф. Җәләлетдинова муз., Г. Рәхим сүз.; «Чебиләр», Л. Шиһабетдинова муз.,

М. Хөсәен сүз.; «Тараканнар кар көри», балалар фольклорыннан, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Хайваннар авазыннан», Р. Тимершина муз., З. Салихина сүз.

*Җырлар:* «Мин җырларга яратам», Л. Таһирова муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Хәерле көн», Ә. Һадиева муз., А. Минһаҗев сүз.; «Яратам», Ф. Хатыйпов муз., Ш. Маннур сүз.; «Нурлы җыр», Г. Гыйләҗетдинова муз., Э. Шәрифуллина сүз.; «Көз килә», Р. Сәрвәров муз., А. Минһаҗев сүз.; «Алтын көз», А. Батыршин муз., З. Нури сүз.; «Әнием», Л. Хисмәтуллина муз., Л. Юнысова сүз.; «Елмаю», Ш. Кашапов муз., Хәйдәр сүз.; «Исәнме, Яңа ел», Г. Гәрәева муз. һәм сүз.; «Кар кызы», Җ. Фәйзи муз., Н. Зариф сүз.; «Балалар ярдәм итә», З. Хәбибуллин муз., Г. Лотфи сүз.; «Яз килә», А. Вәлиуллин муз., З. Мансур сүз.; «Яз җыры», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Язгы тамчы», М. Шәмсетдинова муз., Х. Хәкимуллина сүз.; «Кояшлы ил», Л. Батыр-Болгари муз., Ә. Рәшитов сүз.; «Сөенеч бүләк итәм», Г. Гәрәева муз. һәм сүз., Р. Тимершина эшкәрт.; «Туган тел», татар халык көе, Г. Тукай сүз., Р. Еникиева эшкәрт.; «Җиңү көне», А. Гайнетдинова муз. һәм сүз.; «Чияләр чәчәк атсын», С. Сәйдәшев муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Җырлап яшәр чагыбыз», З. Шәяхмәтова муз., М. Әхмәтҗанов сүз.; «Нәни музыкант», И. Гыйләҗетдин муз., Э. Шәрифуллина сүз.; «Гөлләрем», Л. Таһирова муз., Ә. Кари сүз.; «Иң матур җир», Ф. Кәримуллина муз., Р. Вәлиева сүз.; «Кызыл мәкләр, күбәләкләр», М. Мозаффаров муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Сабан туй», Г. Шакирова муз., Р. Вәлиева сүз.; «Җирдә миңа ни кирәк», Ф. Әхмәтшин муз., Ш. Галиев сүз.; «Мәктәпкә барам», Ф. Шәймәрданова муз., Р. Мозаффаров сүз.; «Рәхмәт сиңа, бакчабыз», Р. Ахиярова муз., Л. Әмирханова сүз.; «Туган илебез», З. Хәбибуллин муз., Х. Вахит сүз.

*Җыр иҗаты:* «Песи, кая барасың?», Р. Тимершина муз., халык сүз.; «Тавык», Р. Тимершина муз., Ә. Кари сүз.; «Куян, син кайда?», З. Ибраһимова муз., халык сүз.; «Хайваннарны чакыру», С. Бәдертдинова муз., халык сүз.; «Әминә», Ә. Бикчәнтәева сүз.; санамышлар: «Җепсез орчык», «Тор, тургай», «Әлчи-бәлчи»; балалар фольклорыннан: юаткычлар, үртәвечләр, санамышлар һәм башка кыска татар халык җырлары.

***Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр***

*Күнегүләр:* «Без инде хәзер зурлар», А. Батыршин муз.; «Марш», «Полька», З. Хәбибуллин муз.; «Төп йөреш», башкорт халык көе («Шәл бәйләдем»), Б. Мөлеков эшкәрт.; «Шаяру», татар халык көе, Р. Тимершина эшкәрт.; «Поход маршы», С. Сәйдәшев муз.; «Бию», «Кояш куянкайлары», Ф. Шәймәрданова муз.; «Түгәрәк уен», татар халык көе, Р. Тимершина эшкәрт.; «Яфраклар белән күнегү», Р. Яхин муз. («Таң атканда»); «Яшьләр биюе», татар халык көе, Р. Тимершина эшкәрт.; «Кыю җайдаклар», Б. Мөлеков муз.; «Түгәрәк уены», татар халык көе, М. Яруллин эшкәрт.; «Кул сугып уйнау», татар халык көе, Р. Тимершина эшкәрт.; «Тасмалар белән күнегү», Р. Яхин муз. («Җыр»); «Төсле шарфлар белән күнегү», Ф. Шәймәрданова муз. («Язгы вальс»); «Бию», татар халык көе, Л. Батыр-Болгари эшкәрт.; «Уенлы бию», Ә. Абдуллин муз.; «Чәчәкләр белән күнегү», С. Сәйдәшев муз. («Лирик көй»); «Флагчыклар тотып тезелү», Р. Яхин муз. («Яшь эзтабарлар маршы»); «Туплар белән күнегү», Ә. Шәрәфиев муз. («Уйнагыз, гармуннар»); «Мәктәп вальсы», Ә. Хәйретдинов муз.; «Кыршау тәгәрәтү», Ю. Виноградов муз.; «Башкорт биюе», Р. Сабит эшкәрт.; «Гөлнәзирә», башкорт халык көе, А. Кобагошев эшкәрт.

*Этюдлар:* «Марш», Х. Вәлиуллин муз.; «Балыкчы малай», Ә. Шәрәфиев муз.; «Шаян бию», Р. Яхин муз.; «Шугалакта», Ю. Виноградов муз.; «Боланнар биюе», Л. Хисмәтуллина муз.; «Беренче яңгыр», Л. Хәйретдинова муз.; «Күбәләкләр биюе», «Чабыш», Р. Еникиева муз.; «Шәрык моңнары», «Таң атканда», Ф. Шәймәрданова муз.; «Су буенда», Ә. Абдуллин муз.

*Биюләр:* «Түгәрәктә бию», татар халык көе; «Вальс», З. Хәбибуллин муз.; «Күчмә бию», татар халык көе; «Бишле бию», татар халык көе, Р. Курамшин эшкәрт.; «Бию», «Яңа ел полькасы», «Чыршы янында бию», «Саубуллашу вальсы», Ф. Шәймәрданова муз.; «Дәртле бию», «Кызлар биюе», Ә. Абдуллин муз.; «Полька», Л. Шиһабетдинова муз.; «Укучылар вальсы», «Шәлләр белән бию»,

С. Сәйдәшев муз.; «Парлы бию», Р. Халитов муз.; «Егетләр биюе», «Биергә чакырам», татар халык көе, М. Макаров эшкәрт.; «Кулчатыр белән бию», Л. Хисмәтуллина муз.; «Күмәк бию», «Дуслаштык», «Сигезле бию», татар халык көе, Ю. Виноградов эшкәрт.; «Парлы бию», татар халык көе, А. Ключарёв эшкәрт.; «Вальс», Р. Халитов муз.; «Зәлидә», татар халык көе, А. Ключарёв эшкәрт.; «Түгәрәк», З. Гыйбадуллин муз., Р. Хафизова сүз.; «Биергә яратабыз», «Парлап биибез», башкорт халык көе, А. Кобагошев эшкәрт.; «Лирик бию», рус халык көе, В. Иванникова эшкәрт.; «Бию», рус халык көе, Г. Фрид эшкәрт.; «Умарина», мордва халык көе, Р. Мостафин эшкәрт.; «Борынгы бию», мари халык көе, С. Маков эшкәрт.; «Тункки-тункки», чуваш халык көе, Р. Тимершина эшкәрт.

*Характерлы биюләр:* «Гөмбәләр», «Бакалар», Л. Хисмәтуллина муз.; «Кар бөртекләре», М. Салихов муз.; «Бүреләр биюе», «Клоуннар», Ф. Шәймәрданова муз.; «Гномнар», Ю. Виноградов муз. («Вальс»); «Ләйсән ява», Л. Батыр-Болгари муз., Ә. Кари сүз.

*Түгәрәк уеннары:* «Әйлән-бәйлән», Ф. Әбүбәкеров муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Көз кунакка килгән», Л. Хисмәтуллина муз., Р. Хисмәтуллина сүз.; «Чыршы янында», И. Шәмсетдинов муз., С. Урайский сүз.; «Чыршыкай – купшыкай», Р. Сәрвәров муз., Х. Әхмәтшин сүз.; «Кыш бабай», Ф. Җәләлетдинова муз., Ә. Рәшитов сүз.; «Шома бас», татар халык җыры, Р. Еникиева эшкәрт.; «Ак каен», М. Вәлиев муз., З. Ярмәки сүз.; «Эх, зилем зиләле», татар халык җырлы-биюле уены; «Түгәрәк», З. Гыйбадуллин муз., Р. Хафизова сүз.; «Без биибез», Р. Гатауллин муз., халык сүз.; «Төймә», татар халык уен җыры, Н. Бакиева эшкәрт.; «Букет», татар халык уен җыры, Р. Тимершина эшкәрт.; «Түгәрәкле биюләр», татар халык көе, С. Баязитова сүз., Р. Тимершина эшкәрт.; татар халык бию көенә кушылып «Бию такмаклары»; «Капка төбе», рус халык җыры, Е. Тиличеева эшкәрт.; «Ялыке», удмурт халык җыры, В. Емельянов эшкәрт.; «Кар бөртеге», удмурт халык җыры, П. Поздеев эшкәрт.; «Болында», мари халык җыры; «Ак каен», чуваш халык җыры, Р. Ильгичева эшкәрт.

*Музыкаль уеннар:* «Үз төсеңне эзлә», С. Низаметдинов муз.; «Чүлмәк сатучы», татар халык уены, А. Мөҗипова эшкәрт.; «Кем беренче?», Ф. Әхмәтов муз.; «Тасмалар җый», Р. Ахиярова муз.; «Дуслашу», татар халык көе, Д. Камалиева эшкәрт.; «Түгәрәк уен», татар халык уены; «Башлык һәм таяк», татар халык көе, Р. Бакиров эшкәрт.; «Таякка атланып», Н. Җиһанов муз.; «Алтын әтәч», татар халык уены, Р. Еникиев муз.; «Почмаклар», З. Хәбибуллин, Р. Еникиев муз.; «Батыр егетләр», башкорт уены, К. Рәхимов, Р. Касыймов муз.; «Бакыр бүкән», башкорт халык уены, Д. Камалиева эшкәрт.; «Энә белән җеп», башкорт халык уены, Р. Тимершина эшкәрт.; «Читән», рус халык уены, Е. Саковнина эшкәрт.; «Кем өлгер?», Л. Шварц муз.; «Чәчәкләр», чуваш халык уены; «Кулъяулык белән уен», удмурт халык уены, Л. Тумашев эшкәрт.

*Җырлы уеннар:* «Танышу», Г. Гыйләҗетдинова муз., халык сүз., Р. Тимершина эшкәрт.; «Кап та коп», татар халык уены, Н. Бакиева муз.; «Каравылчы», татар халык уены, Ф. Шәймәрданова муз.; «Кә-кә-кәбестә», татар халык көе, Ш. Галиев сүз., Г. Гыйләҗетдинова эшкәрт.; «Ике суык», татар халык уены, Ф. Шәймәрданова муз.; «Саныйбыз да уйныйбыз», татар халык көе, Э. Шәрифуллина сүз., Г. Гыйләҗетдинова эшкәрт.; «Чүлмәкче», «Яңгыр», «Тургай», Ф. Шәймәрданова муз., халык сүз.; «Почмак алыш», З. Ибраһимова муз., халык сүз., Р. Тимершина эшкәрт.; «Кем беренче килә», «Мәче һәм тычкан», Л. Шиһабетдинова муз., халык сүз.; «Мин кем?», Ф. Шәймәрданова муз., Р. Насыйбуллина сүз.; «Куып тот», Ф. Шәймәрданова муз.; «Кәҗә, кермә бакчага», А. Мөҗипова муз., халык сүз., Р. Тимершина эшкәрт.; «Капкын», татар халык уены, Д. Камалиева эшкәрт.; «Паровоз», Р. Еникиев муз., халык сүз.; «Кабыргалы-камчылы», башкорт халык уены, А. Кобагошев эшкәрт.; «Буяу сатыш», башкорт халык уены, Р. Тимершина эшкәрт.; «Бер, ике, өч – йөгер!», рус халык уены, С. Бодренкова эшкәрт.; «Кайда

яулык?», мари халык көе, Л. Тумашев эшкәрт., Л. Яхнин сүз.; «Төлке урманда йөри», мордва халык көе, Л. Тумашев эшкәрт., И. Мазнин сүз.; «Ай белән кояш», чуваш халык көе, Л. Тумашев эшкәрт., И. Мазнин сүз.; «Шалкан», чуваш халык уены, И. Вдовина эшкәрт.; «Ян яктырак», удмурт халык көе, Л. Тумашев эшкәрт., И. Мазнин сүз.

*Биюле уен иҗаты:* «Полька», «Вальс», Җ. Фәйзи муз.; «Бию», Р. Еникиев муз.; «Җайдак малай», Ш. Шәрифуллин муз.; «Курчаклар биюе», «Шаян әтәчләр», «Су өстендә бию», Ф. Шәймәрданова муз.; «Егет биюе», Ю. Виноградов муз.; «Торналар биюе», И. Шәмсетдинов муз.; «Кызыл мәкләр – күбәләкләр», М. Мозаффаров муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Вальс», Э. Шәрәфиева муз.; «Без биибез», Р. Гатауллин муз., халык сүз.; «Җырлап бию», татар халык көе, Р. Зарипов эшкәрт.; «Вальс», Җ. Фәйзи муз.; аудиоязмадагы бию көйләренә ирекле биюләр.

***Балалар музыка уен коралларында уйнау***

«Болында», Л. Шиһабетдинова муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Вальс-экспромт», Р. Яхин муз.; «Бию», Җ. Фәйзи муз.; «Сыерчык», И. Шәмсетдинов муз., Г. Лотфи сүз.; «Бишек җыры», Г. Тукай сүз., Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Ай, былбылым», «Ай, матур гөл генә», татар халык көе, Р. Еникиева эшкәрт.; «Зәй-зәй-Зәйнәбем», татар халык көе, Н. Бакиева эшкәрт.; «Әйһәйлүк», «Уфа – Чиләбе», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Саный беләм», Р. Еникиев муз., Җ. Дәрзаман сүз.; «Алтын-көмеш», Р. Сабит эшкәрт; «Өммегөлсем», Ф. Фәизова эшкәрт.; «Атта», Ф. Әхмәтов муз.; «Каз канаты», татар халык җыры, А. Ключарёв эшкәрт.; «Урманда бәйрәм», Н. Мөхетдинова муз., Р. Вәлиева сүз.

***Музыкаль-дидактик уеннар***

*Музыкада аваз югарылыгын ишетү сәләтен үстерү:* «Төрле авазлар», «Бишек җыры», «Баскыч», С. Бәдертдинова эшкәрт.; «Уйла, дөрес әйт!», «Быргы», С. Бәдертдинова муз. һәм сүз.

*Ритмны тою сәләтен үстерү:* «Карусель әйләнә», Р. Гатина муз.; «Кем килә?», «Яфрак бәйрәме», Р. Еникиева муз.

*Тембрны аера белү сәләтен үстерү:* «Тылсымлы кыңгырау»; «Музыкаль йорт»; «Нинди музыка уен коралы яңгырый?».

*Динамик төсмерләрне ишетү сәләтен үстерү:* «Көчле – әкрен», «Эзлә», «Атта», Ф. Әхмәтов муз.

*Музыканы кабул итү:* «Болында»; «Җыр – бию – марш»; «Ел фасыллары»; «Безнең яраткан әсәрләр».

*Музыкаль хәтерне үстерү:* «Композиторны әйт»; «Көйне кабатла»; «Әсәрне танып бел».

***Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәре***

*Сәхнәләштерү, музыкаль спектакльләр:* «Ипекәй белән сөйләшү», татар халык көе, Х. Халиков сүз.; «Яшелчә бакчасында», Л. Хисмәтуллина муз., Р. Вәлиева сүз.; «Балалар һәм торналар», З. Хәбибуллин муз., Г. Лотфи сүз.; «Кунаклар», С. Сабирова муз., Ш. Галиев сүз.; «Карак песи», Җ. Фәйзи муз., М. Җәлил сүз.; «Күбәләк», С. Ихсанова муз., Л. Заһретдинова сүз.; «Балалар һәм казлар», Л. Хәйретдинова муз., К. Тәхау сүз.; «Кызыклы шәкерт», Л. Шиһабетдинова муз., Г. Тукай сүз.; «Болында», Р. Ахиярова муз.; «Бүре һәм кәҗә бәтиләре», балалар фольклоры, Р. Еникиева эшкәрт.; «Албасты», Л. Хисмәтуллина муз., Р. Батулла сүз.; «Эш беткәч уйнарга ярый», Г. Тукай; «Бүләк кемгә?», «Ике кыз», «Гөлчәчәк», татар халык әкиятләре.

*Әдәби-музыкаль композицияләр:* «Алтын көз – уңыш бәйрәме», «Өлкәннәргә – хөрмәт», «Әниләр көне», «Татар теле – туган телем», «Г. Тукай һәм музыка», «Дуслык бәйрәме», «Аулак өй», «Милли музыка уен кораллары», «Татарстан – минем республикам!», «Юлда йөри беләсеңме?».

*Тематик кичәләр:* «С. Сәйдәшев – татар музыкасына нигез салучы», Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты, «Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары», «Халык уеннары», «Халык бәйрәмнәре» («Каз өмәсе», «Карга боткасы» һ.б.), «Идел буенда яшәүче халыкларның мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре» (танышу).

*Бәйрәмнәр:* «Хуш киләсең, Яңа ел», «23 февраль – Ватанны саклаучылар көне», «8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне», «9 Май – Җиңү бәйрәме», «Хуш, балалар бакчасы», «Милли бәйрәм – Сабан туе», «Халыкара туган тел көне».

## • ФИЗИК ҮСЕШ

**Балаларда сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен тәрбияләү, аларда үзләренең гәүдә төзелеше һәм физик мөмкинлекләре турында күзаллауларны баету, хәрәкәт итү тәҗрибәсен алу һәм хәрәкәт итү активлыгын камилләштерү, спортның кайбер төрләре турында беренчел күзаллауларны формалаштыру, кагыйдәләргә буйсынган хәрәкәтле уеннарны өйрәтү өчен шартлар тудыру белем бирү эшчәнлегенең физик үсеш өлкәсендә төп бурыч булып тора.**

***Сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен тәрбияләү өлкәсендә***

Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту. Эре, урта һәм вак моторика дәрәҗәсендә сенсомотор координацияне формалаштыру. Баш мие ярымшарларының үзара йогынтысы үсешенә тәэсир итә торган төрле хәрәкәтләрнең актив үтәлешен булдыру.

Баланың мускул корсетын ныгыту, гәүдәне дөрес тоту рефлексын формалаштыру.

Максатлы прогулкаларда, шәһәр (авыл) буйлап экскурсияләр, туристик походларда катнашу ярдәмендә балаларда оптималь хәрәкәт активлыгы булдыру.

«Сәламәт бул! Өч теләк» китабындагы гыйбрәтле хәлләргә таянып, сәламәт яшәү рәвешенең элементар кагыйдәләрен һәм нормаларын (сәламәт туклану, хәрәкәт режимы, чыныктыру, файдалы гадәтләр) үзләштерергә ярдәм итү.

Белем бирү оешмасының тибын һәм төрен, булган шартларны, төркемнең тулылыгын, төбәкнең климат һәм сезонга караган үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын чыныктыруны оештыру. Балаларның чыныктыру кагыйдәләре һәм төрләре, чыныктыру процедураларының файдасы турындагы белемнәрен тирәнәйтү.

Балаларда дөрес туклану (ашауда чама белү, баллы, камыр, майлы продуктлар, фастфудлар белән артык мавыкмау) турындагы күзаллауларны үстерү. Сәламәт туклануның иң гади кагыйдәләрен үтәргә булышу.

Чәй табынына бирелә торган милли камыр ризыклары: гөбәдия (дөге, йөзем һәм йомыркалы), кабартма, бавырсак, талкыш кәләвә, чәкчәк, кош теле белән таныштыру. Ризык кабул итүнең милли үзенчәлекләре турында сөйләү. Балаларга камыр ризыкларын күпме күләмдә ашарга кирәклеген үзләренә хәл итү мөмкинлеген бирү.

Балаларны республикадан читтә дә танылган дәвалану һәм ял итү урыннары һәм шифаханәләре («Васильевский», «Нарат урманы», «Крутушка», «Бәкер», «Санта» һ.б.) белән таныштыру.

Савыктыру чараларында балаларның актив катнашуы өчен мөмкинлекләр тудыру.

***Хәрәкәт активлыгын камилләштерү, балаларда үзләренең гәүдә төзелеше һәм физик мөмкинлекләре турында күзаллауларны баету, спорт турында башлангыч күзаллауларны формалаштыру өлкәсендә***

Балаларның хәрәкәт итүгә табигый ихтыяҗларын канәгатьләндерү.

Төрле тизлектә, темпны үзгәртә-үзгәртә, әйләнә буенча, юл буенча ике тәгәрмәчле велосипедта йөрү техникасын камилләштерү. Юлдагы ситуацияне күрә белергә, вакытында хәрәкәтне акрынайтырга, билгеләнгән урында туктарга өйрәтү. «Тормоз юлы» төшенчәсе белән таныштыру. Үз сәламәтлегең һәм иминлегеңне саклап калуга юнәлдерелгән күнекмәләрне формалаштырырга булышу.

Балаларга самокатта (уң һәм сул аякта, туры юнәлештә, әйләнә буенча, борылышлар ясап), роликлы тимераякта йөрү мөмкинлеге бирү. Бу хәрәкәтләрдән шатлык хисләре тудыру. Балаларга җәрәхәтләнүләрдән саклану чараларын (шлем, перчаткалар, тез һәм терсәк саклагычлары) куллану турында аңлату.

Балаларга чаңгы шуарга, тимераякта йөрергә, хоккей уйнарга мөмкинлек тудыру. Балаларда спортның кышкы төрләренә карата кызыксыну тәрбияләү.

Балаларның Идел буе халыклары уеннарын мөстәкыйль оештыруларын хуплау. Хәрәкәт итү активлыгыннан балаларда уңай эмоцияләр тудыру. Уен нәтиҗәләрен гадел бәяли белүләрен хуплау.

Татар хәрәкәтле уеннарын үзгәртә, бер-берсе белән катнаштыра белү күнекмәләренә өйрәтү. Сабантуй милли бәйрәмендә «Таяк тартыш», «Бау тартыш», «Капчык сугышы» һ.б. уен-ярышларда балаларның актив катнашуы өчен мөмкинлекләр тудыру.

Кеше тормышында спортның әһәмияте турында күзаллаулар формалаштыру. Спортның милли төре – татарча көрәш белән таныштыру. Балаларда спортның милли төрләре белән шөгыльләргә карата кызыксыну уяту. Физик культура һәм спорт өлкәсендә аерым казанышларны хуплау.

## ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР ИСЕМЛЕГЕ

***Йөгерүле уеннар.*** «Йортсыз куян», «Аю», «Куышу», «Ачкычлар», «Сыерчык оялары», «Төлке», «Парлашып бас».

***Сикерүле уеннар.*** «Сикергечләр», «Бакалар», «Чикерткәләр», «Песи һәм чыпчыклар», «Әтәчләр».

***Шуышулы һәм үрмәләүле уеннар.*** «Күчмә кошлар», «Кыңгырау шалтыратам», «Кем беренче?».

***Тупны ыргыту һәм тотып алу уеннары.*** «Тупны тапшыр», «Иң төз атучы», «Куянкай», «Тупны биеккәрәк ыргыт!», «Чыпчык оча».

***Эстафета, ярыш уеннары.*** «Туплы эстафета», «Көнгерә», «Кем тизрәк?», «Матур шарлар», «Поезд», «Кыргаяклар ярышы».

**Татар халык уеннары.** «Чүлмәк сатыш», «Күз бәйләш», «Төенчек», «Бүкән», «Почмак алыш», «Самавыр», «Без-без, без идек...», «Аксак төлке».

***Рус халык уеннары.*** «Зур туп», «Буш урын», «Качышлы», «Лапта», «Җәнлекләр өйрәтүче», «Балык тоту».

***Башкорт халык уеннары.*** «Әбәк-күбәк», «Энә белән җеп», «Йөзек салыш», «Исемен әйт», «Курай».

***Мари халык уеннары.*** «Әтәчләр сугышы», «Тилгән һәм казлар», «Кем тизрәк?».

***Мордва халык уеннары.*** «Тупны тидер!», «Ачкычлар», «Чүлмәкләр».

***Удмурт халык уеннары.*** «Су анасы», «Кулъяулык белән уен», «Сукыр тәкә», «Атның койрыгын тот!».

***Чуваш халык уеннары.*** «Бүре һәм куян», «Җитез тиеннәр», «Ай һәм кояш», «Инешләр».

## 2.2. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУДА ВАРИАТИВ ФОРМАЛАР, АЛЫМНАР, МЕТОДЛАР ҺӘМ ЧАРАЛАР

«Куаныч» төбәк белем бирү программасы мәктәпкәчә төп белем бирү программасын тулыландыра. Күләме аны тормышка ашыру өчен кирәкле вакытның 40 %ыннан артмый һәм Оешма тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

Төп белем бирү программасының вариатив өлешен тормышка ашыру, социомәдәни шартларның төрлелеген, тәрбияләнүчеләрнең милли составын, яшен, аларның кызыксынуларын, балаларны тәрбияләүдә һәм белем бирүдә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) уңышларын, шулай ук әйләнә-тирә социум мөмкинлекләрен исәпкә алып, www.куаныч.рф интернет-порталындагы электрон белем бирү ресурслары нигезендә тәэмин ителә. Белем бирү Программасы тарафыннан каралган электрон белем бирү ресурсларыннан тыш, Оешма күрсәтмә, таратма, табигый, ясалма, реаль һәм виртуаль чаралар кулланырга хокуклы.

Балаларга тәрбия һәм белем бирү бурычларын тормышка ашыруда форма, чара, алым һәм методларны тәрбияче үзе сайлый.

Уеннарның төрле төрләре, шул исәптән дидактик, үстерешле, рольле, традицион хәрәкәтле һәм халык уеннары; өлкәннәр белән балаларның һәм/яки балаларның үзара хезмәттәшлеге; төрле (иң әүвәл тикшеренү) юнәлештәге проектлар; милли бәйрәмнәр, социаль акцияләр һ.б.ш. белем бирү эшчәнлеген оештыруның вариатив формаларына мисал була ала.

Шөгыль үз кыйммәтләрен югалтмады, әмма ул белем бирү эшчәнлеген оештыруның бердәнбер формасы буларак каралырга тиеш түгел. Балалар белән махсус фронталь һәм индивидуаль уен-шөгыльләрнең белем бирү процессында үз урыны бар, һәм алар традицион белем бирү формалары булып тора.

Мәгълүматны үзләштерү этабында оештыруның башка формалары да актив кулланылырга мөмкин. Өлкәннәр тарафыннан оештырылган һәм балалар үзләре сайлап алган мөстәкыйль эшчәнлек төрләрен бәйләп алып бару аша барлык бу формалар бергә һәм һәркайсы аерым рәвештә гамәлгә ашырыла ала.

Белем бирү Программасын гамәлгә ашыруда төрле белем бирү технологияләре (модельләштерү, проектлаштыру, үстерешле белем бирү, уйлап табу мәсьәләләрен чишү теориясе (ТРИЗ), «Ситуация» һ.б.) кулланыла ала. Балалар сәламәтлегенә зыян салмыйча гына, мөмкинлек булганда, электрон өйрәтү һәм читтән торып белем бирү технологияләре кулланыла ала. Программаны гамәлгә ашырганда электрон өйрәтү, читтән торып белем бирү технологияләрен куллану, шулай ук электрон белем бирү чаралары белән эш 2.4.3648-20 Санитария кагыйдәләре һәм 1.2.3685-21 Санитария кагыйдәләре һәм нормалары таләпләренә туры килергә тиеш.

Белем бирүне оештырганда, нигезенә балаларның танып белү активлыгының характеры салынган традицион методларны (сүзле, күрсәтмәле, гамәли) заманча методлар белән (үстерешле белем бирү, авазлар ассоциациясе, Сингапур методлары һ.б.) тулыландырырга мөмкин.

Тәрбия бирү бурычларын чишкәндә, *үз-үзеңне тоту һәм эшчәнлек тәҗрибәсен оештыру* (җәмгыятьтә үз-үзеңне тотуда уңай үрнәкләр булдыру, күнегү, тәрбияви һәм уен ситуацияләре), *балаларның үз-үзләрен тотышын һәм эшчәнлек тәҗрибәләрен аңнарына сеңдерү* (өлкәннәрнең шәхси үрнәге, татар язучыларының һәм шагыйрьләренең әсәрләрен уку, «Татармультфильм» оешмасының мультипликацион фильмнарын карау, тәртип һәм кагыйдә нормаларын аңлату, тормыш ситуацияләренә һәм эш-гамәлләргә бәя бирү), *үз-үзеңне тоту һәм эшчәнлек тәҗрибәләренә мотивацияләү* (бүләкләү, ярышлы уеннар, проектлар) *методларын* кулланырга мөмкин.

Тәрбия һәм белем бирү методларын сайлаганда, педагог балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен, һәр методның педагогик потенциалын, аны куллану шартларын, тормышка ашырыла торган максат һәм бурычларын исәпкә ала, балаларның ирешергә мөмкин булган казанышларын фаразлый. Тәрбия һәм белем бирү бурычларын чишүдә методлар комплексын кулланырга мөмкин. Шуның белән беррәттән, балаларның эшчәнлектә субъект буларак үз-үзләрен күрсәтә белүләрен истә тотарга кирәк: әйләнә-тирә дөнья һәм татар халкының мәдәниятенә карата кызыксыну, эшчәнлекнең төрле төрләренә карата сайлаулы караш, эшчәнлекне сайлауда һәм гамәлгә ашыруда инициатива күрсәтү һәм мөстәкыйльлек, милли мәдәният объектларына интерпретация ясауда һәм эшчәнлек продуктларын булдыруда иҗадилык.

Балаларны туган (татар) яисә рус теленә өйрәтүне оештырганда, белем бирү бурычларын тормышка ашыру чаралары, алымнары, методлары, белем бирү эшчәнлеген оештыру формаларын гына түгел, балаларның коммуникатив сәләтләрен үстерүдә булган казанышларын истә тотып, белем бирүнең тагын да нәтиҗәлерәк модельләрен кулланырга кирәк.

**1. Белем бирү-дисциплинар модель** балаларны туган (татар) яисә рус теленә өйрәтү белем бирү эшчәнлегендә гамәлгә ашырыла торган итеп махсус оештыруны күздә тота.

Төркемчәләр белән үткәрелгән уен-шөгыльләрнең дә белем бирү процессында урыны бар. Аларның нәтиҗәлелеге белем бирү этабында эзлекле рәвештә күзәтелә. Үзара бәйләнешнең мондый формасында тәрбияче актив позициядә тора, балалар мөстәкыйль рәвештә үзләштерә алмый торган эчтәлекне ача (сүзне әйтә, җөмлә төзелешенең үзенчәлекләрен аңлата, әсәрдән өзек укый, рус халык әкиятләре, гыйбрәтле хикәятләр сөйли һ.б.). Балаларга бирелгән мәгълүматны аңларга һәм үзләштерергә ярдәм итәргә кирәк.

Мондый уен-шөгыльләр уртанчылар төркемендә һәркайсы 20 минуттан да артык булмаган, зурлар төркемендә – 25 минут, мәктәпкә әзерлек төркемендә 30 минут дәвамында атнага 3 тапкыр уздырыла.

Төрле яшьтәге балалар белән белем бирү процессын планлаштыруның үз үзенчәлеге бар. Кечкенәләр, уртанчылар һәм зурлар төркемнәрендә белем бирү процессында күбесенчә өйрәтүнең актив формалары кулланылса, мәктәпкә әзерлек төркемендә махсус оештырылган өйрәтү шөгыльләре мөһим урын алып тора. Шөгыльләрдә укыту-методик комплектын, электрон белем бирү ресурсларын куллану, уен аша өйрәтү бурычын кертү, аны хәл итү белем бирү эшчәнлегенең алшартларын формалаштыруга ярдәм итә: бурычны кабул итә белү, инструкция буенча эш итү, үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү. Әмма шул ук вакытта махсус оештырылган шөгыльләрнең әһәмиятен бик күпертү дә дөрес түгел. Балаларга рольле һәм режиссёрлык уеннары, педагог белән аралашу, конкрет объектлар белән эш итү, реаль вакыйгаларны күзәтү һ.б. якынрак.

Балалар бакчасында балаларны татар (рус) теленә өйрәткәндә, тәрбиячегә телне үзләштерүне ясалма оештырылган үстерешле характердагы тел мохите шартларында тормышка ашырылу тиешлеген исеннән чыгармаска кирәк. Телне үстерә торган мохит төшенчәсе предметлы тирәлек мохитен дә, шулай ук нигезендә педагогның тәрбияләнүчеләр белән дидактик аралашуы яткан чын мәгънәсендәге тел мохитен дә үз эченә ала. Әгәр өлкәннәр сөйләм культурасына ия, балалар белән аралаша һәм аларның активлыгын хуплый икән, әйләнә-тирә мохитнең сөйләм үсешенә йогынтысы да уңай булачак.

Төркем тәрбиячеләренә, бала эшчәнлеге интеграциясенә һәм бурычларның төрлелегенә таянып, телгә өйрәтү материалын системалы рәвештә ныгытып торырга кирәклеген истә тоту зарур.

**2. Үстерешле модель** балаларны туган (татар) яисә рус телендә белем бирү эшчәнлеге шартларында һәм көндәлек режим моментларында өйрәтүне дә күздә тота.

Махсус оештырылган сөйләм ситуациясе сөйләм үсеше өчен шартлар тудырылган аерым бүлмә булдыруны күзаллый. Ул укыту-методик комплектларны үзләштерү өчен кирәкле булган мультимедиа җиһазлары, төрле типтагы сүзлекләр (рус-татар, татар-рус, аңлатмалы, синонимнар, антонимнар, фразеологик һ.б.), ачык җете күрсәтмә әсбаплар, дидактик аудио- һәм видеоматериаллар белән җиһазландырылырга мөмкин. Бу бүлмә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт символикасы, Россия һәм Татарстан башкалаларының фоторәсемнәре, туган шәһәрнең (авылның) төп истәлекле урыннары, татар һәм рус декоратив-гамәли сәнгатенең матур альбомнары, үстерешле уеннар, төрле балалар рәсемнәре, проектлар, уенчыклар, татар әкиятләре персонажлары, балалар өчен матур әдәбият һ.б. белән дә җиһазландырыла ала.

Тәрбияче режим моментлары барышында уздырыла торган белем бирү эшчәнлеген аның кысаларында өйрәнелгән материалны аралашуның табигый ситуацияләрендә ныгытырлык итеп оештыра.

Режим моментлары барышында бала өчен әлегә мәгънәсе аңлашылмаган ят сүзләр аның баш миенең уң як ярымшарын активлаштырачак, аңарда бу сүзләрнең мәгънәсенә төшенү һәм кирәкле ситуацияләрдә файдалану теләге туачак. Яңа шартларда аралашуны оештыру балага сөйләмне уңышлы үзләштерергә мөмкинлек бирәчәк (М.М. Кольцова, Е.Ю. Протасова).

Режим моментлары барышында шөгыльләр саны проект (әңгәмә, аралашу) темасына бәйле булачак. Табигый аралашу ситуациясен тудырырга мөмкинчелек бирә торган режим моменты – саф һавада йөрү – «Язгы күңел ачулар» проектын гамәлгә ашыруда тел өйрәтү процессын оештыруның иң кулай формасы булачак. Табигать күренешләрен күзәтү барышында аралашу, кәгазь көймәләр йөздерү, сабын куыклары, кояш нуры шәүләсе белән уеннар, велосипед, самокатта йөрү үткән материалны ныгытуга, яңа шартларда сүзлекне активлаштырырга ярдәм итәчәк, ә хис-тойгылар китереп чыгарган сүз-гыйбарәләр хәтергә озакка уелачак.

Көн дәвамында бала белән аралашуны шундый итеп корырга кирәк: ул диалогка керерлек, сорауларга җавап кайтарырлык, үзе сорау бирерлек, уртак эшчәнлек барышында вазифалар үтәрлек, ягъни аңлы рәвештә сөйләм гамәлләрен башкарырлык булсын. Балалар белән мультфильмнар карау, китаплар уку, ике телдә аудиоязмалар тыңлау һәм алар турында алга таба фикер алышу, «Тәрҗемәчеләр» уенын уйнау файдалы. Өлкәннәр белән дә, яшьтәшләре белән дә аралашудан туган сөенеч уртак эшчәнлек мотивы булырга мөмкин. Шулай итеп, балалар бакчасының көндәлек тормышында туган (татар) яисә рус теле яңа функция башкара – аралашу чарасына әйләнә.

**3. Шәхескә юнәлтелгән модель** өлкәннәр һәм балаларның уртак партнёрлык эшчәнлеге шартларында көн дәвамында тормышка ашырыла.

Барыннан да элек, балага төркемдә уңайлы булуны тәэмин итәргә кирәк, ул, нәрсәнедер аңлап җиткермәгәнгә күрә, җәфа чигәргә тиеш түгел. Икетелле балалар йөргән бакчада һәр өлкән кеше (әти-әни, тәрбияче, кече тәрбияче) сөйләмне үстерү буенча педагог та булып тора. Алар, теге яки бу очракта кулланыла торган стандарт фразалар белән таныштыру өчен, килеп туган ситуациядән файдалана.

Көн дәвамында балалар эшчәнлегенең төрле төрләре гомуми контекст белән берләштерелергә тиеш (проектның темасы). Аның эчтәлеге вариатив һәм тәрбияче тарафыннан үзгәртелергә мөмкин. Сүзлек запасын үстерүнең җитәрлек һәм кирәкле дәрәҗәсен, аның активлашуын, коммуникатив-эшчәнлекле тәҗрибәсен баетуны исәпкә алып, катгый беркетелмәгән, ә шәхси (шәхси-дифференциаль) алымнан файдаланырга киңәш ителә. Теге яки бу мәсьәләне хәл итү өчен, бер эшчәнлек төрен көндәлек режимда күрсәтелгән вакыт кысаларында башкасына алыштыру мөмкин.

Тәрбиячегә даими рәвештә баланың әйләнә-тирәсендәге предметларның исемен атарга, иллюстрацияле картотекалардан файдаланырга, вакыт-вакыт кулга уенчык-персонаж алып, роль

буенча тавышны үзгәртеп, аның белән сөйләшергә, шул рәвешле балага аралашу үрнәге бирергә кирәк.

Бала шактый зур сурәтле ачык җете рәсемнәргә мохтаҗ. Шуңа күрә предметларны һәм аларның үзлекләрен күрсәткән зур тематик плакатлар (мәсәлән: «Бу – лимон. Ул сары һәм әче. Ә бу – алма. Ул түгәрәк, кызыл, татлы»), сурәтләнгән объектларның гамәлләрен тасвирлап булырлык сюжетлы рәсемнәр сериясен (мәсәлән: «Аю өнендә йоклый. Куян урман буйлап сикереп йөри. Кошлар агач ботагында утыра») элү файдалы.

Бала телне начар белгән очракта, тәрбиячегә аралашуны ул аңларлык яисә сөйләшү предметы турында төшенерлек итеп оештырырга кирәк. Әйтик, бергә урамда йөргәндә, «бу чәчәк ак, ә бу ... кызыл» дип, җөмләне дәвам итеп, җитешмәгән сүзне бала бик җиңел табарлык ситуацияләр тудыру мөһим.

Программаның вариатив өлешен тормышка ашыруның теләсә нинди форма, ысул, методлары һәм чаралары баланың белем алу процессында актив катнашуын тәэмин итәргә тиеш. Бала белем эчтәлеген, активлык формаларын сайлауда үзе актив катнаша. Шул ук вакытта баланың сөйләм активлыгын күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм ярдәм итү педагогның яңа функциясенә әйләнә. Педагог, тел мохитенә кертеп һәм материаллар тәкъдим итеп, баланың үз-үзен тотышын күзәтә һәм сөйләм үсешен характерлый торган мөһим моментларны теркәп бара. Кирәк булган саен, ул ярдәм күрсәтә, сиздермичә генә сүзнең дөрес формасы үрнәген бирә, сөйләм активлыгы өчен мактый. Педагог балаларны үз үрнәгендә өйрәтә, үз тәҗрибәсен җиткерә, балалар инициативасын хуплый, эшчәнлекне планлаштырырга һәм аның нәтиҗәләрен анализларга ярдәм итә. Шул рәвешле, сөйләм үстерү уртак партнёрлык эшчәнлеге алып бару шарты буларак кабул ителә.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: **педагогның теге яки бу белем бирү модельләрен сайлау яки аларны катнаштыру, шулай ук башка вариатив модельләр төзү хокукы кала.**

Тел мохитен булдыруның төп чараларыннан берсе – Оешмада педагогларның коммуникатив эшчәнлеге. Сөйләмнең тәэсире балага өйрәнергә ярдәм итсен өчен, кайбер шартларны истә тотарга кирәк:

1) тәрбиячененң, шул исәптән рус телен өйрәтү буенча тәрбиячененң сөйләме балаларга аңлаешлы булырга тиеш, синтаксик яктан бик катлаулы озын җөмләләр кулланмау хәерле;

2) әгәр бала тәрбиячененң нәрсә турында сөйләгәнен аңламый икән, кабатлауларны, җөмләне үзгәртүне, ишарәләрне һәм башка алымнарны кулланырга киңәш ителә. Башта сүзләрне бик ачык итеп акрын темпта, аннары тизрәк, табигыйрак әйтү зарур;

3) гадәттә, тел өйрәнгәндә, барлык балалар да материалны бер үк төрле тизлектә үзләштерә алмый, шунлыктан аларның шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алу мөһим. Яңа мәгълүматны балалар төрле кабул итү каналлары (күрү, ишетү, кинестетик) аша үзләштерә, ә уен аша өйрәткәндә исә, материал гади ятлауга караганда җиңелрәк һәм тизрәк хәтергә сеңә;

4) өйрәтүнең һәр яңа этабына күчү – **сөйләм үсешенең алдагы этапларын тәмамлау түгел, ә аларны алга таба интенсивлаштыру һәм катлауландыру** дигән сүз ул.

Балаларга башлангыч тел белеме бирү процессын проектлаштырганда, Оешмадагы барлык белгечләрнең: тәрбиячеләрнең, логопедларның, физик культура буенча инструкторларның, музыка җитәкчеләренең, өстәмә белем бирү педагогларының көчен берләштерү бик мөһим. Куелган бурычларны тормышка ашыруда белгечләрнең системалы рәвештә үзара килешеп эш алып барулары зарур. Моннан тыш, сөйләм үсешен мониторинглауның күзәтү методына нигезләнгән һәм, киләчәктә оптимальләштерү максатыннан, педагогик гамәлләрнең нәтиҗәлелеген бәяләүгә бәйле системасы кирәк.

Балаларның билгеле бер контекстлы эчтәлекне үзләштерүе кульминация моменты – ял, бәйрәм, спектакль, махсус оештырылган уен ситуациясе формасында тәмамланырга мөмкин,

анда балалар алынган белемнәрен гомумиләштерә, уңышларын күрсәтә. Мондый чаралар балаларның сөйләм үсеше динамикасын һәм үзенчәлекләрен ачыкларга, алынган мәгълүмат нигезендә Программаны үзләштерүнең шәхси белем бирү маршрутын төзергә ярдәм итә, педагогка белем бирү эшчәнлеген үз вакытында оештырырга, планлаштырырга һәм эчтәлегенә үзгәрешләр кертергә мөмкинлек бирә.

## 2.3. БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ МӘДӘНИ ПРАКТИКАЛАРНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырыла торган төп белем бирү программасының бер өлешен тормышка ашыру һәм үзләштерү буенча балалар белән өлкәннәрнең эшчәнлеге ике төп модельдә – **өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеге һәм балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә оештырыла.**

Өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеге кысаларында белем бирү бурычларын үтәү бала эшчәнлегенең төрле төрләрен оештыру процессында башкарыла торган белем бирү эшчәнлегендә дә, шулай ук көндәлек режим барышында (балаларның иртән килүе, урамда йөрүе, ризык кабул итүгә әзерлек, көндезге йокы һ.б.) уздырыла торган белем бирү эшчәнлегендә дә гамәлгә ашырыла.

Белем бирү эшчәнлеге балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен (уен, танып белү, коммуникатив һ.б.) оештыру яки аларның интеграциясе аша тормышка ашырыла. Эшчәнлек төрләрен педагог үзе сайлап ала. Белем бирүдә интеграцияле алым танып белү ысулларын эшчәнлекнең бер төреннән икенчесенә күчерү буларак карала. Интеграцияле белем бирүнең үзенчәлеге шунда: ул белем бирүнең үзенчәлекле үзәге булган бер өстенлекле эшчәнлеккә нигезләнә. Калган эшчәнлекләр исә белем бирүнең төп эчтәлеген тирәнрәк аңларга булыша.

Көндәлек режимның белем бирү потенциалын истә тотарга кирәк. Өлкәннәр һәм балаларның режим моментларындагы аралашуы вакытында гадәти рәвештә килеп чыккан диалоглар балалар өчен сөйләм моделе һәм охшатып сөйләү өчен үрнәк булып тора. Нәкъ менә кызыклы аралашу, танып белүгә ярдәм итә торган уку, мавыктыргыч уен, мультфильмнар, әвәләү, рәсем ясау – эшчәнлекнең бу төрләре балаларның туган телдә сөйләмен баета һәм камилләштерә. Балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен үстерү һәм баланың сөйләм телен үстерү арасында ике яклы бәйлелек күзәтелә. Шуңа күрә, **туган телдә сөйләмне үстерү өчен, балалар эшчәнлегенең теләсә кайсы төрен файдалана белү бик мөһим.**

Белем бирү эшчәнлеген тәрбияче үзара аралашуның концентрацияле формасы буларак төзергә тиеш. Перспективалы үстерешле, уен, цифрлы һәм мәгълүмати-коммуникацион технологияләр, үз-үзеңне үстерү технологиясе (М. Монтессори), уйлап табу мәсьәләләрен чишү теориясе (Г.С. Альтшуллер), модельләштерү технологиясе (Л.А. Венгер) һ.б. кебек заманча технологияләрне дөрес файдаланганда, алдан планлаштырылган нәтиҗәгә ирешергә мөмкин. Теләсә кайсы технологиянең асылы – диагностика ярдәмендә куелган максатлар һәм алдан планлаштырылган нәтиҗәләр нигезендә югарырак нәтиҗәгә ирешү. Технологиядән файдалану процессы укыту методларын һәм чараларын катнаштырырга, мәктәпкәчә белем бирүнең эчтәлеген структуралаштырырга, белем бирү процессына төзәтмәләр кертергә мөмкинлек бирә. Авазлар ассоциациясе, уен, үстерешле белем бирү, модельләштерү, проектлаштыру кебек заманча методлар, шулай ук Сингапур методы буенча эш тәҗрибәсе аралашуның нәтиҗәлелеген тәэмин итәчәк. Туган (татар) телне өйрәтүне оештыру методлары һәм формалары аның максат һәм бурычларына тәңгәл килергә тиеш.

Балалар инициативасын хуплауда әңгәмә мөһим роль уйный. Әңгәмә барышында бала үз фикерен әйтергә һәм әңгәмәдәшен тыңларга өйрәнә. Дөрес формалаштырылган сораулар

фикерне уята, элемтә һәм гомумиләштерүләр урнаштыруга китерә. Әңгәмәне дөрес алып бару диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерә.

Диалогтан монологка күчү барышында логик эзлеклелек күзәтелә: башта өлкән кеше баланы гади җөмләләр төзергә, аннары аларны үзара бәйләргә өйрәтә. Шул ук вакытта баланың сөйләме ирекле төсмер ала, аңа планлаштыру элементы кертелә, бу исә хикәяне, интонацион тәэсирле монологны мөстәкыйль төзү процессына күчәргә мөмкинлек бирә.

Тәрбия чаралары системасын үзгәртүгә юнәлтелгән халык авыз иҗаты һәм матур әдәбият иркен аралаша башлауга, шулай ук әхлакый фикерләр туугa ярдәм итә. Балалар өчен язылган әсәрләрне сайлап алудан бигрәк, аларны сюжет эчтәлеген анализлауга, хис һәм үзара мөнәсәбәтләрне тасвирлауга, әдәби әсәр геройларының гамәлләренә бәя бирә белүгә әзерләү мөһим. «Татармультфильм» берләшмәсенең балалар өчен махсус сайлап алынган мультипликацион фильмнары да әлеге контекстта нәтиҗәле булып тора, чөнки аларда кешеләр генә түгел, ә төрле эмоциональ халәттәге һәм әхлакый сайланыш ситуацияләрендәге хайваннар да төп геройлар булырга мөмкин. Мультфильмнарның үстерешле потенциалы бары тик аларны сайлап алу һәм эчтәлеген анализлау буенча алдан эш алып барылган очракларда гына актуаль булып торуын искәртеп китәргә кирәк.

Туган телне үзләштерүгә Татарстан Республикасы сынлы сәнгать әсәрләренең эмоциональ йогынтысы да ярдәм итә. Сәнгатьне кабул итү – кешенең хис һәм фикеренең киеренке эшчәнлеге, аерым рухи хезмәте ул. Картинаның эчтәлеге буенча эшләгәндә, тәрбияче балаларның эмоциональ кичерешләрен, үз хисләрен һәм фикерләрен белдерә алу сәләтен үстерә. Шунысын да исәпкә алырга кирәк: картинадагы пейзажны яки натюрмортны карау сурәтләнгән объектларны (күренешләрне) кызыксыз санап чыгуга гына кайтып калырга тиеш түгел.

Кечкенәләр төркемнәрендә балаларга белем бирүгә килгәндә исә, икенче-өченче ел дәвамында уртак эшчәнлек әкренләп мөстәкыйль эшчәнлеккә күчә (Ю.М. Хохрякова). Педагог аерым кечерәк төркемнәр (ике-дүрт бала) белән үткәрә торган ***шәхсиләштерелгән мини-шөгыльләр*** сөйләм үсеше бурычларын, нинди дә булса гамәлгә өйрәтүне тормышка ашыру өчен уңай мөмкинлекләр тудыра. Мондый шөгыльләр, гадәттә, биш минуттан да озакка бармый. Шәхсиләштерелгән мини-шөгыльләр сабыйларда үз гамәлләрен оештыру һәм элек мини-шөгыльләрдә үзләштерелгәннәрне куллану ысулларын ныгытуның иң гади күнекмәләрен формалаштыруга юнәлтелгән ***төркемчәләр белән уздырыла торган шөгыльләр*** белән үрелеп барылырга мөмкин. Мондый шөгыльләрнең вакыты һәм катнашучылар саны төгәл билгеләнми, әмма алар көн саен иртәнге ашка кадәр яки кичке аштан соң, төркемдә иң күбе алты-сигез бала гына булганда үткәрелә. Балаларның күбесендә теге яки бу уенчык (предмет) белән эш итә белү күнекмәләре үсә барган саен, аларның сөйләм үсеше дәрәҗәсен исәпкә алып, ***фронталь шөгыльләр*** оештыру мөмкинлеге булдырыла. Мондый шөгыльләрнең үзенчәлеге – баланың мөстәкыйль эшчәнлеген үстерүгә турыдан-туры юнәлгән булуы.

Сабыйларның актив сөйләмен үстерү өчен иң яхшы шартлар өлкәннәр аларның инициативалы мөрәҗәгатьләрен хуплаганда туа. Моннан тыш, һәр тәрбияләнүченең фикерен игътибар белән, кызыксынып тыңлап, аларны тулыландыралар һәм төгәлләштерәләр, социаль мөнәсәбәтләрне, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуны камилләштерү максатыннан, дөрес әйтү үрнәген биреп, сиздермичә төзәтәләр.

Мәктәпкәчә яшьтә балалар мәгълүматка бик мохтаҗ. Шуңа күрә балаларга сөйләм күнекмәләрен һәм коммуникатив сәләтләрен булдырырга ярдәм итә торган махсус оештырылган аралашу кирәк. Туган телне үзләштереп, балалар аралашуның иң мөһим формасына – сөйләм теленә өйрәнә.

Туган (татар) телен өйрәнү процессы баланың Программа тарафыннан һәр яшь өчен аерым билгеләнгән татар теле нормаларын һәм кагыйдәләрен үзләштерүеннән, аларны аралашуның

табигый ситуацияләрендә кулланууыннан һәм төп коммуникатив сәләтләргә ирешүеннән гыйбарәт. Коммуникатив сәләт ана (татар) теленең грамматик формаларын куллану тәҗрибәсен туплауны, актуаль һәм потенциаль запасны баетуны, аралашу процессын фаразлау һәм программалаштыруны, коммуникатив ситуациягә «керү» һәм аның белән идарә итүне, шулай ук аралашу процессының үзен, социаль партнёр мәнфәгатьләрен исәпкә алуны һәм коммуникатив культураны үз эченә ала.

Бала өлкәннәр һәм башка балалар белән уртак эшчәнлектә генә түгел, **мөстәкыйль эшчәнлектә** дә үсә. Мәдәни практикаларның кыйммәтләре эшчәнлекнең төрле төрләрендә балаларның мөстәкыйльлеге һәм иҗаты, активлыгы, инициативалы булуларында чагыла һәм аларның нәтиҗәлелеген тәэмин итә. Мәдәни практикаларга уен, танып белү-тикшеренү, коммуникатив практика, балалар матур әдәбиятын уку керә. Төркемнең үстерешле предметлы тирәлек мохитен оештыру да әһәмияткә ия. Балаларның коммуникатив активлыгын үстерү, аларның үсешен баету өчен, тәрбиячегә предметлы мохитне баету, яңарту, дидактик һәм уен чараларын даими рәвештә алыштырып тору мөһим. Төркемнең үстерешле предметлы тирәлек мохитен коммуникатив активлыкны арттырырлык итеп оештыру мөһим. Тәрбиячегә төркемнең предметлар мохитен баетырга, аны яңартырга, дидактик һәм уен чараларын даими алыштырып торырга кирәк.

Мәктәптә татар телен өйрәнүгә махсус әзерлеккә аерым игътибар бирергә кирәк. Моның өчен балаларны сүзгә аваз анализы ясарга; сузык һәм тартык авазларны аерырга, сүзнең авазлар структурасында ориентлашырга, тәкъдим ителгән модельләргә сүзләр сайларга; сузык аваз хәрефләрен танырга һәм сузыкларның тартык авазларга йогынтысын күрсәткән кагыйдәләрен аңлатырга кирәк.

Балаларны грамотага өйрәтүгә әзерлек – ул берничә уку-укыту операциясеннән торган иң катлаулы программа бурычларының берсе. Аны хәл итүдә Р.К. Шәехованың «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып» (1 нче һәм 2 нче кисәк, 2023) эш дәфтәрен файдалану ярдәм итәргә мөмкин.

Балаларны рус теленә өйрәтүне эшчәнлекнең төрле төрләрен оештыру процессында башкарыла торган белем бирү эшчәнлегендә дә, шулай ук көндәлек режимны үтәгәндә уздырыла торган белем бирү эшчәнлегендә дә уртанчылар төркеменнән башларга киңәш ителә. Өйрәтү характеры ***махсус оештырылган сөйләм ситуацияләрендә*** генә түгел, ә көндәлек режимны үтәгәндә килеп туган ситуацияләрдә дә кулланылырга тиеш, бу вакытта гади җөмләләрдән катлаулыларына әкренләп күчү мөһим. ***Аралашуның табигый ситуацияләре*** өлкәннәр һәм бала эшчәнлегендә партнёрлык мөнәсәбәтләре урнашуга шарт булып тора.

Баланың үсешен тәэмин итә торган шартларга, шулай ук куелган максатларга бәйле рәвештә бурычлар төрле күләмдә: киләчәктә мәктәптә русча укыр өчен рус телен тулысынча үзләштерүдән алып, сөйләм һәм коммуникатив сәләтләрне үстерү максатында өстән-өстән генә өйрәтүгә кадәр куела ала. Шуңа ярашлы рәвештә укыту формалары төрле: балалар эшчәнлегенең төрле төрләрендә тулысынча рус телендә аралашудан алып, атнага берничә тапкыр 20–30 минутлык белем бирү эшчәнлеген оештыруга кадәр булырга мөмкин. Галимнәр киңәшләрен исәпкә алырга кирәк: алар раславынча, «балалар белән көн саен аралашу икенче телне яхшылап өйрәнү мөмкинлеген бирә» (Е.Ю. Протасова, Н.М. Родина).

Мәктәпкәчә яшьтәге бала өлкәннәр белән уртак эшчәнлектә һәм мөстәкыйль рәвештә туган ягын, аның тарихын, мәдәниятен белергә, сәнгать әсәрләрен аңларга, әйләнә-тирә табигатьнең матурлыгына, шәһәр (авыл) архитектурасына сокланырга, мавыгып уйнарга, туган (татар) телендә һәм башка милләтләр телендә аралашырга өйрәнә. Татар халкының мәдәни мирасына җәлеп итү, өлкәннәр – телне белүчеләр белән аралашканда мәдәни күнекмәләрне үзләштерү


мәдәни практикаларны үзләштерү процессы буларак кабул ителә. Ләкин чираттагы сораулар туа: ничек итеп балаларны татар халкының мәдәни мирасына тартырга? Бу мәсьәләне чишкәндә өлкәннәрнең роле нинди? Өлкәннәрнең балалар белән үзара педагогик мөнәсәбәтләренең үсеш дәрәҗәсе нәрсәгә бәйле? Бу сорауларга тәртип белән җавап бирик.

Оешма белем бирү эшчәнлеген төбәк үзенчәлекләрен, һәр тәрбияләнүчесе үсешендәге социомәдәни ситуацияне, аның кыйммәтләрен, фикерләрен һәм шул фикерләрне белдерү ысулларын исәпкә алып оештырганда гына баланы татар халкы мәдәниятенә җәлеп итәргә мөмкин, шул ук вакытта әлеге аралашу вакытында өлкәннәр баланың омтылышларын хуплап һәм үстереп торучы партнёр ролендә булырга тиеш. Эшчәнлек процессына өлкәннәрнең һәм балаларның тигез хокукта кушылуы партнёрлык мөнәсәбәтләренең төп функциональ характеристикасы булып тора. Шул рәвешле, өлкән кеше, иң тәҗрибәле һәм компетентлы партнёр буларак, куелган максатка ирешүдә балалар белән тигез хокукта катнаша.

Буыннар арасында тыгыз бәйләнешләрне булдыру юнәлешендә белем бирүгә әйдәп баручы роль бирелә. Бу уртак хезмәттәшлекне, диалог һәм буыннар арасында аралашуны максатчан оештыруга теләк уята.


Татар халкы мәдәниятенә җәлеп итү процессын тәгәлләштерү өчен, баланың эшчәнлек субъекты булып җитешүенең һәр этабында аның өлкәннәр белән хезмәттәшлеге эчтәлеген ачарга кирәк. Бала тарафыннан культура нормаларын, эшчәнлек чараларын, ысулларын, үз-үзеңне тоту һәм аралашу үрнәкләрен үзләштерү, гаилә, җәмгыять, дәүләт традицияләренә җәлеп итү балачак үсешенең яңа социомәдәни ситуациясендә бара.

Өлкәннәрнең һәм балаларның роле, позицияләре эволюциясен хезмәттәшлек субъектлары үсеше логикасында күзәтергә мөмкин. 1 нче рәсемдә баланың, өлкәннәр белән аралашканда, иң элек милли мәдәният чараларына өйрәнүе, аннан соң аларны үзләштерүе һәм сеңдерүе, соңрак үзенең дә аларны иҗат итүе, ягъни иҗади эшчәнлек субъектына әйләнүе күрсәтелә.




1 нче рәсем. Баланы милли мәдәниятқә җәлеп итү стадияләре.

*Шартлы билгеләр:*



Шулай итеп, балаларның әйләнә-тирә дөнья объектлары һәм милли мәдәни кыйммәтләр белән үзара бәйләнеше вакытында өлкән кешенең турыдан-туры катнашында «җайлашу» ситуациясе баланың, өлкән кешенең һәм мәдәниятнең чагыштырмача аерымлыгына бәйле. Өлкәннәрнең роле баланың милли мәдәният чаралары белән бәйләнешен билгели торган педагогик хезмәттәшлекне оештырудан гыйбарәт. Өлкәннәрнең мондый позициясе баланың субъектлылыгын үстерүнең киләсе этабына күчүен тәэмин итәргә тиеш.

***Милли мәдәниятне өйрәнү*** этабы белем бирү мөнәсәбәтләренең барлык субъектларының (катнашучыларының) актив катнашында бара. Бу этапта мәдәниятkә туры килүчәнлек һәм регионализм принцибы гамәлгә ашырыла башлый, өлкәннәр һәм балалар арасында аерым, үзенчәлекле мөнәсәбәтләр урнаша. Милли мәдәниятнең килеп чыгышы турында мәгълүматны өлкәннәр баланың дөньяны аңлау дәрәҗәсен, сәләтләре, иҗади потенциалы үсешен исәпкә алып җиткерә, ә мәдәниятне үзләштерү педагогның компетентлылыгыннан тора.

***Милли мәдәниятне үзләштерү*** субъектлылыкка ирешелгән һәм ирешелә торган дәрәҗәне характерлый. Әлеге этапта милли мәдәниятне үзләштерү нәтиҗәләрен, баланың өлкәннәргә һәм мәдәниятнең үзенә карата мөнәсәбәте үзгәрүен ачык күзәтергә була. Өлкән кеше баланың потенциаль мөмкинлекләре диапазонына ориентлаша, бу баланың актуаль һәм иң якын үсеш зоналары арасындагы ераклыкның артуында чагылыш таба.

Мәктәпкәчә балачакның тәмамлануы этабында ***милли мәдәниятне сеңдерү*** мәдәни үрнәкләрнең репродукциясенә һәм аларны балалар эшчәнлегенең барлык төрләрендә куллана алу мөмкинлегенә бәйле. Әлеге этап баланың милли мәдәният чаралары белән турыдан-туры бәйләнеше белән характерлана, ә өлкәннәрнең роле балалар иҗатын ачу һәм актуальләштерү мөмкинлекләрен киңәйтү өчен шартлар тудыруда чагыла.

***Мәдәни иҗат*** бала үсешенең иң югары дәрәҗәсен характерлый. Ул милли мәдәниятне баета торган яңа чаралар уйлап табу белән бәйле. Өлкән кеше бу чорда баланың иҗади активлыгына төрлечә ярдәм итәргә, шул рәвешле аның мәдәни үсешенә һәм үз-үзен үстерүенә булышырга тиеш.

Педагогик хезмәттәшлек аралашуның диалогик характерын күздә тота. Өлкәннәр һәм балалар арасындагы үзара ышаныч баланың татар халкы мирасын ихластан кабул итүенә, мәдәни тәҗрибәне өйрәнүенә һәм баетуына, милли мәдәниятне, шул исәптән татар халкының телен үзләштерүенә ярдәм итә. Милли мәдәниятне сеңдерү, мәдәни иҗат процессларының тәгалләнүе балалар белән өлкәннәрнең педагогик хезмәттәшлегенең үсеш дәрәҗәсенә турыдан-туры бәйләнгән.

Шулай итеп, тәрбия һәм белем бирү татар телендә алып барыла торган балалар бакчасының эшчәнлеге Россия Федерациясендәге күпмилләтле халыкның тел мирасын саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелергә тиеш. Уртак җирлектә яшәүчеләр белән аралашыр өчен балаларга телләрне табигый тел мохитендә өйрәнү мөмкинлеге бирү актуаль. Аларны үзләштереп, бала башка телдә сөйләшү, башка мәдәният вәкиле булуның, шул ук вакытта туган телне яратуның һәм туган мәдәниятне дөньяга танытуның гадәти күренеш икәнен аңлый башлый, чөнки тәрбия процессы нигезендә конституцион, гомумкешелек һәм милли кыйммәтләр ята.

## 2.4. БАЛА ИНИЦИАТИВАСЫН ХУПЛАУНЫҢ ЫСУЛЛАРЫ ҺӘМ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

Педагогик сүзлектә «инициативалылык» актив һәм мөстәкыйль гамәлләргә сәләтле һәм хирыс булган шәхес үзенчәлеге буларак аңлатыла. Димәк, инициативалы шәхесне иҗтимагый яктан актив, җаваплы, җитәкче ролен үзенә алырга, куйган максатка мөстәкыйль ирешә алырга

сәләтле кеше буларак карарга мөмкин. Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандартының 2.11.1-6 пунктына таянып, бала инициативасының ысулларын һәм юнәлешләрен карап үтик.

Баланың инициативасын хуплау өчен, педагог бала мәнфәгатьләренә һәм өстенлекләренә нигезләнгән ирекле мөстәкыйль балалар эшчәнлеген бәяләргә тиеш. Тәрбия һәм белем бирү татар телендә булган төркем балаларында туган якны өйрәнү, татар халык уеннарын мавыгып уйнау, туган (татар) телдә аралашу, татар җырларын җырлау, бию, рәсем ясау, әвәләп ясау, уйлап чыгару, тикшеренү, конструкцияләү мөмкинлекләре барлыкка килү, мәктәпкәчә белем бирүнең соңгы этабында оптималь тәрбия һәм белем бирү шартларында бала эшчәнлегенең төрле төрләрендә мөстәкыйльлекнең ачык чагылган күрсәткечләрен тәэмин итәргә юл ача. Күрсәткечләр сыйфаты булып түбәндәгеләр тора: өлкәннәр ярдәменнән башка куелган бурычларны чишәргә омтылу, эшчәнлекнең максатын билгели белү, эш-гамәлләрнең барышын һәрьяклап уйлау, чараларны сайлап ала, алдан уйлаганны тормышка ашыра белү һәм куелган максатка ярашлы адекват нәтиҗәгә ирешү. Моннан тыш, килеп чыккан бурычларны чишүдә инициатива һәм иҗат чагылышына сәләт барлыкка килә. Балаларның ирекле мөстәкыйль эшчәнлеген оештыруда режим моментлары иң кулай вакыт булып тора.

Иң кечкенә яшьтәге төркемнәрдә инициативаның өстенлекле өлкәсе булып предметлы манипулятив эшчәнлек тора. Шуңа күрә педагогка баланың предметлар өлкәсен киңәйтергә, аларның төрлелеген тәэмин итәргә, баланың мөстәкыйль эш-гамәлләрен хупларга, ирешкән нәтиҗәләренә аның белән бергә шатланырга кирәк.

Мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең кечкенәләр төркемендә инициативаның өстенлекле өлкәсе булып әйләнә-тирә дөньяны танып белү, кызыксындыручы гамәлләрне, мәгълүматларны белергә омтылу тора. Шуңа күрә бала өлкәннәргә түбәндәге сораулар бирә: «Бу нәрсә?», «Бу кем?», «Кайда?», «Ник?», «Нигә?». Ләкин бала бу сорауларны теләсә кемгә түгел, ә бары тик ышанычын яулаган кешеләргә генә бирә. Баланың бу омтылышын хупларга, танып белү активлыгын бәяләргә, баланың күзәтү, предметларны чагыштыру, аларның үзенчәлекләрен һәм сыйфатларын тикшерергә омтылышын үстерүгә юнәлтелгән ысуллар куллану мөһим. Педагогка баланы барлыкка килгән проблемаларны мөстәкыйль чишү юлларын эзләргә этәргеч бирә торган ситуацияләр тудырырга, эшчәнлекле сынаулар уздырырга кирәк.

Уртанчылар төркемендә инициативаның өстенлекле өлкәсе булып бала эшчәнлеге һәм тормышының барлык өлкәләрендә активлык чагылышы тора. Шуңа күрә баланың һәрвакытта да мөстәкыйль эшчәнлекне сайлап алу мөмкинлеге булырга, атрибутлар һәм җиһазлар мөмкин кадәр төрле һәм даими рәвештә алышынып торырга тиеш (якынча ике айга бер тапкыр). Педагог балалар тормышын алар үзләштергән алымнарны мөстәкыйль куллану таләп ителгән проблемалы гамәли һәм танып белү ситуацияләре белән баетырга, бала сорауларына игътибар белән карарга, фикер алышуда партнёр булырга кирәк. Балаларга эшнең командалы формаларында дустанә мөнәсәбәт тәҗрибәсе туплый ала торган шартлар тудыру зарур. Планлаштырылган мондый эшчәнлек балада мөстәкыйльлек тәрбияләргә һәм үз-үзенә ышаныч булдырырга ярдәм итә.

Мәктәпкәчә яшьтәге зурлар төркемендә инициативаның өстенлекле өлкәсе булып өлкәннәр тарафыннан танылу һәм үз-үзенә ышанганлыкка ихтыяҗ туу тора. Шуңа күрә педагогка баланың мөстәкыйльлеген, инициативасын, иҗатын үстерә торган шартларга игътибар итәргә кирәк. Моның өчен педагог балада алган белем һәм күнекмәләрен проблемаларны мөстәкыйль чишү өчен кулланырга теләк тууны активлаштыра торган ситуацияләр булдырырга тиеш. Әгәр дә бала таныш булмаган ситуациядә таныш проблемаларны чишүдә авырлык тоя икән, юнәлтеп җибәрә торган махсус сораулар бирү алымын кулланырга, шуңа охшашлы проблемаларны ничек хәл итүен исенә төшерергә мөмкинлек бирергә, аны килеп туган авырлыкларны җиңүдә яңа иҗади чишелешләр эзләргә этәрергә кирәк. Балалар бакчасында булган вакытта көн дәвамында ярдәм һәм мактау алымнарын кулланып, балада инициатива чагылышын хупларга кирәк.

Һәр яшь төркемендә баланың инициативалылыгын тәэмин итә торган үстерешле предметлы тирәлек мохитен баетуга аеруча игътибар итәргә кирәк. Яңа яисә күптән онытылган предметлар пәйда булу танып белү активлыгы туугa этәрә. Бу яңа уеннар һәм уенчыклар, иллюстрацияле китаплар, гадәти булмаган конструкторлар, фотосурәтләр, борынгы заман предметлары, таныш булмаган җайланма детальләре, тәҗрибә һәм экспериментлар уздыру өчен материаллар булырга мөмкин. Әлеге предметларның серлелеге балаларны гаҗәпләндерергә, кызыксындырырга юл ача, аларга фикер йөртергә, фаразларга, тыңларга, үз фикерләрен дәлилләргә, яңалыкны ачу куанычын тоярга булыша.

## 2.5. ПЕДАГОГИК КОЛЛЕКТИВНЫҢ ТӘРБИЯЛӘНҮЧЕЛӘР ГАИЛӘЛӘРЕ БЕЛӘН ҮЗАРА ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Бала һәм аның үсеше Оешма һәм ата-аналар (законлы вәкилләр) арасындагы хезмәттәшлекнең иң югары максаты һәм төп эчтәлеге булырга тиеш.

Хезмәттәшлек стратегиясе ата-аналарны (законлы вәкилләрне), кыйммәтле социомәдәни тәҗрибәгә ия кешеләр буларак, турыдан-туры җәлеп итүне күздә тота. Гаиләнең бала өчен беренчел социальләшү урыны гына булмыйча, белем бирү процессында да мөһим роль уйнавы һәркемгә мәгълүм. Нәкъ менә гаиләдә бала социаль мөнәсәбәтләрнең тәүге тәҗрибәсен ала, рухи кыйммәтләрне, кагыйдә һәм нормаларны үзләштерә, сөйләмен үстерә, беренчел белем һәм күнекмәләргә өйрәнә.

Хезмәттәшлек ата-аналарны (законлы вәкилләрне) Оешманың белем бирү процессына турыдан-туры, шул исәптән белем бирү инициативаларына булган ихтыяҗларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү нигезендә уртак белем бирү проектларын булдыру юлы белән дә җәлеп итүне күздә тота. Шуңа күрә белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар белем бирү проектларын гамәлгә ашыруда инициатива күрсәтә, милли уен вариантларын арттыра, Сабан туе бәйрәменә мәйданны бизәү, үзара хезмәттәшлекнең иң нәтиҗәле формалары һәм башкалар турында фикер алыша ала.

Гаилә туган тел һәм мәдәниятнең беренчел институты булып тора, ул мәктәпкәчә яшьтәге баланың белем алуына, социальләшүенә, шәхси үсешенә зур йогынты ясый. Шуңа күрә төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы тәрбиячеләргә үз эшләрендә гаиләнең тормыш шартлары, аның милли составы, кыйммәтләре һәм гореф-гадәтләре, телне белү дәрәҗәсе кебек факторларны исәпкә алырга, шулай ук тәрбия һәм белем бирү мәсьәләләрендә ата-аналарның сәләтләрен һәм казанышларын танырга һәм хөрмәт итә белергә кирәк.

Оешманың гаилә белән тыгыз хезмәттәшлеге уртак эшчәнлекне тагын да уңышлырак итә. Тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән аралашуның заманча формалары (мәгълүмати-аналитик, танып белү, ял итү, язма, күрсәтмә мәгълүмат) ата-аналар һәм педагогик коллективның балаларны тәрбияләү, сәламәтләндерү һәм үстерүгә юнәлтелгән гамәлләрен координацияләргә булышачак (2 нче таблицаны карагыз). Педагоглар һәм ата-аналар арасында мәгълүмат алмашу ике якның да партнёрлык мөнәсәбәтләренең, ышанычлы хезмәттәшлекнең нигезе булып тора.

Икетеллелекне булдыру һәм формалаштыру эшендә гаилә белән хезмәттәшлек баланың тулы үсешен тәэмин итү өчен алшарт булып тора. Ике телне иртә яки мәктәпкәчә балачакта үзләштерүчеләр математиканы, чит телләрне җиңелрәк, әйбәтрәк өйрәнә, киләчәктә уңышка ирешә, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә җайлаша, конкурентлыкка сәләтле була.

Мәктәпкәчә белем бирү системасында партнёрлык ике якның да мөнәсәбәтләре ике телне дә белүче балаларны үстерү өчен уртак җаваплылык нигезендә төзелүен аңлата. Партнёрлык

гаилә һәм Оешма тигез хокуклы булуын, аларның бер үк максатка – берничә телне белүче, уңышка ирешергә әзер сәламәт бала тәрбияләргә омтылуын күздә тота һәм моңа ирешү өчен хезмәттәшлек итә.

Баланың үз-үзен тотышында тайпылышлар яки сөйләм үсешендә проблемалар булган очракта, тәрбияче белән гаилә арасындагы диалог аеруча мөһим. Диалог баланың үз-үзен тотышын яки тел проблемаларын бергәләп анализларга, аларның сәбәпләрен, аларны хәл итү ысулларын ачыкларга мөмкинлек бирә. Диалогта ата-аналарга баланың сөйләмен үстерүнең индивидуаль юнәлешен гамәлгә ашыру буенча консультация бирелә. Әйтик, татар телен яхшы белгән ата-аналарга бала белән ешрак сөйләшергә, сүзне интонация белән баетырга, сүзлек запасын әкренләп тирәнәйтергә киңәш ителә. Бер үк сүзне төрле контекстларда кулланырга, ситуацияне аңлатырга һәм бала өчен яңа булган бар нәрсәне атарга, яңа сүзләрнең мәгънәсен ачыкларга кирәк.

Бала янында аралашу өчен төрле яшьтәге кешеләрнең (өлкәнрәк ир-ат һәм хатын-кыз, үзеннән кечерәк яки олырак балалар) булуы, аерым авазларның әйтелеш үзенчәлекләре, төрле интонация, тембрлар белән танышу мөмкинлеге мөһим фактор булып тора. Ә сөйләм үсешенең нәтиҗәлелеге өчен татар телендә эшли торган «Шаян ТВ» балалар телеканалын, «Яшь ТНВ» телеканалы кысаларында нәниләр өчен чыга торган «Күчтәнәч» программасын, аудиоязмалар, инновацион китаплар, балалар спектакльләрен, «Татармультфильм» берләшмәсенең мульт-фильмнарын һ.б. шундый өстәмә чараларны кулланырга тәкъдим итәргә кирәк. Стеналарга текстлы аңлатмалары белән мавыктыргыч рәсемле плакатлар эләргә мөмкин.

Шул ук вакытта баланы бер үк мультфильм, бер үк уеннар, бер үк китапны күп тапкырлар уку белән ялыктырырга ярамый.

Бала туган телдә әйтелгән сүзгә русча җавап бирә икән, бу җөмләне кабатларга һәм татарча җавап алырга кирәк. Телләрне бутап сөйләшүгә юл куярга ярамый. Бала сүзендәге хаталарны, дөрес әйтмәгәнне үзгәртеп, йомшак кына, табигый рәвештә төзәтергә кирәк.

Сөйләм телен үстерү өчен, галимнәр ата-аналарга бала белән аралашуга көненә 15 минут-тан да ким булмаган вакыт бүләргә киңәш бирәләр. Әмма бу аралашу кызыклы, мавыктыргыч булырга, яңа белем бирергә тиеш. Китап уку, ике телдә мультфильмнар карау һәм алар буенча фикер алышу, өй театры, рольле яки режиссёрлык уены, фотосурәтләр, рәсемнәр карау, алар буенча сөйләшү яисә күчермәсен ясау файдалы булачак. Нәкъ менә балалар эшчәнлегенең махсус төрләрен сөйләм белән бергә башкару, ата-аналарның балалар белән аралашуы тел байлыгын арттыра, сөйләмне камилләштерә.

Янәшә яшәгән халыкларның тел һәм мәдәниятен кабул итмәүнең тискәре моментларыннан сакланырга кирәк. Үзләренә аңлашылмаган телдә сөйләшүне мыскыл итү дип санаучы һәм тәрҗемә таләп итүче ата-аналарны игътибардан читтә калдырырга ярамый. Мондый ата-аналар, бала чакта бер – туган тел генә булырга тиеш, ә икенчесе беренчесен үзләштергәннән соң өйрәнелә ала, дип ялгыш фикер йөртә. Мондый ата-аналарга икетелле тәрбиянең әһәмиятен аңлатырга, «бала вакытта өйрәнелгән телнең дә туган тел закончалыклары буенча үзләштерелүенә һәм шулай ук кешедә «тирән утыруына» төшендерергә кирәк. Ул мәктәптә уку процессында өйрәнгәненә караганда камилрәк була» (Е.Ю. Протасова, Н.М. Родина).

Ата-аналар ягыннан икетеллелеккә мөнәсәбәт уңай булырга тиеш. Балаларының туган (татар) телен белүе чикле булса да, аның татарча сөйләшүе шатлык булуын төрле яклап күрсәтер-гә кирәк. Шул ук вакытта алар баланың коммуникатив сәләтләрен үстерүгә, сөйләм телен бозуларны кисәтүгә зур игътибар бирергә тиеш. Ә тәрбияченең гаиләгә сөйләм культурасын тәрбияләү мәсьәләләрендә ярдәм итүе зарур.

Ата-аналар белән диалог белем бирү мөнәсәбәтләрен җайга салу, шулай ук белем бирү эшчәнлеген планлаштыру өчен кирәк. Педагогларга ышанып тапшырылган тәрбияләнүчеләренең гаиләләрендәге яшәү рәвешен белү балаларга татар халкының мәдәни мирасын тапшыруда белем бирүгә бәйле бурычларны нәтиҗәле хәл итәргә мөмкинлек тудыра. Педагоглар ата-аналар белән тел үзләштерүдәге уңышлар турында гына түгел, ә баланың тарихка, мәдәни традицияләргә, туган як табигатенә карата кызыксыну белдерүе турында да мәгълүмат белән уртаклашырга тиеш. Мондый шартларда ситуатив хезмәттәшлек чын партнёрлыкка әйләнергә мөмкин.

Оешма ата-аналарга белем бирү процессында актив катнашырга тәкъдим итә, ә ата-аналар курчак театрына, күренекле сәнгать эшлеклеләре музейларына (Г. Тукай, С. Сәйдәшев, М. Җәлил), халык җырларын, «Созвездие-Йолдызлык» конкурсы финалистларының гала-концертын тыңларга мөмкинлек биргән концертларга баруны оештыруда, шулай ук балалар белән шәһәр буйлап экскурсияләргә чыгуда һ.б. ярдәм күрсәтә ала.

Уртак проект эшчәнлеге ата-аналарны җәлеп итү өчен яхшы мөмкинлекләр бирә. Ата-аналар проектларны тормышка ашыруда катнашырга хокуклы. Алар Сабан туе, Нәүрүз кебек милли бәйрәмнәрдә, Халыкара туган тел бәйрәмендә, театр актёрлары, балалар китаплары авторлары, мультипликацион фильмнарны төшерүчеләр белән очрашуларда катнаша, Оешманың китапханә фондын һәм китапханәсен баетуга өлеш кертә ала.

Оешма тарафыннан ата-аналарның (законлы вәкилләренең) социаль челтәрләрдә үзара аралашуы хуплана: мәгълүмат алмашу, баланың әхлакый сыйфатларын һәм патриотик хисләрен тәрбияләү буенча тәҗрибә уртаклашу, балаларның милли мәдәниятка, билингвизм проблемаларына карата кызыксынуларына булышу мәсьәләләрендә фикер алыша ала. Бары тик гаилә белән тыгыз хезмәттәшлектә эшләү генә гаиләдә икетеллелекне уңышлы һәм перспективалы, ә Оешма эшчәнлеген нәтиҗәле һәм сыйфатлы итә.



*2 нче таблица*

| Мәгълүмати-аналитик формалар | |
|---|---|
| Хезмәттәшлекнең мәгълүмати-аналитик формалары алга таба мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен тәрбияләнүченең гаиләсе: ата-ананың социаль хәле, психологик-педагогик компетентлык дәрәҗәсе, гаилә мәнфәгатьләре, кыйммәтләре, яшәү шартлары турында мәгълүмат җыю һәм эшкәртүне гамәлгә ашырырга тиеш. Бары тик аналитика нигезендә генә балага карата шәхси-ориентлашкан тәрбия ысулын куллану, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар белән эшлекле аралашу мөмкинлегенә ирешергә була. Ата-аналар белән хезмәттәшлек итү формасына анкета тутыру, интервью бирү, сорау-җавап, әңгәмә, күзәтүләрне кертергә мөмкин | |
| Анкета тутыру | Ата-ананың белем алудагы ихтыяҗын ачыклау, гаилә әгъзалары белән элемтә урнаштыру, балага карата кулланылачак тәрбия чараларын яраштыру, гаиләне өйрәнү максаты белән балалар бакчасы хезмәткәрләре тарафыннан киң кулланыла торган диагностика алымнарының берсе |
| Сорау-җавап | Беренчел мәгълүмат җыю методы, ул тикшерүченең һәм сорауга җавап бирүченең турыдан-туры (әңгәмә, интервью) яки турыдан-туры булмаган (анкета) социаль-психологик бәйләнешенә нигезләнгән. Бу очракта сүз яки язма фикер мәгълүмат чыганагы булып тора |
| Интервью һәм әңгәмә | Сорауга җавап бирүче тарафыннан әйтелгән мәгълүматны алырга мөмкинлек бирә. Бу үз-үзеңне тоту мотивларын, ниятләрне, фикерләрне (башка ысуллар белән өйрәнеп булмаган нәрсәләрне) өйрәнергә булыша, мондый методларны субъектив методларга әйләндерә |
| **Танып белү формалары** | |
| Хезмәттәшлекнең танып белү формалары ата-ананың психологик-педагогик компетентлыгын арттыруга юнәлдерелгән, ата-ананың гаиләдә бала тәрбияләүгә карашларын үзгәртергә сәләтле. Моннан тыш, әлеге хезмәттәшлек формалары баланың яшь һәм индивидуаль үсеш үзенчәлекләре белән, тиешле күнекмәләрне формалаштыруның рациональ методлары һәм тәрбия алымнары белән таныштырырга мөмкинлек бирә | |
| Практикум | Ата-анада баланы тәрбияләүгә, педагогик ситуацияләрне хәл итүгә, педагогик осталык формалаштыру һәм үстерүгә юнәлдерелгән, педагогик фикер йөртүләрен үзенә бер төрле үстерү максатыннан үткәрелә торган гамәли шөгыль |
| Лекция | Гаилә тәрбиясенә хас теге яки бу проблеманың асылын ача торган психологик-педагогик агарту формасы |
| Дискуссия (Бәхәсләр) | Тәрбия проблемалары буенча фикер алышу. Ата-ананың психологик-педагогик компетентлылык дәрәҗәсен күтәрүнең бер формасы. Ул мәктәпкәчә тәрбиянең актуаль проблемалары турында фикер алышуга җәлеп итәргә, тупланган тәҗрибәгә таянып, факт һәм күренешләрне анализларга мөмкинлек бирә |

| | |
|---|---|
| Түгәрәк өстәл | Әлеге форманың үзенчәлеге шунда: һәркемнең тигез хокуклылыгы шартларында белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар үзара фикер алыша |
| Симпозиум | Проблеманы хәл итү барышында катнашучылар әлеге проблема буенча чыгыш ясый, аннан соң бирелгән сорауларга җавап бирә |
| Дебатлар | Бер-берсенә каршы торучы, көндәшлек итүче як вәкилләре тарафыннан алдан әзерләнгән чыгышлар формасында фикер алышу |
| Ата-аналар катнашындагы педагогик совет | Советның төп максаты – ата-ананы мәктәпкәчә белем бирү системасындагы проблемалар турында актив фикер алышуга җәлеп итү |
| Педагогик лаборатория | Ата-аналарның төрле чараларда катнашуының нәтиҗәлелеге турында фикер алышуны күздә тота |
| Ата-аналар конференциясе, шул исәптән коммуникатив платформада | Мәктәпкәчә белем бирүнең актуаль проблемалары буенча ата-аналарның психологик-педагогик компетентлылыгын арттыруда нигез булып тора. Бу форманың әһәмияте шунда: анда ата-аналар һәм педагоглар гына түгел, җәмәгатьчелек тә катнаша |
| Гомуми ата-аналар җыелышы, шул исәптән коммуникатив платформада | Җыелышның төп максаты – балаларны тәрбияләү, белем бирү һәм үстерү мәсьәләләре буенча ата-аналар җәмәгатьчелеге һәм педагогик коллективның гамәлләрен координацияләү |
| Төркемле ата-аналар җыелышы, шул исәптән коммуникатив платформада | Тәрбиячеләрнең ата-аналар коллективы белән хезмәттәшлегенең нәтиҗәле формасы, балалар бакчасы һәм өй шартларында һәр яшькә караган этапта белем бирү бурычлары һәм эчтәлеге белән танышу формасы, гаилә тәрбиясе тәҗрибәсе белән уртаклашу формасы |
| Аукцион | Алга куелган проблема буенча файдалы киңәшләр «сату» рәвешендәге уен формасында уткәрелә торган җыелыш |
| Сораулар һәм җаваплар кичәсе | Ата-аналарга киләчәктә эш-гамәлләрдә куллану максатыннан педагогик белемнәрне төгәлләштерергә, яңаларын белергә, балалар үсешенең кайбер физик һәм психик проблемалары турында фикер алышырга мөмкинлек бирә |
| Ата-аналар кичәләре | Ата-аналар коллективын берләштерүнең яхшы ысулы. Бу аралашу бәйрәмнәре, хатирәләрне уртаклашу кичәләре, проблемаларны хәл итү юлларын бергәләп эзләү, сорауларга җаваплар алу булырга мөмкин |
| Ата-аналар укулары | Ата-аналарга мәктәпкәчә тәрбиянең актуаль проблемалары буенча лекцияләр тыңларга, алар турында фикер алышуларда катнашырга мөмкинлек бирә |
| Ата-аналар өчен тренинг | Баласына карата үз мөнәсәбәтен үзгәртергә, үзара мөнәсәбәтләрне ачыграк, ышанычлырак итәргә теләгән ата-аналар белән эшләүнең актив формасы |

| | |
|---|---|
| Педагогик әңгәмә | Күтәрелгән тема буенча бердәм нәтиҗәгә ирешү өчен, тәрбия мәсьәләләре буенча фикер алышу, ата-аналарга вакытында ярдәм күрсәтү формасы |
| Гаиләнең кунак бүлмәсе | Бала – ата-ана мөнәсәбәтләрен оптимальләштерү максатыннан ата-аналар һәм балалар коллективын берләштерү өчен үткәрелә; ата-ана һәм бала арасында эмоциональ бәйләнешне арттыра |
| Ата-аналар клублары | Педагоглар (белгечләр) һәм ата-аналар арасында бала тәрбияләүдә гаиләнең әһәмиятен аңлауга ярдәм итә торган ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштыруны, шулай ук ата-аналар тарафыннан педагогларның (белгечләрнең) компетентлылыгы бала тәрбияләү һәм аның индивидуаль үсеше мәсьәләләренә караган бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирәчәген аңлауны күздә тота |
| Игелекле эшләр көннәре | Ата-аналар тарафыннан балалар бакчасына ирекле рәвештә кулдан килгәнчә булышу, балалар өчен үстерешле предметлы мохит булдыруга ярдәм итү көннәре |
| Ачык ишекләр көне | Ата-аналарны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары, традицияләре, кагыйдәләре, үзенчәлекләре белән таныштыру аларны әлеге эшчәнлектә катнашуга җәлеп итү мөмкинлеге бирә |
| Ачык ишекләр атнасы | Атна дәвамында ата-аналар уртак һәм мөстәкыйль эшчәнлекне оештыруны, баланың педагог һәм яшьтәшләре белән аралашуын күзәтә, баланың мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын тирәнрәк аңлый ала |
| Таныштыру көннәре | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрмәгән балаларның ата-аналары өчен үткәрелә |
| Бакчага барып килүләр | Ата-аналар алдында өйдәгедән аерылып торган шартларда конкрет педагогик бурычлар куюны күздә тота: балаларның турыдан-туры белем бирү эшчәнлегендәге активлыгын, баланың уенда үз-үзен тотышын, яшьтәшләре белән аралашуын күзәтү |
| Тикшеренү-проектлы, рольле, имитацияле һәм эшлекле уеннар | Уенда катнашучылар, аерым бер белемне генә сеңдереп калмыйча, вазгыятьне анализлый, үзара мөнәсәбәтләрнең, педагогик гамәлләрнең яңа моделен кора |
| **Күңел ачу формалары** | |
| Үзара бәйләнешнең күңел ачу формалары белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында җылы, формаль булмаган мөнәсәбәтләр урнаштыруны күздә тота | |
| Бәйрәмнәр, бәйрәм иртәләре, концертлар, ярышлар һ.б. | Төркемдә эмоциональ комфорт тудырырга, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларны бер-берсенә якынайтырга булыша |
| Ата-аналар һәм балаларның кул эшләре күргәзмәсе, гаилә вернисажлары | Ата-аналар һәм балаларның уртак эшчәнлеге нәтиҗәләрен күрсәтә |

| | |
|---|---|
| Бергәләп походлар һәм экскурсияләргә бару | Бала белән ата-ана мөнәсәбәтләрен ныгыта |
| **Язма формалар** | |
| Атналык язмалар | Ата-аналарга адресланган язу баланың сәламәтлеге, аның кәефе, тәртибе, балалар белән үзара мөнәсәбәте, яраткан шөгыле һ.б. турында хәбәр итә |
| Формаль булмаган язмалар | Тәрбиячеләр бала аша аның яңа уңышы турында мәгълүмат, күрсәтелгән ярдәм өчен гаилә әгъзаларына рәхмәт сүзләре белдерелгән кыска язулар җибәрә, шулай ук ата-аналар да балалар бакчасына үтенеч яисә рәхмәт белдерелгән язулар җибәрә ала |
| Шәхси блокнотлар | Өйдә һәм балалар бакчасында барган хәлләр турында мәгълүмат белән уртаклашу өчен, көн саен балалар бакчасы белән гаилә арасында йөри ала. Шул рәвешле тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары тәрбиячеләргә телефон номеры, йорт адресы, эш урыны алышынуы, булачак ял һ.б. турында хәбәр итә ала |
| Бала үсеше турында язма хисап | Бу форма шәхси элемтәләрне алыштырмаган шартларда гына файдалы була ала |
| **Күрсәтмә-мәгълүмати формалар** | |
| Әлеге хезмәттәшлек формалары ата-аналарны балалар бакчасындагы тәрбия шартлары, эчтәлеге һәм методлары белән таныштыру мәсьәләләрен хәл итә, педагоглар эшчәнлеген дөрес бәяләргә, гаилә тәрбиясе проблемаларын яңадан карарга, тәрбиченең эшчәнлеген объектив бәяләргә мөмкинлек бирә | |
| Мәгълүмати танышу | Белем бирү эшчәнлеген оештыру шартлары, кадрлар составы, программа, ата-аналарның Интернет челтәрендәге фикерләре, массакүләм мәгълүмат чараларында реклама, мәгълүмат проспектлары, видеофильмнар белән таныштыруга юнәлдерелгән |
| Мәгълүмати агарту | Үзара хезмәттәшлекнең гаммәви мәгълүмат чаралары аша, тематик күргәзмәләр ясау, стенд, фотокүргәзмә, видеороликлардагы мәгълүмат һ.б. аша оештырылган, ягъни турыдан-туры булмаган формаларына юнәлдерелгән |

# 3. ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ

## 3.1. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ ПСИХОЛОГИК-ПЕДАГОГИК ШАРТЛАРЫ

Программа индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләренә ярашлы рәвештә баланың үсешен тәэмин итә торган психологик-педагогик шартлар булдыруны, башка балалар, өлкәннәр һәм әйләнә-тирә дөнья белән мөнәсәбәтләр субъекты буларак, һәр баланың сәләтен һәм иҗади потенциалын үстерүне күздә тота.

- Өлкәннәр һәм балалар арасында **шәхси-яңалык тудыру хезмәттәшлеге,** бу очракта һәр балага эшчәнлек төрләрен, партнёрны, аның белән аралашачак телне, милли мәдәният чараларын һ.б. сайлау мөмкинлеге бирелә торган ситуацияләрне тудыру күздә тотыла; туган як тарихын, мәдәниятен, табигатен танып белү өлкәсендә яңа белемнәр үзләштергәндә, баланың шәхси тәҗрибәсенә таяну тәэмин ителә.
- **Бала уңышлылыгының чагыштырма күрсәткечләренә,** ягъни баланың хәзерге һәм алдагы казанышларын чагыштыруга, уңай үзбәя бирүне, үз мөмкинлекләренә һәм сәләтләренә ышанычны стимуллаштыруга **юнәлгәнлек.**
- **Уенны** бала үсешенең иң мөһим факторы буларак **формалаштыру.** Өлкәннәр тарафыннан балаларның бер-берсенә карата уңай, дусларча мөнәсәбәтенә һәм балаларның уен эшчәнлегендә үзара аралашуларына ярдәм итү.
- Баланың социаль-коммуникатив, танып белү, сөйләм, сәнгати-эстетик һәм физик үсешенә, аның индивидуальлеген саклауга, мөстәкыйльлегенә һәм инициативасына ярдәм итә торган **үстерешле белем бирү мохитен булдыру.**
- Балачак үсешенең социаль вазгыятен исәпкә ала торган **белем бирү эшчәнлеген** республиканың ике дәүләт телендә – татар һәм рус телләрендә төзү. Эшчәнлекне, уртак эшчәнлектә катнашучыларны, матди чараларны балаларның ирекле сайлавы өчен шартлар тудыру. Белем бирү эшчәнлегендә балаларның индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләренә туры килә торган үстереш чараларын, эш формаларын һәм методларын куллану.
- **Репродуктив** (әзер үрнәкне яңадан җитештерүче) һәм **продуктив** (субъектив яңа продукт җитештерүче) эшчәнлекләрнең, ягъни мәдәни формаларны һәм үрнәкләрне үзләштерү **эшчәнлегенең**, шулай ук балалар оештырган тикшеренү һәм/яки иҗат эшчәнлегенең, уртак һәм мөстәкыйль, хәрәкәтчән һәм статик активлык формаларының **тигезлек хәлендә булуы.**
- Мәктәпкәчә яшьтәге баланың **тулы үсеше** өчен тиешле шарт буларак, **гаиләнең катнашуы.** Балаларны тәрбияләүдә, аларның сәламәтлеген саклауда һәм ныгытуда ата-аналарга (законлы вәкилләргә) ярдәм итү, гаиләләрне Оешманың белем бирү процессына җәлеп итү.
- **Педагогларның** профессиональ компетентлылыгын, шул исәптән коммуникатив күнекмәләрен үстерүгә, татар (рус) теле буенча белемнәрен ныгытуга һәм балага телне өйрәтү осталыгын камилләштерүгә юнәлдерелгән **профессиональ үсеше.** Интернеттан куркынычсыз файдалану кагыйдәләренә ия булуны, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның Интернет челтәрендә хезмәттәшлек урнаштыруны күздә тота.

## 3.2. ҮСТЕРЕШЛЕ ПРЕДМЕТЛЫ ТИРӘЛЕК ҺӘМ ЦИФРЛЫ МОХИТНЕ ОЕШТЫРУНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Оешмада үстерешле предметлы тирәлекне оештыруга карата кырыс таләпләр куймый торган Программаны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә тиеш. Оешмага Программаның максатлары, бурычлары һәм принциплары нигезендә үстерешле предметлы тирәлекне мөстәкыйль проектлау хокукы бирелә. Оешманың үстерешле предметлы тирәлеген проектлаганда, балалар үсешенең этномәдәни вазгыяте исәпкә алынырга тиеш.

Мәгълүмати социальләштерү үзенчәлеген, балаларның яшь, милли һәм гендер үзенчәлекләрен исәпкә алган очракта, үстерешле предметлы тирәлекне булдыруның төрле вариантлары булырга мөмкин. Ул үстерү мохите генә түгел, үзе дә үсештәге мохит булырга тиеш.

Оешманың предметлы тирәлеге балалар активлыгының төрле төрләрен тормышка ашыру мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш: хәрәкәт (төбәк традицияләре исәпкә алынган активлык формаларын да кертеп), уен (халык хәрәкәтле уеннары, әйлән-бәйлән уены), коммуникатив (татар һәм рус телләрендә аралашу), танып белү-тикшеренү (туган як тарихын, мәдәни байлыкларын, туган як табигатен өйрәнү һәм тикшерү), балалар матур әдәбиятын, халык авыз иҗатын, сурәтләү сәнгатен үзләштерү (татар декоратив-гамәли сәнгатен, конструкторлаштыруны кертеп), музыка иҗаты (татар композиторларының музыкаль әсәрләрен кабул итү һәм мәгънәсен аңлау, татар җырларын җырлау, татар биюләрен башкару, халык музыка уен коралларында уйнау).

Бала өчен Оешмадагы инфраструктура объектларын, шулай ук балалар активлыгының төп төрләрен тәэмин итә торган уеннарны, уенчыкларны, материалларны, әсбапларны куркынычсыз һәм тоткарлыксыз куллану мөмкинлеге тудырылырга тиеш.

Үстерешле предметлы тирәлекне проектлаганда, Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартында каралган белем бирү өлкәләрендә (иҗтимагый-коммуникатив, танып белү, сөйләм, сәнгати-эстетик һәм физик үсеш) белем бирү процессының бөтенлеге исәпкә алынырга тиеш (3 нче таблица).

Әйтик, *иҗтимагый-коммуникатив өлкәдә* белем бирү эшчәнлеген тәэмин итү өчен түбәндәгеләр таләп ителә:

– төркемдә һәм белем бирү эшчәнлеге өчен билгеләнгән урыннарда (музыка, спорт залларында, сөйләм телен үстерү кабинетында, рәсем студиясендә һ.б.) балага өлкәннәр белән дә, башка төркемгә йөрүче яшьтәшләре белән дә аралашу һәм уртак эшчәнлек өчен шартлар тудырыла. Балалар уен һәм шөгыльләргә үз төркемнәре белән җыелырга, шулай ук, үз мәнфәгатьләренә карап, кечерәк төркемнәргә дә берләшә алырга тиеш. «Изучаем русский язык» УМК проектын гамәлгә ашыру өчен, мөмкинлек булганда, янәшә территориядә төрле яшьтәге балалардан торган зур (кечкенә) төркемнәр белән өлкәннәрнең аралашуы һәм уртак эшчәнлеге өчен зона булдырыла ала;

– Оешманың предмет тирәлеге балаларның *уен эшчәнлеген үстерү шартларын тәэмин итәргә* тиеш. Моның өчен төркем бүлмәләрендә һәм аның янәшәсендәге территорияләрдә пространство төрле уеннар, шул исәптән сюжетлы-рольлеләрен уйнау мөмкин булырлык итеп оештырылырга тиеш. Төркем бүлмәләрендә һәм аның янәшәсендәге территорияләрдә җиһазлар, уенчыклар (шул исәптән халык уенчыклары), төрле дидактик, режиссёрлык, сюжетлы-рольле уен материаллары, шулай ук шартлы алмаш предметлар булырга тиеш;

– Оешманың предмет тирәлеге балаларның *танып белү һәм тикшеренү үсеше шартларын тәэмин итәргә* тиеш. Моның өчен Оешмада балаларның танып белү һәм тикшеренү эшчәнлегенең төрле төрләре өчен җиһазлар һәм мәгълүмат ресурслары, приборлар һәм

материаллар белән җиһазландырылган урыннар яки зоналар булырга тиеш, ягъни тәҗрибәләр һәм экспериментлар үткәрү өчен лаборатория, китап почмагы, китапханә, кышкы бакча, яшелчә бакчасы, тере почмак һ.б.;

– предметлы тирәлек балаларның *сәнгати-эстетик үсеше шартларын тәэмин итәргә* тиеш. Оешманың һәм аның янындагы территорияләрнең бүлмәләре эстетик яктан зәвыклы итеп бизәлергә тиеш, балаларның рәсем ясау, музыка, театр эшчәнлеге өчен җиһазлар һәм материаллар белән тәэмин ителгән зоналарны алдан әзерләп куярга кирәк;

– предметлы тирәлек балалар организмын *физик яктан үстерү һәм савыктыру шартларын тәэмин итәргә* тиеш. Оешманың һәм аның янындагы территорияләрнең бүлмәләрен балаларның физик активлыгы, авыруларны кисәтү һәм баланы савыктыру өчен җиһазлар һәм чаралар белән тәэмин итәргә кирәк.

Оешмада *белем бирү процессын мәгълүматлаштыру өчен* шартлар тудырылырга тиеш. **«Куаныч» программасының иң мөһим өлеше – www.куаныч.рф. порталы.** Портал Программаны гамәлгә ашыруда төп рольне уйный, ул күпфункцияле һәм түбәндәгеләрне эшләргә мөмкинлек бирә:

– мәктәпкәчә белем бирү оешмасы педагогының (яисә белгеченең) шәхси кабинетын булдырырга;

– тәҗрибәле педагоглар, методистлар, югары уку йорты мөгаллимнәре тарафыннан эшләнгән шөгыль, бәйрәм конспектларын, планлаштыру материалларын, уен чараларын кулланырга;

– алдынгы педагогик тәҗрибәне тарату максатыннан, шәхси материалларны (фото-, видео-, аудиоформатта, PDF форматында) урнаштырырга;

– педагогларның видеошөгыльләрен карарга һәм бәя бирергә, аларның рейтингын төзергә;

– порталда фото-, аудио-, видеоматериаллар, PDF материалларны карарга;

– китапханә материалларын (фото-, видео-, аудиоформатта, PDF форматында) тирәнтен эзләү ярдәмендә (хештеглар, материал тибы), структурлаштырып (категорияләр, яшькә карап) һәм сортларга аерып (популярлык, исем буенча) кулланырга;

– төркемдә тәрбияләнүчеләрнең планлаштырылган нәтиҗәләрен төбәк буенча балаларның казанышларына чагыштырма анализ ясарга;

– социаль функцияләрне кулланырга: блоглар, шәхси хәбәрләр, дуслар, белдерүләр;

– контентка канәгатьсезлек белдерергә, кулланучылар турында мәгълүматның куркынычсызлык системаларын исәпкә алырга.

Порталда гомуми кулланышта электрон белем бирү ресурслары урнаштырылган, алардан файдалану балаларга белем бирү программасы буенча планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә. Мондый белем бирү ресурсларына аудио-, аудиовизуаль чаралар (слайдфильмнар, видеофильмнар, видеосюжетлар, мультимедиа презентацияләр, мультфильмнар), китапларның электрон версияләре, челтәрле белем бирү ресурслары, мультимедиа универсаль энциклопедияләре, казуаль уеннар һәм башкаларны эченә алган электрон белем бирү ресурслары керә.

Портал Программаны «җанлы», үстерешле итә һәм мөгаллимнәр, модераторлар, методистлар, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының алдынгы педагоглары тарафыннан материалларны камилләштерү һәм тулыландыру хисабына үсә бара торганга әйләндерә. Электрон белем бирү ресурслары педагогларга «Куаныч» программасында каралган бурычларны вариатив рәвештә һәм сыйфатлы итеп гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә.

Цифрлы технологияләрнең үсеше балалар тарафыннан белем бирү Программасын планлаштырылган нәтиҗәләргә ярашлы рәвештә үзләштерү дәрәҗәсен күтәрергә юл ачкан

инновацион характердагы өстәмә белем бирү ресурсларын булдыруны актуальләштерә. Мондый белем бирү ресурсларына китап басмалары, интерактив уеннар, сайтлар, порталлар һәм башкалар керә.

Нәшрият эшендә мәсьәләләрне заманча хәл итү мәгариф өлкәсендә үстерешле һәм тәрбияви нәтиҗәлелекне тәэмин итәргә сәләтле «инновацион китаплар» ясарга мөмкинлек бирә. «Инновацион китаплар»ны шартлы рәвештә өч төркемгә бүләргә була: сәнгати-анимацион, цифрлы басмалар, мобиль кушымталы басмалар.

Сәнгати-анимацион басмалар төркемен түбәндәге әсәрләр тәшкил итә: «Шүрәле»; «Тылсымлы сәхифәләр»; «Койрыклар»; «Йаван-паттар» (чуваш әкиятләре буенча); «Идел буе батырлары» (17 телдәге версиядә); «Кырмысказки-1»; «Кырмысказки-2»; «Кырмысказки-3»; «Бикбатыр белән Биккуркак»; «Бал корты һәм Шөпшә»; «Карга белән Шөпшә».

Мобиль кушымталы басмалар төркеменә «Мирас угы», «Җиде энҗе бөртеге», «Ак Барс кайда яши?» кебек әсәрләр керә. Интерактив такталарга җайлаштырылган интерактив уеннар белән комплектта «Ылыслы әкият»; «Безнең йортыбызга 100 ел»; «Ак Барс кайда яши?» исемле заманча әкиятләр бар.

Цифрлы басмалар төркеменә «БАЛА» (www.бала.рф) мультимедиа балалар китапханәсе һәм «Волжские богатыри» (www.волжскиебогатыри.рф) әкиятләр һәм мультфильмнар җыентыгы керә.

Программа куллану өчен уңайлы, белем бирү сайтларына һәм порталларга иректе керә алуны тәэмин итә. Китапларның электрон версиясе, видеошөгыльләр, аудио- һәм видеоматериаллар, проектлар, уеннар, планлаштыру материаллары һ.б. гомум кулланышта.

Түбәндә китерелгән ресурслар битләрендә педагоглар «Куаныч» программасы тарафыннан куелган белем бирү бурычларын чишәргә кирәкле мәгълүматны таба ала:

www.ganiev.org – тавышландырылган рус-татар онлайн-сүзлеге;

www.500slov.tatar – татар телен өйрәнү порталы;

www.balasuzlek.ru – интерактив анимацияләнгән һәм тавышландырылган онлайн-сүзлек;

www.ak-bure.ru – «Ак Бүре белән татар телен өйрәнәбез» проекты сайты;

www.аваз.бала.рф – мари, татар, чуваш, мордва һәм удмурт телләрендә аваз әйтелешен өйрәнү буенча «Аваз» проекты сайты;

www.tatarhistory.ru – Татарстан тарихы буенча электрон атлас;

www.историятатарстана.рф – татар халкының килеп чыгышы тарихы турында анимацияле ролик;

www.tatarcartoon.ru – «Татармультфильм» берләшмәсе тарафыннан төзелгән анимацияле фильмнар җыентыгы;

www.балачак.рф – «Уйна», «Сабантуй» проектларының сайты;

www.зеленыйтатарстан.рф – балаларның экологик белемен арттыру өчен уникаль интерактив балалар мохитен булдыру проекты сайты;

www.sakla.ru – юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча уникаль интерактив балалар мохитен булдыру проекты сайты.

Мәгълүмат кырының даими киңәюен исәпкә алырга кирәк. Димәк, электрон белем бирү ресурсларының саны арта. Аларны куллану мәктәпкәчә белем бирү оешмасы педагоглары эшенең нәтиҗәлелеген арттырырга булыша, күп көч таләп итә торган планлаштыру, белем бирү эшчәнлеген оештыру процессларын җиңеләйтә, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның барысы өчен дә ярдәмче булып тора.

*3 нче таблица*

| Мәгариф өлкәсе | Җиһазландыру |
|---|---|
| **Иҗтимагый-коммуникатив үсеш** | – Идел буе халыкларының милли киемнәрен кигән курчаклар;<br>– халык уенчыклары (Актүбә һәм Шәмәрдән);<br>– сюжетлы уеннар оештыру өчен уен маркерлары («Гаилә», «Авылда», «Аш бүлмәсе», «Кафе», «Шәһәр буенча сәяхәт» һ.б.);<br>– курчак караваты (бишек);<br>– татар чигешләре элементлары белән ясалган урын-җир һәм кухня кирәк-яраклары комплекты;<br>– кухня кирәк-яраклары: савыт-саба, агач кашыклар, балчык чүлмәк, бакыр самавыр, җиз комган, көянтә белән чиләкләр, уклау, куна тактасы һ.б.;<br>– тозлы камырдан ясалган камыр ризыклары (вак бәлеш, пәрәмәч, чәкчәк һ.б.);<br>– кием-салым предметлары (түбәтәй, яулык, камзул, калфак һ.б.) |
| **Танып белү үсеше** | – Милли бизәкләр белән бизәлгән биш курчаклы матрёшка;<br>– күрсәтмә танып белү материаллары (иллюстрацияләр, карточкалар, электрон картотека, PowerPoint презентацияләре, лэпбуклар, коллекцияләр, видеосюжетлар һ.б.);<br>– аяк киемнәрен, баш киемнәрен, бизәнү әйберләрен дә кертеп (иллюстрацияләр-карточкалар, электрон картотека), Идел буе халыкларының милли киемнәре;<br>– милли костюмны әзерләгәндә кулланыла торган тукымалар коллекциясе;<br>– милли көнкүреш предметлары;<br>– «Татар милли ашлары» китабы;<br>– Татарстан Республикасы башкаласы – Казан шәһәренең истәлекле урыннарының сурәтләре белән бизәлгән слайдлар, фотоальбомнар, буклетлар;<br>– Татарстан Республикасы шәһәрләре, аларның истәлекле, тарихи урыннары, шәһәрләрнең төп предприятиеләре сурәтләре төшерелгән фотоальбомнар (Казан – «Казаноргсинтез», Яр Чаллы – «КАМАЗ», Түбән Кама – «Түбән Кама Шин», Чистай – «Восток» сәгать заводы, Яшел Үзән – «Серго исемендәге завод» (POZIS компаниясе) һ.б.);<br>– һөнәрләр буенча костюмнар комплекты (инженер-нефтьче, төзүче һ.б.);<br>– слайдлар, фотоальбомнар, открыткалар тупланмасы, видеосюжетлар, тарихи һәйкәлләр, музейлар, туган шәһәр (авыл) урамнарын, узган вакыйгаларны презентацияләү; |

| | |
|---|---|
| | – Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең геральдик билгеләре (флаг, герб, гимн);<br>– Россия Федерациясе Президентының, Татарстан Республикасы Рәисенең, шәһәр мэрының портретлары комплекты;<br>– язучы, шагыйрь, рәссам-иллюстратор, композитор һәм республиканың башка күренекле шәхесләренең портретлары комплекты;<br>– Бөек Ватан сугышы геройлары (М. Җәлил, М.П. Девятаев, Г. Гафиятуллин, П.М. Гаврилов, Н.Г. Столяров һ.б.) батырлыклары турында китаплар, фото- һәм видеоматериаллар;<br>– Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның бәйрәм йолаларына (Каравон – Татарстанда рус халык бәйрәме, Сабан туе – татар халык бәйрәме һ.б.) караган күрсәтмә материаллар;<br>– «Зур балалар атласы»;<br>– глобус;<br>– Татарстан Республикасын (картада һәм глобуста республика территориясен, Идел елгасы һәм аның кушылдыклары – Чулман, Зөя, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары, Кабан күле, якын-тирәдәге күл һәм елгаларны билгеләргә), Татарстанның эре шәһәрләрен (Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Яшел Үзән, Лениногорск, Яр Чаллы, Түбән Кама, Чистай һ.б.) географик картада күрсәтү өчен материаллар;<br>– балалар өчен төбәкнең хайваннар һәм үсемлекләре турында документаль (танып белү, үстерешле) фильмнар;<br>– туган як табигате турында картиналар репродукцияләре җыелмасы («Язгы челтәр», Р. Исмәгыйлев; «Яшел челтәрләр», «Көзге челтәрләр», Х. Якупов һ.б.);<br>– туган як үсемлекләреннән гербарий (агачлар – имән, юкә, нарат, усак, чыршы, өрәңге һ.б.; чәчәк ата торган үләннәр (дару үләннәре) – сары мәтрүшкә, зәңгәр мәтрүшкә, кычыткан, хуш исле бөтнек һ.б.); кыр һәм болын чәчәкләре – күкчәчәк, ромашка, кыңгырау чәчәк, тукранбаш, кыр миләүшәсе һ.б.), үсемлек орлыклары, җимешләре коллекциясе;<br>– урман (болын) җиләкләренең (каен җиләге, җир җиләге, кура җиләге, каражиләк һ.б.) рәсемнәре;<br>– яшелчә, җиләк-җимеш, гөмбә муляжлары;<br>– йорт хайваннары сурәтләнгән рәсемнәр (сыер, ат, сарык, кәҗә, эт, мәче һ.б.);<br>– йорт кош-кортлары сурәтләнгән рәсемнәр (әтәч, тавык, чебеш, үрдәк, каз, күркә һ.б.);<br>– төбәктә яши торган кыргый хайваннар төшерелгән рәсемнәр (бүре, төлке, керпе, куян, поши, аю, силәүсен, сусар, ак куян, соры куян һ.б.);<br>– кышлаучы кошлар төшерелгән рәсемнәр (саескан, карга, песнәк, чыпчык, тукран, көртлек, суер, байгыш, ябалак һ.б.);<br>– күчмә кошлар төшерелгән рәсемнәр (карлыгач, сыерчык, кара карга, шәүлегән, күке, тургай, сандугач һ.б.); |

| | |
|---|---|
| | – йөзүче кошлар сурәтләнгән рәсемнәр (акчарлак, аккош, каз, үрдәк, челән һ.б.);<br>– канатлы ерткычларның сурәтләре (сапсан, карчыга, ак башлы сип, кара гриф, дала бөркете, бөркет, тилгән һ.б.);<br>– хайван һәм кош фигуралары җыелмасы;<br>– Татарстан Республикасының Кызыл китабы;<br>– балалар энциклопедиясе;<br>– музей экспонатларын карау өчен фотоальбомнар (Татарстан Республикасы Милли музее, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы, Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы, Габдулла Тукай әдәби-мемориаль музей комплексы һ.б.);<br>– балалар өчен документаль (үстерешле, танып белү) фильмнар, Казан шәһәре тарихы турында күрсәтмә әсбаплар;<br>– балалар өчен Зөя утрау-шәһәренең истәлекле урыннары сурәтләнгән күрсәтмә әсбаплар, документаль фильмнар;<br>– балалар өчен борынгы Болгарның истәлекле урыннары сурәтләнгән күрсәтмә әсбаплар, документаль фильмнар |
| **Сөйләм үсеше** | – Татарча-русча сүзлек, русча-татарча сүзлек, синонимнар сүзлеге һ.б.;<br>– «Изучаем русский язык» УМК күрсәтмә һәм тарату материаллары;<br>– мөстәкыйль эш өчен эш дәфтәрләре;<br>– балалар китапханәсе;<br>– өлкәннәр өчен басма һәм/яисә электрон китапханә;<br>– Татарстан Республикасы рәссам-иллюстраторлары, балалар язучылары, шагыйрьләренең портретлары;<br>– «Татармультфильм» берләшмәсе мультфильмнары;<br>– китаплар, халык мәкальләре һәм әйтемнәре картотекасы (тасвирламалары һәм килеп чыгышы тарихы белән бергә);<br>– предметлы, сюжетлы, киселә торган рәсемнәр;<br>– «Артык сүз» сүзләр уены картотекасы;<br>– өстәл уеннары («Лото», «Домино», «Өченче артык», «Дүртенче артык» һ.б.);<br>– үстерешле уеннар («Сурәтләү буенча тап», «Парын тап», «Тылмачлар», «Сүзләр чылбыры» һ.б.);<br>– бармак уеннары;<br>– театральләштерелгән уеннар, режиссёрлык уеннары, импровизацияләр өчен атрибутлар; битлекләр, ярымбитлекләр;<br>– сөйләргә өйрәтү алгоритмнары (схемалары), интеллект-карталар төзү өчен материаллар, шигырьләр өйрәнү, табышмаклар уйлап табу өчен мнемотаблицалар;<br>– татар халык әкиятләре буенча рәсемнәр;<br>– балалар китаплары өчен рәсемнәр ясаучы татар рәссам-иллюстраторлары репродукцияләре тупланмасы (Ф. Хәсьянова һ.б.);<br>– иҗтимагый күренешләрне сурәтләгән татар рәссамнары картиналары репродукцияләре тупланмасы («Сабан туе», Л. Фәттахов; «Әбием тарихлары», Ш. Нигъмәт һ.б.) |

| | |
|---|---|
| **Сәнгати-эстетик үсеш** | – 3–7 яшьлек балалар өчен «Шома бас» татар халык бию көйләре язмалары;<br>– татар халык җырлары, балалар башкаруындагы җырлар, татар композиторларының музыка әсәрләре язмалары һ.б.;<br>– музыка уен кораллары (иллюстратив материаллар, язмалар): думбра, кубыз, мандолина, курай, гармун, тальян гармун һ.б.;<br>– Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле чыгышларының видеоязмалары;<br>– республика балалар хореография һәм вокаль ансамбльләре чыгышларының видеоязмалары;<br>– Татарстан Республикасы композиторлары, рәссамнары, скульпторлары, режиссёрлары, театр актёрлары, атаклы җырчыларының портретлары комплектлары;<br>– Идел буе халыклары биюләрен башкару өчен костюмнар комплектлары;<br>– театральләштерелгән күренешләрне, импровизацияләрне кую өчен костюмнар комплекты;<br>– татар декоратив-гамәли сәнгать чәчәк-үсемлек орнаментын төзү өчен җыелма;<br>– республика халык кәсепчелегенә караган рәсемнәр (басма һәм электрон);<br>– «Түбәтәйне бизә» (читек, алъяпкыч, яулык һ.б.) дидактик уеннары (шул исәптән электрон);<br>– «Лото» («Музыка уен кораллары», «Орнаментлар» һ.б.) дидактик уены;<br>– киселә торган рәсемнәр (предметлы, сюжетлы);<br>– буяу өчен комплектлар;<br>– мөстәкыйль эшчәнлек өчен кием, көнкүреш, архитектура ансамбльләре предметлары комплектлары;<br>– курчак театры;<br>– татар телендә «Шаян ТВ» балалар телеканалы тапшырулары, «Яшь ТНВ» балалар һәм яшьләр телеканалы кысаларында нәниләр өчен «Күчтәнәч» тапшырулары видеоязмалары |
| **Физик үсеш** | – Идел буе халыклары уеннары картотекасы;<br>– милли уен-ярышлар атрибутлары (капчыклар, колгалар, чүлмәкләр, сөлгеләр, көянтә-чиләк, кашыклар һ.б.);<br>– «Сабан туе» циклыннан уеннар картотекасы;<br>– сәламәт яшәү рәвешенең файдасы, сәламәт туклану турында мультипликацион фильмнар;<br>– сәламәт яшәү рәвешенең файдасы һәм сәламәт туклану турында китаплар («Сәламәт бул. Өч теләк»);<br>– спорт төрләре һәм танылган спорт командалары турында күрсәтмә материалларның басма һәм/яисә электрон җыелмалары: хоккей буенча – «Ак Барс», футбол буенча – «Рубин», баскетбол буенча – «УНИКС», волейбол буенча «Зенит», «Динамо» командалары һ.б.;<br>– 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасы, 2015 елда узган су спорт төрләре буенча XVI дөнья чемпионаты, 2018 елда узган футбол буенча дөнья чемпионаты, нәфис гимнастика һәм спорт гимнастикасы буенча Россия чемпионатлары һ.б. турында видеофильмнар |

## 3.3. ПРОГРАММАНЫ МАТДИ-ТЕХНИК ЯКТАН ТӘЭМИН ИТҮ, БЕЛЕМ ҺӘМ ТӘРБИЯ ЧАРАЛАРЫ, МЕТОДИК МАТЕРИАЛЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШ (рәсем сәнгате, әдәби һәм анимацияле әсәрләрнең якынча исемлеге белән)

Матди-техник чаралар зур потенциаль мөмкинлекләргә ия. Компьютер технологияләренең, цифрлы чараларның һәм башка техник җайланмаларның гаять тиз үсеше матди-техник чараларны актуальләштерде. Димәк, бүгенге мәктәпкәчә мәгариф системасына 1.2.3685-21 Санитария кагыйдәләре һәм нормаларына туры китереп эшләнгән мәгълүмат-белем бирү – мантыйкка ярашлы һәм зарури адым.

Компьютер-техник чараларны рациональ куллану балаларны татар (рус) теленә өйрәтүнең сыйфатын күтәрергә, балаларга барлык белем бирү өлкәләре буенча Программаны үзләштерүнең фаразланган нәтиҗәләренә ирешергә мөмкинлек тудыра. Шуңа күрә Оешмада Программаны электрон ресурслар, шулай ук аудиосистема (музыкаль үзәк), телевизор, мультимедиа җайланмалары һәм/яисә интерактив такта, проектор, стационар һәм мобиль компьютерлар, принтер, ноутбук, бала өчен нетбук, документ-камера, MimioPad чыбыксыз график планшеты һ.б. компьютер-техник чаралар белән тәэминителеше алдан ук каралырга тиеш.

Оешманың компьютер-техник җиһазланышын төрле максатларда кулланырга була:

– балаларга әдәби, музыкаль әсәрләрне, танып белүгә ярдәм итү фильмнарын, нәфис фильмнарны, «Татармультфильм» берләшмәсенең мультипликацион фильмнарын һ.б.ны күрсәтү өчен;

– төп белем бирү программасының вариатив өлешен гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган материалларны мәгълүмат мохитендә эзләү өчен;

– барлык кызыксынган затларга, шулай ук киң җәмәгатьчелеккә Программа турында мәгълүмат бирү өчен;

– Программаны үзләштерү һәм гамәлгә ашыруга кагылышлы проблемалар турында тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары (законлы вәкилләре) белән фикер алышу өчен.

Заманча белем бирү процессы презентацияләр ясау (PowerPoint; Prezi), дидактик электрон уен һәм әсбаплар булдыру (SMARTNotebook; EasiTeach) өчен программа белән тәэмин ителешне, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташтыруны күз алдында тота.

Программа бурычларын нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен, техник һәм мультимедиа ягыннан тәэмин итү генә түгел, махсус җайланмаларны, укыту-методик комплектларын, белем бирүнең заманча чараларын, төрле үстерешле уеннар комплектларын да куллану зарур.

Татар (рус) теленә өйрәтү шөгыльләре һәм проектларны тормышка ашыру бүлмәләре, төркем бүлмәләрендә милли мәдәният үзәге, халык көнкүреше мини-музее, халык кәсепләре күргәзмәсе, туган як табигатенең сурәтләре куелган фотокүргәзмәләр күпфункцияле һәм дидактик мөмкинлекләргә ия.

Оешма белем бирүдә кирәкле компьютер-техник чараларны, җиһазларны, электрон белем бирү ресурсларын, әдәби, музыкаль, анимация әсәрләрен һәм Татарстан Республикасы Дәүләт музее картиналары репродукцияләрен мөстәкыйль сайлый ала.

### 3.3.1. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘСЕМ СӘНГАТЕ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ЯКЫНЧА ИСЕМЛЕГЕ

1. Абдулов У.Н., «Кечкенә Тукай Печән базарында»
2. Акимов В.Я., «Зәңгәрсу таң»
3. Газиев Р.Х., «Акбай»
4. Газиев Р.Х., «Мәрҗани мәчете»

5. Гайфуллин А.И., «Зәңгәр күл»
6. Гайфуллин А.И., «Иртә»
7. Гайфуллин А.И., «Казан Кремле»
8. Гайфуллин А.И., «Казан университеты»
9. Гайфуллин А.И., «Кол Шәриф мәчете»
10. Гайфуллин А.И., «Көз»
11. Гайфуллин А.И., «Тирән күл»
12. Гыймаев З.Ф., «Әбигә хат килде»
13. Зарипов И.К., «Сөембикә улы Үтәмеш белән»
14. Заһидуллин Р.Г., «Бакчада»
15. Заһидуллин Р.Г., «Казан урамнарында»
16. Заһидуллин Р.Г., «Кунаклар килде. Иске Татар бистәсендә»
17. Заһидуллин Р.Г., «Сабантуй алдыннан бүләк җыю»
18. Зуев Е.В., «Катык»
19. Зуев Е.В., «Кәбестә. Октябрь»
20. Зуев Е.В., Өчпочмак һәм пәрәмәчләр»
21. Зуев Е.В., «Сөлге белән натюрморт»
22. Зуев Е.В., «Чәй һәм чәкчәк»
23. Казаков Х.И., «Кечкенә Тукай»
24. Кугач М.Ю., «Бәйрәм алдыннан»
25. Кугач М.Ю., «Кайту»
26. Лепилов К.М., «Атлар печән олавы янында»
27. Мавровская М.К., «Тукай балачакта»
28. Мортазин И.Х., «Бәйрәм»
29. Мортазин И.Х., «Сабантуй»
30. Неустроев С.В., «Борынгы әйберләр»
31. Неустроев С.В., «Кыр чәчәкләре»
32. Неустроев С.В., «Рәхим итегез»
33. Неустроев С.В., «Ромашкалар»
34. Неустроев С.В., «Самавыр белән натюрморт»
35. Нигъмәтуллин Ш.Г., «Җиңү белән кайтыгыз»
36. Нигъмәтуллин Ш.Г., «Кояшлы март»
37. Рәфыйков И.В., «Кунакка»
38. Рәфыйков И.В., «Сөембикә»
39. Рәфыйков И.В., «Сугыш елларында»
40. Рәфыйков И.В., «Туган тел»
41. Родионов А.М., «Кайту»
42. Сәйфетдинов Ә.К., «Татар килене»
43. Урманче Б.И., «Мөнирә Булатова портреты»
44. Урманче Б.И., «Сара ханым Илдар белән»
45. Урманче Б.И., «Сирень»
46. Урманче Б.И., «Шара Жандарбекова портреты»
47. Фәттахов Л.Ә., «Әни күрмәгәндә»
48. Фәттахов Л.Ә., «Сабантуй»

49. Фəттахов Л.Ә., «Язгы рəссамнар»
50. Фəхретдинов Р.З., Татарстан Республикасының гербы
51. Фёдоров В.А., «Тукайның Өчиледəн Кырлайга китүе»
52. Халиков Ф.Г., «Сөембикə белəн хушлашу»
53. Хафизов Д.С., «Җəй ислəре»
54. Хафизов Д.С., «Төче чия белəн натюрморт»
55. Худяков В.Г., «Әсирлеккə төшкəн Сөембикəнең Казан белəн хушлашуы»
56. Хуҗин Р.Ф., «Арбор. Кыш»
57. Хуҗин Р.Ф., «Тəрəзə янында»
58. Шəйдуллин Ш.М., «Карт алмагач төбендə»
59. Ширяева А.Г., «Авыр елларда»
60. Шишкин И.И., «Аланлык»
61. Шишкин И.И., «Арыш»
62. Шишкин И.И., «Имəн урманында печəн чабу»
63. Шишкин И.И., «Нарат урманында иртə»
64. Шишкин И.И., «Нарат урманында кич»
65. Якупов Р.Ш., «Ишегалды»
66. Якупов Р.Ш., «Өйгə»
67. Якупов Х.Г., «Ана портреты»
68. Якупов Х.Г., «Габдулла Тукай истəлегенə»
69. Якупов Х.Г., «Девятаев портреты»
70. Якупов Х.Г., «Хөкем алдыннан»
71. Якупов Ш.К., «Урман əкияте»
72. Якупов Ш.К., «Урман əкияте» (кыш алдыннан)
73. Якупов Ш.К., «Уяну»
74. Якупов Ш.К., «Хатирəлəр»
75. Яманова Р.Р., «Өчиле – Тукай ягы»

Скульптура
1. Зяблицев Г.А., «Былтыр һəм Шүрəле»
2. Нигъмəтуллина Р.Х., «Туган тел»
3. Нигъмəтуллина Р.Х., «Фазыл чишмəсе»

Скульптура композициялəре
1. Башмаков И.Н., «Бакалар» фонтаны
2. Башмаков И.Н., «Екатерина II каретасы»
3. Башмаков И.Н., «Казан мəчесе»
4. Башмаков И.Н., «Күгəрченнəр» фонтаны
5. Башмаков И.Н., «Су анасы» фонтаны
6. Башмаков И.Н., «Тукай мəйданындагы сəгать»
7. Вəлиуллин Ф.Ә., «Күлгə»
8. Вəлиуллин Ф.Ә., «Ышаныч»
9. Миңнуллина А.М., «Су ташучыга һəйкəл»
10. Миңнуллина А.М., «Хəйриячегə һəйкəл»
11. Миңнуллина А.М., «Шүрəле серлəре»

## 3.3.2. «ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ» БЕРЛӘШМӘСЕ МУЛЬТИПЛИКАЦИОН ФИЛЬМНАРЫНЫҢ ЯКЫНЧА ИСЕМЛЕГЕ

1. «Агачлар да авырый», «Татармультфильм» берләшмәсе.
[Электрон ресурс]. URL: https://youtu.be/E0YzTDTJE6k
2. «Ай һәм Кояш» https://youtu.be/T06zBPTn9tk
3. «Ак Бабай» https://youtu.be/-qB0d2EHKVI
4. «Ак Барс» https://youtu.be/xfXX7HEuUlI
5. «Алты хәреф» https://youtube.com/playlist?list=PLche815oSwI-zaLG86gJDEpKbLtbQvvSh )
6. «Алтын бөртекләр» https://youtu.be/xev-rPfrkq4
7. «Бал корты һәм Шөпшә» https://youtu.be/X-OOEB6Ndko
8. «Бала белән Күбәләк» https://youtu.be/9HtBrPPKtmg
9. «Бикбатыр белән Биккуркак» https://youtu.be/9Quatjx4Yg8
10. Блокнотчык һәм Мөһер. 1 серия http://xn-80akhkd8ah.xn-p1ai/mults
11. Блокнотчык һәм Мөһер. 2 серия http://xn-80akhkd8ah.xn-p1ai/mults
12. Блокнотчык һәм Мөһер. 3 серия http://xn-80akhkd8ah.xn-p1ai/mults
13. «Бүләк кемгә?» https://youtu.be/4OUS1YlEYgQ
14. Татарстан гасыры 1 – www.вектатарстана.рф
15. Татарстан гасыры 2 – www.вектатарстана.рф
16. Татарстан гасыры 3 – www.вектатарстана.рф
17. Татарстан гасыры 4 – www.вектатарстана.рф
18. «Гали белән Кәҗә» https://youtu.be/Ocfb9kUTU7o
19. «Ике кыз» https://youtu.be/y0lRicLwwfs
20. «Иртә» https://youtu.be/njfSUazXP5A
21. «Каз белән Аккош» https://youtu.be/xjQqmtrQDgk
22. «Карга белән Шөпшә» http://tatarcartoon.ru/view?q=vALtCzW-U8Ipn
23. «Кәҗә белән Сарык» https://youtu.be/G2VjXpiPl-w
24. «Кем көчле?» https://youtu.be/H9D0QTrKEp4
25. «Койрыклар» https://youtu.be/NTwwWJ4qrxA
26. «Куян кызы» http://tatarcartoon.ru/view?q=0FEaOb18b0ERH
27. «Кызыклы шәкерт» https://youtu.be/pwr9onB6bqg
28. «Кырлай» https://youtu.be/uhYVhHt0Frg
29. «Кырмысказки-2018» http://tatarmultfilm.ru/ cartoons/kyrmyskazki
30. «Кырмысказки-2019» http://tatarmultfilm.ru/ cartoons/kyrmyskazki-2
31. «Кырмысказки-2020» http://tatarmultfilm.ru/ cartoons/kyrmyskazki-3
32. «Кышкы кич» https://youtu.be/InMnR7aHyDY
33. «Мактанчык чыпчык» https://youtu.be/hQXQfFMWmQQ
34. «Өч кыз» https://youtu.be/RwkxdsMBMb0
35. Сабантуй http://tatarmultfilm.ru/cartoons/sabantui
36. «Сертотмас үрдәк» http://tatarmultfilm.ru/view?q=yjAvOK8vvfZ3A
37. «Сөткә төшкән тычкан» https://youtu.be/YOs3nsraa_k
38. «Су анасы» https://youtu.be/qYSVkfT4Ht4
39. «Төлке белән Каз» https://youtu.be/yk0YGTzwz_Y
40. «Туган тел» https://youtu.be/bv53S25q7sQ
41. «Чукмар белән Тукмар» https://youtu.be/g70CLzBKx7A
42. «Шаян песи» https://youtu.be/rVXkixAmNi4

43. «Шүрәле» https://youtu.be/sflrlsXHZ-A
44. «Эш беткәч уйнарга ярый» https://youtu.be/wbVxupDwPS4
45. «Ялкау маэмай» https://youtu.be/Vpaq8DGROJk
46. «Яңгыр илә Кояш» https://youtu.be/_EbOWAWbFnI

## 3.3.3. «БАЛА» МУЛЬТИМЕДИА КИТАПХАНӘСЕ. ЯКЫНЧА МАТУР ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

*Әкиятләр, легендалар:* «Ата каз», «Алтын бөртекләр», «Ике кыз», «Бүләк кемгә?», «Аю белән Хатын», «Балыкчы Аю», «Ике ялкау», «Песәй», «Куркак юлдаш», «Ялкау малай», «Кәҗә бәтиләре һәм Бүре», «Мәче белән Аю», «Өч кыз», «Карт белән Төлке», «Тавык, Тычкан һәм Көртлек», «Кем нәрсә ярата?», «Төлке белән Каз», татар халык әкиятләре; «Зөһрә йолдыз», «Тавык нигә суда йөзә алмый?», легендалар; «Тычкан тотучы мәче», мәзәк; «Йомры кумәч», «Төлке белән Торна», «Аю белән Бабай», «Шалкан», рус халык әкиятләре; «Бөдрә чәчле кыз», чукча халык әкияте; «Шат күңелле Чыпчык белән карт Карга», калмык халык әкияте; «Абый белән эне», хакас халык әкияте.

*Дөнья халыклары әкиятләре:* «Башак», «Сандугач», украин халык әкиятләре; «Тавык белән Сарык», «Бүре аларны нигә ашаган?», болгар халык әкиятләре; «Кәҗә бәтие, Бәрән һәм Бозау», абхаз халык әкияте; «Әтәч ничек көлкегә калган?» әкияте; «Ябалак» әкияте; «Конфет ашап тамак туямы?», корея халык әкияте; «Күбәләкләр ничек барлыкка килгән?», филиппин халык әкияте; «Комсызлык бәласе», венгр халык әкияте; «Әтәч һәм Бөркет», тибет халык әкияте; «Итагатьле мәче», литва халык әкияте; «Икмәк», төрекмән халык әкияте.

*Әдәби әкиятләр:* Ә. Бикчәнтәева. «Туп-туп тубыбыз», «Тәмле сүз»; Р. Вәлиева. «Акыллы малай икән», «Кыңгырау чәчәк», «Күбәләк белән Кырмыска», «Туган көндә»; Җ. Тәрҗеманов. «Җиләккә барганда», «Йокы бабай», «Табылган әйбер»; И. Туктар. «Җем-җем!.. Чвик!..», «Ялкау өчен ботка суынган»; Р. Батулла. «Елак Әтәч», «Шапшакларны бака ялый», «Аю Әппәс», «Әйлән-бәйлән уены»; З. Хөснияр. «Куян кучтәнәче, яки Тешсез малай»; Ф. Яруллин. «Иң бәхетле көн», «Кояштагы тап»; Ф. Зариф. «Чишмә»; Б. Рәхмәт. «Бала белән Әтәч»; Ш. Галиев. «Рус казлары: га-га-га», «Камканы коткардым»; Р. Шәрипова. «Катыктан акча эзләү», «Чүлмәк вату»; З. Гомәрова. «Ашыгыч ярдәм», «Кояш елый»; Г. Бакир. «Йорт салалар»; Җ. Дәрзаман. «Актырнак белән Назбикә», «Чүкеч»; М. Хәсәнов. «Көн җылынды»; И. Шәймөхәммәтов. «Мактанчык бака»; Ф. Мәрданова. «Керпе ничек энәле булган?»; С. Сәүбанова. «Мактанчык алма», «Керпе», «Шифалы сөт»; Э. Шәрифуллина. «Бәлки, җавап бирерсез?», «Әкияттәге кебек», «Бәйрәм ашы – кара-каршы», «Алтын балык»; Ә. Гаффар. «Койрык», «Суалчан кунакка бара», «Юынмый торган балык», «Кыңгырау чәчәкләр»; Р. Вәлиев. «Уенчыклар», «Төнге әкият», «Тегермән», «Өйдәге диңгез», «Икеле»; Г. Тукай. «Һәркем эштә», «Ташбака белән Куян», «Ай һәм Кояш»; А. Алиш. «Чукмар белән Тукмар», «Куян кызы», «Каз белән Аккош», «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар», «Бал корты һәм Шөпшә», «Бик яхшы сабак алды ябалак»; Н. Исәнбәт. «Куянкай», «Һәркемнең үз эше»; Г. Мөхәммәтшин. «Ак песи», «Гап-гади Инсаф»; Д. Гарифуллин. «Йә, алар кемнәр икән?»; Ә. Хәсәнов. «Балалар бакчасында»; Г. Таһирова. «Кечкенә миләш»; Н. Әхмәдиев. «Яңа чана», «Басмада»; С. Гаффарова. «Гөлгүзәл»; Г. Лотфи. «Тамчы»; Н. Фәттах. «Ирек, Алмас һәм Җәлил», «Велосипедлы Мөнир»; К. Насыйри. «Комсыз эт»; Р. Гыйззәтуллин. «Айсылу»; Л. Толстой. «Төлке белән Кысла»; Дәрдемәнд. «Өч угыл»; М. Гафури. «Әби белән онык»; Р. Мингалим. «Канатларың булса...», «Дөресе аның шулай...»; Л. Лерон. «Супермалай»; Х. Халиков. «Хәзер инде өчәү без», «Витаминлы аш», «Ярканат»; Ә. Исхак. «Гүзәл»; Д. Аппакова. «Рөстәм»; М. Хөсәен. «Безнең дуслар»; М. Җәлил. «Күке»; С. Әдһәмова. «Дуслар»; Ф. Садриев. «Ботка»; Ф. Зыятдинов. «Карга белән Шөпшә»; Хәйдәр. «Керпе туны»; М. Әмир. «Бәби әйтә»; Г. Гомәр.

«Чуар тавык»; Р. Фәхретдин. «Ашау әдәпләре»; К. Ушинский. «Җил белән Кояш»; З. Әхмәров. «Агачлар да авырый»; Т. Әйди. «Дачада»; Ә. Баян. «Яхшылык кире кайта»; А. Хәсән. «Кыш бабай бүләк өләшә»; Н. Каштанов. «Канатлы ай»; Г. Сабитов. «Кадерле бүләк»; М. Закир. «Кара төс ни өчен кирәк?»

## 3.4. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУДА КАДРЛАРГА КАРАТА КУЕЛГАН ШАРТЛАР

Педагогларның һәм укыту-ярдәмче хезмәткәрләрнең Оешмада балаларны даими карап-тәрбияләп торуы Программаны сыйфатлы рәвештә тормышка ашыруның шарты булып тора.

Педагогик хезмәткәрләргә тәрбияче (татар (рус) телен укыту буенча тәрбиячене дә кертеп), өлкән тәрбияче, укытучы-логопед, педагог-психолог, музыка җитәкчесе, физик культура инструкторы кебек белгечләр керә.

Укыту-ярдәмче персоналга тәрбияче ярдәмчесе һәм кече тәрбияче керә. Укыту-ярдәмче хезмәткәрләрнең квалификациясе җитәкче, белгеч һәм хезмәткәрләрнең бердәм квалификация белешмәлегендә билгеләнгән квалификация характеристикаларына туры килергә тиеш.

Педагогик хезмәткәрләрнең квалификациясе «Педагог» һөнәри стандартына, җитәкче, белгеч һәм хезмәткәрләрнең бердәм квалификация белешмәлегендә билгеләнгән квалификация характеристикаларына туры килергә тиеш.

Оешма Программаны гамәлгә ашыру өчен таләп ителгән вазифалар составын һәм хезмәткәрләр санын мөстәкыйль билгели.

Башка педагогик хезмәткәрләрнең вазифалары, Программаның максатларына, белем бирү бурычларына, шулай ук балаларның үсеш үзенчәлекләренә карап, Оешма тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

Программаны тормышка ашыручы педагогик хезмәткәрләр түбәндәге уңайлы мохитне:

– эмоциональ иминлек;

– индивидуальлекне һәм инициативаны хуплау;

– төрле вазгыятьләрдә үзара эш итү өчен кагыйдәләр билгеләү;

– вариатив үстерешле белем бирүне оештыру;

– балага белем бирү мәсьәләләре буенча ата-ана (законлы вәкилләр) белән аралашуны булдыру өчен кирәкле һөнәри компетенцияләргә ия булырга тиеш.

Программаны нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен, Оешма педагогик һәм укыту-ярдәмче хезмәткәрләрнең һөнәри, шул исәптән өстәмә һөнәри үсеше өчен шартлар тудыруны күз алдында тотарга тиеш.

Оешма, балаларның сәламәтлеген саклау һәм төбәк үзенчәлекләрен исәпкә алып, белем бирү мәсьәләләре буенча мөстәкыйль рәвештә яисә башка оешмаларны, партнёрларны җәлеп итеп, педагогик кадрларга консультатив ярдәм оештырырга, шулай ук Программаны гамәлгә ашыру процессын методик яктан оештыруны тәэмин итәргә тиеш.

## 3.5. МӘКТӘПКӘЧӘ ТӨРКЕМНӘРДӘ ЯКЫНЧА РЕЖИМ ҺӘМ КӨН ТӘРТИБЕ

Программа Оешмага, төп белем бирү программасын тормышка ашыру шартларын, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның ихтыяҗларын, гамәлгә ашырыла торган вариатив авторлык белем бирү программаларының үзенчәлекләрен, шул исәптән мәктәпкәчә

яшьтәге балаларга өстәмә белем бирү программалары һәм белем бирү эшчәнлегенең башка үзенчәлекләрен күздә тотып, 2.4.3648-20 Санитария кагыйдәләре һәм 1.2.3685-21 Санитария кагыйдәләре һәм нормаларына туры китереп эшләнгән көндәлек режимны һәм көн тәртибен мөстәкыйль билгеләү хокукын калдыра.

## 3.6. БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕН ПЛАНЛАШТЫРУ

Программа белем бирү процессын катгый регламентлауны һәм белем бирү эшчәнлеген календарь планлаштыруны күздә тотмый, ул, төп белем бирү программасының үзенчәлекләреннән, белем бирү эшчәнлеге шартларыннан, Оешма педагоглары һәм укыту-ярдәмче персоналының, тәрбияләнүчеләр һәм аларның гаиләләренең ихтыяҗларыннан һәм мөмкинлекләреннән, кызыксынуларыннан һәм инициативаларыннан чыгып, Оешма педагогларына үз эшчәнлекләрен үзгәрүчән, яраклашучан итеп планлаштыру өчен урын калдыра.

Педагогларның эшчәнлеген планлаштыру баланың шәхси үсешен педагогик бәяләү нәтиҗәләренә таяна һәм беренче чиратта һәр баланың үсеше өчен психологик-педагогик шартлар тудыруга, шул исәптән предметлы пространство мохитен үстерүгә юнәлдерелергә тиеш. Планлаштыру оешма эшчәнлеген камилләштерүне күздә тота һәм Программаны гамәлгә ашыру сыйфатын эчке һәм тышкы бәяләү нәтиҗәләрен исәпкә алырга мөмкинлек бирә.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының тәрбия эше календарь планында чагылдырылган барлык чаралар да Программаның үзенчәлекләрен, төбәкнең дәүләт һәм милли бәйрәмнәрен, истәлекле даталарын истә тотып уздырылырга тиеш.

**Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының тәрбия эше календарь планындагы дәүләт бәйрәмнәре һәм милли бәйрәмнәр, истәлекле даталарның якынча исемлеге**

30 нчы август – Казан шәһәре көне

15 нче сентябрь – татар язучысы Абдулла Алиш туган көн
Сентябрьнең икенче яртысы (22 нче сентябрь) – Сөмбелә бәйрәме
27 нче сентябрь – РСФСРның халык рәссамы Лотфулла Фәттахов туган көн

6 нчы ноябрь – Татарстан Республикасы Конституциясе көне
Ноябрьнең икенче яртысы – Каз өмәсе
29 нчы ноябрь – Татарстан Республикасы Дәүләт флагы кабул ителгән көн

3 нче декабрь – татар композиторы Салих Сәйдәшев туган көн
22 нче декабрьдән 7 нче гыйнварга кадәр – Нардуган көннәре

13 нче гыйнвар – рус рәссамы, пейзажист Иван Шишкин туган көн
15 нче гыйнвар – композитор Нәҗип Җиһанов туган көн
Гыйнварның икенче яртысы – Орчык бәйрәме (йон эрләү йоласы)

7 нче февраль – Татарстан Республикасының Дәүләт гербы кабул ителгән көн
15 нче февраль – герой-шагыйрь Муса Җәлил туган көн
21 нче февраль – Халыкара туган тел көне

18 нче март – татар композиторы Фәрит Яруллин туган көн
1–20 нче март – Карга боткасы (татар мәҗүси бәйрәме)
21–22 нче март – Нәүрүз көннәре
Март-апрель – «Боз озату» татар халкының йола бәйрәме

26 нчы апрель – татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай туган көн
26 нчы апрель – Татарстанда Туган тел һәм шигърият бәйрәме (шагыйрь Г. Тукай көненә багышлап үткәреләә)

1 нче май – татар шагыйрәсе Резеда Вәлиева туган көн
Май-июнь – Каравон рус халык бәйрәме (уздыру вакыты Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләнә)

Июнь – Татар халкының милли бәйрәме Сабан туе (уздыру вакыты Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләнә)

14 нче июль – Татарстан Республикасының Дәүләт гимны кабул ителгән көн

1 нче август – Татарстан Республикасының халык шагыйре Роберт Миңнуллин туган көн



*1 нче кушымта*

## НОРМАТИВ ҺӘМ НОРМАТИВ-МЕТОДИК МАТЕРИАЛЛАР ИСЕМЛЕГЕ


1. Россия Федерациясе Конституциясе (26 нчы маддә).

2. Бала хокуклары турында конвенция. БМО Генераль Ассамблеясенең 1989 елның 20 ноябрендәге 44/25 санлы резолюциясе белән кабул ителгән.

3. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 20 декабрендәге 272-ФЗ номерлы Федераль закон (2014 елның 31 декабрендәге редакциядә, 2015 елның 2 маендагы үзгәртмәләр белән) [Электрон ресурс] // Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы: керә алу режимы: pravo.gov.ru.

4. «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы Федераль законның 11 нче һәм 14 нче маддәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 августындагы 317-ФЗ номерлы Федераль закон.

5. «Россия Федерациясе халыкларының телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы.

6. Татарстан Республикасы Конституциясе (8 нче маддә).

7. «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (2019 елның 9 декабрендәге үзгәртмәләр белән).

8. «Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (2017 елның 27 апрелендәге 27-ЗРТ номерлы үзгәртмәләр белән).

9. «Россия Федерациясендә бала хокукларына төп гарантияләр турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон.

10. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балаларга өстәмә белем бирү концепциясен раслау турында» 2014 елның 4 сентябрендәге 1726-р номерлы боерыгы.

11. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 ел чорына кадәр Россия Федерациясендә тәрбияне үстерү стратегиясе» 2015 елның 29 маендагы 996-р номерлы боерыгы.

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015–2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларны тәрбияләүне үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 443 нче номерлы карары.

13. Баш дәүләт санитария табибының «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял иттерү һәм савыктыру оешмаларына карата санитария-эпидемиология таләпләре» 2.4.3648-20 Санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 нче номерлы карары.

14. Баш дәүләт санитария табибының «Кеше өчен яшәү мохите факторларының куркынычсызлыгын һәм/яисә зарарсызлыгын тәэмин итүгә карата гигиена нормативлары һәм таләпләре» 1.2.3685-21 Санитария кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 2 нче номерлы карары.

15. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандартын раслау турында» 2013 елның 17 октябрендәге 1155 нче номерлы боерыгы (Россия Юстиция министрлыгында 2013 елның 14 ноябрендә теркәлгән, теркәлү номеры 30384).

16. РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Педагог» (мәктәпкәчә, башлангыч, гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү өлкәсендә педагогика эшчәнлеге) (тәрбияче, укытучы) һөнәри стандартын раслау турында» 2013 елның 18 октябрендәге 544-н номерлы боерыгы.

17. Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифаларының бердәм квалификация белешмәлеген раслау турында, «Мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының квалификация характеристикалары» бүлеге хакында» 2010 елның 26 августындагы 761н номерлы боерыгы (2011 елның 31 майдагы редакциясендә) (Россия Юстиция министрлыгында 2010 елның 6 октябрендә теркәлгән, теркәлү номеры 18638).

18. Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Методик рекомендацияләрнең юнәлешләре турында» 2014 елның 31 июлендәге 08-1002 номерлы хаты (Россия Федерациясе субъектларының гражданнарның гомуми һәм бушлай мәктәпкәчә белем алу хокукын тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү буенча хокукларын гамәлгә ашыру буенча методик рекомендацияләр).

19. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2022 елның 25 ноябрендәге 1028 номерлы боерыгы белән расланган (теркәлгән: 28.12.2022, №71847) Федераль мәктәпкәчә белем бирү программасы.

20. Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмалары өчен тәрбия бирүнең якынча эш программасы (2021 елның 1 июлендәге беркетмә, № 2/21).

*2 нче кушымта*

## ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Гаффарова С.М., Гарафиева Г.З., Гарипова Д.С. и др. Изучаем русский язык: методическое пособие по обучению русскому языку детей дошкольного возраста. – Казань: Хэтер, 2011.

2. Гарипова Н.Г., Әхмәтова Р.С., Хәсәнова Ф.М. Әйләнә-тирә дөнья белән танышу (зурлар төркеме): мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен методик кулланма. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2016.

3. Гарәфиева Г.З. Сөмбеләнә кем белә? – Казан: ТаРИХ, 2003.

12. Закирова К.В. Куанычым-багалмам: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2015.

4. Закирова К.В. На поляне детства: хрестоматия для воспитателей дошкольных образовательных учреждений и родителей. – Казань: РИЦ, 2011.

5. Закирова К.В. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия. – Казан: РИЦ, 2011.

6. Закирова К.В. Уйный-уйный үсәбез. Балалар бакчасында уеннар. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2010.

7. Закирова К.В., Гыйләҗетдинова Г.Р. Мин бәйрәмнәр ятатам. Сценарийлар, музыкаль уеннар. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009.

8. Закирова К.В., Кадыйрова Р.Ә., Сафиуллина Г.М. Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе. – Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.

9. Закирова К.В., Кадыйрова Р.Ә. Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе. Методик әсбәп өчен аудиокушымта. – Казан: «Аксу» компаниясе, 2013.

10. Закирова К.В., Мортазина Л.Р. Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак. Балалар бакчасында уеннар. – Казан: РИЦ, 2012.

11. Закирова К.В., Мортазина Л.Р. Әй уйныйбыз, уйныйбыз: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма. – Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.

12. Закирова К.В. Иң матур сүз: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия. – Яңарт. 3 нче басма. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2015.

13. Закирова К.В. Күңел ачыйк бергәләп. Бәйрәм иртәләре сценарийлары. – Казан: Мәгариф, 2003.

14. Зиннурова Ф.М. Уйнап укый сабыйлар: логопедлар, тәрбиячеләр өчен методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2007.

15. Зиннурова Ф.М. Үз илемдә, үз телемдә: логопедлар, тәрбиячеләр өчен методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2009.

16. Зиннәтова Р.М. Сурәтләү һәм кору эшчәнлеге (зурлар төркеме): мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен методик кулланма. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2016.

17. Зиннәтова Р.М., Гәрәева Л.Ә. Сурәтләү һәм кору эшчәнлеге (уртанчылар төркеме): мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен методик кулланма. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2017.

18. Ибраһимова З.Г. Шома бас (Танцуй веселей). – Казан: «Аксу» компаниясе, 2012.

19. Латыйпова В.З. Сабый дөрес сөйләшсен. Логопедия төркемендә коррекция-тәрбия эшен оештыру. – Казан: Мәгариф, 2009.

20. Нәбиуллина Г.Ә., Гыйләҗева Л.Г., Камалова В.М. Татар телендә сөйләм үстерү (зурлар төркеме): мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен методик кулланма. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2016.

21. Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ. Туган телдә сөйләшәбез. Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү (беренче кече яшьтәгеләр төркеме): тәрбиячеләр өчен методик кулланма. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2012.

22. Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ. Туган телдә сөйләшәбез. Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү (икенче кече яшьтәгеләр төркеме): тәрбиячеләр өчен методик кулланма. – Казан: ФОЛИАНТ, 2013.

23. Шаехова Р.К. Рабочая тетрадь №1. «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып. 1 нче кисәк». – Казань: Хәтер, 2011.

24. Шаехова Р.К. Рабочая тетрадь №2. «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып. 2 нче кисәк». – Казань: Хәтер, 2011.

25. Шаехова Р.К. Методическое пособие к рабочей тетради «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып. 1–2 нче кисәкләр». – Казань: Хәтер, 2011.

26. Шаехова Р.К. Раз – словечко, два – словечко...: занимательное обучение татарскому языку / Р.К. Шаехова. – Казань: Хәтер, 2011.

# ЭЧТӘЛЕК

**КЕРЕШ** ........ 2
**1. МАКСАТЛАР БҮЛЕГЕ** ........ 4
1.1. АҢЛАТМА ЯЗУЫ ........ 4
1.1.1. Программаның максаты һәм бурычлары ........ 4
1.1.2. Программаны формалаштыру принциплары һәм ысуллары ........ 6
1.2. Планлаштырылган нәтиҗәләр ........ 8
1.3. Планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүнең педагогик диагностикасы ........ 15
**2. ЭЧТӘЛЕК БҮЛЕГЕ** ........ 49
2.1. БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘЛӘРЕ БУЕНЧА БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ (УКУ ҺӘМ ТӘРБИЯ) БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ЭЧТӘЛЕГЕ ........ 49
БЕРЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ
Иҗтимагый-коммуникатив үсеш ........ 49
Танып белү үсеше ........ 50
Сөйләм үсеше ........ 51
Сәнгати-эстетик үсеш ........ 52
Физик үсеш ........ 54
ИКЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ
Иҗтимагый-коммуникатив үсеш ........ 55
Танып белү үсеше ........ 57
Сөйләм үсеше ........ 58
Сәнгати-эстетик үсеш ........ 60
Физик үсеш ........ 63
УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ
Иҗтимагый-коммуникатив үсеш ........ 65
Танып белү үсеше ........ 66
Сөйләм үсеше ........ 68
Сәнгати-эстетик үсеш ........ 71
Физик үсеш ........ 76
ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ
Иҗтимагый-коммуникатив үсеш ........ 77
Танып белү үсеше ........ 79
Сөйләм үсеше ........ 81
Сәнгати-эстетик үсеш ........ 84
Физик үсеш ........ 90
МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ
Иҗтимагый-коммуникатив үсеш ........ 92

Танып белү үсеше ....................................................................................94
Сөйләм үсеше ..........................................................................................96
Сәнгати-эстетик үсеш ...............................................................................99
Физик үсеш ..........................................................................................106
2.2. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУДА ВАРИАТИВ
ФОРМАЛАР, АЛЫМНАР, МЕТОДЛАР ҺӘМ ЧАРАЛАР .................................108
2.3. БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ МӘДӘНИ
ПРАКТИКАЛАРНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ..................................................112
2.4. БАЛА ИНИЦИАТИВАСЫН ХУПЛАУНЫҢ ЫСУЛЛАРЫ
ҺӘМ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ ..............................................................................116
2.5. ПЕДАГОГИК КОЛЛЕКТИВНЫҢ ТӘРБИЯЛӘНҮЧЕЛӘР
ГАИЛӘЛӘРЕ БЕЛӘН ҮЗАРА ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ....................118
**3. ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ** .........................................................................125
3.1. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ
ПСИХОЛОГИК-ПЕДАГОГИК ШАРТЛАРЫ ...................................................125
3.2. ҮСТЕРЕШЛЕ ПРЕДМЕТЛЫ ТИРӘЛЕК ҺӘМ
ЦИФРЛЫ МОХИТНЕ ОЕШТЫРУНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ...............................126
3.3. ПРОГРАММАНЫ МАТДИ-ТЕХНИК ЯКТАН ТӘЭМИН ИТҮ,
БЕЛЕМ ҺӘМ ТӘРБИЯ ЧАРАЛАРЫ, МЕТОДИК МАТЕРИАЛЛАР
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШ (рәсем сәнгате, әдәби һәм анимацияле
әсәрләрнең якынча исемлеге белән) ......................................................133
3.3.1. Татарстан Республикасы рәсем сәнгате әсәрләренең
якынча исемлеге.....................................................................................133
3.3.2. «Татармультфильм» берләшмәсе мультипликацион
фильмнарының якынча исемлеге..............................................................136
3.3.3. «Бала» мультимедиа китапханәсе. Якынча матур
әдәбият исемлеге ..................................................................................137
3.4. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУДА КАДРЛАРГА
КАРАТА КУЕЛГАН ШАРТЛАР ..................................................................138
3.5. МӘКТӘПКӘЧӘ ТӨРКЕМНӘРДӘ ЯКЫНЧА РЕЖИМ
ҺӘМ КӨН ТӘРТИБЕ ...............................................................................138
3.6. БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕН ПЛАНЛАШТЫРУ .......................................139
1 нче кушымта. НОРМАТИВ ҺӘМ НОРМАТИВ-МЕТОДИК
МАТЕРИАЛЛАР ИСЕМЛЕГЕ ......................................................................141
2 нче кушымта. ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ ........................142

Уку-укыту басмасы

**Шәехова Резеда Камил кызы**
«КУАНЫЧ» – ТӨБӘКНЕҢ
МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАСЫ

Проектның җитәкчесе
**Алсу Низамиева**

Консультантлар
**Кафия Закирова, Рузалия Кадыйрова, Лилия Шәйдәева, Мөсфирә Нургалиева**

Җаваплы редактор
**Илгизәр Зәкиев**

Әдәби редакторлар
**Зөһрә Фәсхиева, Фәридә Әхмәтҗанова**

Дизайн һәм график вёрстка
**Елена Шәрәпова**

IT бүлек җитәкчесе
**Дамир Бариев**

Техник директор
**Илдар Низаметдинов**

Административ бүлек
**Асия Галиева, Светлана Котдусова, Яна Смоленцева, Анна Кудрявцева**

**Татар балалар нәшрияты**
420047, Казан шәһәре, 3 нче Армавир ур., 8.
www.tdpress.ru

Басарга кул куелды: 11.02.2024. Офсет басма. Тиражы — 1500 данә. Заказ №
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы»нда басылды.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2.

КҮРШЕ УМАРТА ул үрдәк умырзая ит зәңгәр ЗАТ мөһим кыяр һәйкәл ОЧРАШУ ЗИННҺАР олы ЭТ ЕЛ мәхәббәт пәрәмәч елга нечкә оста ТӨЗ кадерле

сулыш сум нәрсә СҮЗ ҮЛӘН өй кыш ләкләк көчтәнәч өн жөмһүрият

гөбәдия вак ерткыч Л исә кайдан үрдәк лаек ЯЛ оя өй кызыл озак океан О кыяр нәрсә хәл нигез жөмлә жомга Ш җитмеш ҮЗ оча

дуслык гадел вазыйфа егет еш дарухәнә дүрт ут җавап егерменче кавын олы Т очрашу һәйкәл НЕФТЬ ОН ҮСМЕР күрше чүл КЫЙБАТ кыйммәтле һәм мәңгегә һава чәч һич НӘНИ ҺӘРВАКЫТ җылыта

су ял оя хәл исәнлек лаек океан озак татар тарак ТҮБӘ зур чәч еш кызыл АЙ ЮЛ ЗАТ лачын заман Л егет келәм пешекче АЙ сабан нигез жомга каен К китап Э Е эт олы

КҮРШЕ УМАРТА ул үрдәк умырзая ит зәңгәр мөһим кыяр һәйкәл ОЧРАШУ ЗИННҺАР ЕЛ мәхәббәт пәрәмәч елга нечкә оста ТӨЗ кадерле
сум нәрсә СҮЗ ҮЛӘН өй
гөбәдия вак ерткыч исә кайдан үрдәк лаек ЯЛ оя өй кызыл озак океан кыяр нәрсә хәл нигез жөмлә җомга җитмеш Ю
дуслык гадел вазыйфа егет еш дарухәнә очрашу һәйкәл НЕФТЬ чүл КЫЙБАТ кыйммәтле һәм мәңгегә



ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ЭМОЦИОНАЛЬ ИНТЕЛЛЕКТ
www.tdpress.ru

ISBN 978-5-6050160-1-4
9 785605 016014 >

www.куаныч.рф

**«Куаныч» порталы сезне куандырсын!**

«Куаныч»та:

- 5 юнәлешкә һәм 5 яшь категориясенә караган план-конспектлар;
- Алдынгы методистлар төзегән төп дәресләр;
- Декоратив-гамәли сәнгать һәм сынлы сәнгать әсәрләре;
- Республика рәссамнары картиналары;
- «Куаныч» программасының электрон китапханәсе;
- Татар телендә мультфильмнар;
- Дәресләр өчен кирәкле (фото, видео, аудио, PDF) материаллар;
- Педагоглар белән тәҗрибә уртаклашу.